Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 42 (1407) 28 октябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

5

Яшь буын тамашачысында классик әсәргә карата ничек кызыксыну уятырга? Г. Кариев театрының яңа спектакле шушы сорауга җавап эзли сыман.

12

Хәзерге көндә АКШта гомер итүче милләттәшебез Зөфәр Бикбов табиб кешенең дә кылкаләм остасы була алуын матур иҗаты белән раслый.

14

Актаныш районы Әнәк авылы үткәнендә «башкорт» милләтенең катнашы юклыгын тарихчы Таһир Кәримов анык дәлилләде.

Алтын көз ул – уйчанланган чагы, Гамьле чагы балачакның да...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2023 елны Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итте.
- Норлат шәһәренең Мәдәният сараенда Түбән Кама татар дәүләт драма театры директоры, Татарстанның халык артисты Рөстәм Галиевның «...Чаклар» китабын тәкъдим итү кичәсе булды.
- Марий Элдагы «Республика татар мәдәният үзәге»нең 25 еллык юбилее уңаеннан Бөтендөнья татар конгрессы ноутбук һәм күпфункцияле техник җиһаз алу өчен сертификат бүләк итте.
- Автор башкаручы Илгиз Шәйхразиев Казахстанның Төркестан шәһәрендә узган «Voice Of Turan» фестивалендә беренче урын алды.
- Татарстан Милли музеенда «Җиңү адымнары – 2022» республика проекты җиңүчеләрен бүләкләделәр.
- Казандагы Мостай Кәрим скверында, шагыйрь һәйкәле каршында беренче тапкыр шигърият бәйрәме узды.
- Татарстанның халык артисты, К.Тинчурин театры актеры Нуретдин Нәҗмиевның юбилее уңаеннан, Балык Бистәсе мәдәният йортында «Гомер буе сине көтәм» спектакле күрсәтелде.
- «Шома бас» бию конкурсының икенче этабы һәм гала-концерты Екатеринбургтагы Халык иҗаты сараенда узачак.
- Казан Кремлендә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган бөтенроссия пленэры эшләреннән гыйбарәт күргәзмә ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Зилә СӨНГАТУЛЛИНА, җырчы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты:

«Без эфирны хәзерге кебек фонограммалар белән тутырмадык. Анда һәрвакыт симфоник оркестрлар белән затлы, җанлы чыгышлар була иде. Музыкаль әсәрләрне симфоник оркестр белән кем яза хәзер? Беркем язмый. «Алтын фонд»ка кергән татар классик һәм чит ил классик әсәрләре – барысы да симфоник оркестр белән язылган әсәрләр».

СЫНАМЫШЛАР

Октябрь япмаса, декабрь япмас ● Беренче кар көндез яуса – кыш салкын, төнлә яуса – җылы була ● Әүвәлге карны күрсәткәч, кырык көннән кар ятар ● Боз кытыршы булып туңса, иген уңар ● Әгәр кар җиде мәртәбә явып, җиде мәртәбә эреп бетеп, сигезенче тапкыр яугач ятса, киләсе җәйне ашлык бик уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 40 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 13 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 33 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **4 ноябрьдә 9 сәгать 02 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

28 октябрь – язучы Шәрига Гази кызы Таһированың тууына 100 ел (1912–2006);

– Халыкара анимация көне.

31 октябрь – филология фәннәре кандидаты, әдәби тәнкыйтьче һәм публицист Рәшит Габделхак улы Фәтхрахмановка 60 яшь (1962).

30 октябрь – Башкортстанның һәм Россиянең атказанган рәссамы, С.Юлаев премиясе лауреаты Айрат Рәүф улы Терегуловка 65 яшь (1957);

– СССРдагы сәяси репрессияләр корбаннарын искә алу көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрь-ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 28 октябрь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(25 октябрь – 1 ноябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә** кадәр бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл ахир аеның 3 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ, академик

ЭКСПЕРИМЕНТ ХӘЕРЛЕГӘ БУЛЫРМЫ?

«Мәдәни җомга» газетасының 30 сентябрь санында мәктәптә укыту программаларындагы үзгәрешләр турында аңлатып язылган «Яңа федераль стандартлар: татар теле сәгатьләре ике тапкыр кимергә мөмкин» дигән бик әһәмиятле мәкалә басылып чыкты. Моның өчен аның авторына һәм газета хезмәткәрләренә рәхмәт, мондый яңалыкларны белеп тору бик мөһим. Шушы хәл уңаеннан борчулы уйларыбызны бәян итәргә кирәктер.

Безнең илдә фән-техника һәм социаль-икътисад өлкәләрендә экспериментлар, гади тел белән әйткәндә, төрле тәҗрибәләр кылып сынап караулар, еш булып тора. Максат – уңай нәтиҗәләр, әмма алар һәрвакытта да уңышлы килеп чыкмый. Мәсәлән, соңгы ике-өч дистә елда мәгариф өлкәсендә бер-бер артлы үткәрелеп торган экспериментларның күбесе уңай нәтиҗәләргә китермәде, киресенчә, руслардан башка халыкларның милли мәгарифенә зур зыян салды.

Яңа федераль стандартлар туган телләрне һәм милли әдәбиятларны укытуга тагын да биегрәк киртә кору булачак: инде болай да, соңгы елларда кертелгән үзгәрешләр аркасында, бу предметларны өйрәнү өчен атнасына бирелгән ике-өч сәгать минималь вакыт тагын да киметеләчәк, кайбер классларда исә бөтенләй бетереләчәк. Россия мәгариф министрлыгы төзегән 1-9 класслар өчен яңа үрнәк укыту програмаларында туган тел һәм әдәбият дәресләре, узган елныкы белән чагыштырганда, ике тапкыр кими.

1-4 классларда, элекке федераль стандартлар белән чагыштырганда, рус телендә белем алучылар өчен «Туган тел» дәресләре 42 процентка, туган телдә белем алучылар өчен – 52 процентка кимрәк булачак. Рус мәктәпләренең 5-9 нчы классларында туган тел дәресләре 33 процентка, милли мәктәпләрдә – 48 процентка кимиячәк. Туган тел укытуга вакыт чит телләрне өйрәтүгә караганда азрак бирелә.

Кешенең башын бутау өчендер: укыту программаларын төрле вариантларда төзү планлаштырыла. 1-4 нче класслар өчен 5 вариантлы, 5-9 нчы класслар өчен 6 вариантлы укыту программасы эшләү күздә тотыла. Бу вариантларның кайберләрендә, мәсәлән, 1-4 нче класслар программаларының өченче вариантында «Туган тел» сәгатьләре бөтенләй күренми, 5-9 нчы класслар өчен программаларның беренче вариантында шулай ук «Туган тел» дәресләре өчен аерым сәгатьләр генә бүлеп бирелмәгән.

Туган телне һәм милли әдәбиятны укыту өчен яңа программаларда бик аз гына вакыт бирелүне дә күз буяу өчен генә дип карарга кирәктер: 1-3 нче классларда бу ике предметның икесенә бергә атнасына 2 сәгать, 4 нче класста исә – 1 сәгать планлаштырыла. 9 нчы класс укучыларына, туган телләрен һәм милли әдәбиятларын өйрәнү өчен, бары тик 1 сәгать бирү күздә тотыла.

Яңа федераль стандартларны игътибар белән өйрәнсәң, анда руслардан башка халыклар балаларының туган телләрен һәм милли әдәбиятларын өйрәнүен чикләү һәм бетерү өчен төрле уйдырмалар корылган булуын аңлыйсың. Шундыйларның берсе – туган телләр һәм милли әдәбиятлар укыту өчен вакытны тагын да киметүне яки бөтенләй бетерүне мәктәптәге санитария кагыйдәләренең (таләпләренең) (СанПин) үзгәрүенә сылтау. Санитария таләпләрен (нормаларын) үзгәртү, катгыйландыру ни өчен туган телләрне һәм әдәбиятларны укыту сәгатьләрен генә киметүгә китерергә тиеш? Бу бер. Икенчедән, ул СанПинны ни сәбәпле үзгәртергә кирәк булган, элеккесенең нәрсәсе ярамый башлаган?

Федераль мәгариф министрлыгы туган телләрне һәм әдбиятларны тагын да киметү яки бөтенләй бетерү өчен уйлап чыгарган тагын бер тозак ул – мәктәптә укуны атнасына биш көнгә калдыру нияте. Бу идеяне кем тәкъдим иткән һәм моның кирәге бармы икән?! Цивилизация заманы, фән-техника, яшәү рәвеше һәм шартлары катлаулана, һәртөрле мәгълүмат арта барганда, төптән уйланылмаган чаралар күреп, балаларның, яшьләрнең белемнәрен чикләү нигә кирәк? Хакимият артык демократик булып кылана башлады: имеш, ата-аналар теләгән исәпкә алырга кирәк. Уку атнасын кыскартырга күпме ата-ана тели икән һәм теләгәннәре бу яңалыкның укучыларның белемнәрен киметүгә китерәчәген уйлыйлар микән? Моңарчы күп дистәләрчә еллар совет һәм Россия мәгариф системасында, мәктәпләрдә ниндидә фәннәрне күпме вакыт һәм ни рәвешле укытасын ата-аналардан сорап, аларның теләгән исәпкә алып хәл итмәделәр бит. Туган тел һәм әдәбияттан башка предметларны, шул исәптән рус телен һәм әдәбиятын да, укытуда хәзер дә ата-аналар теләге белән эш итмиләр. Моның серенә төшенү кыен түгел: бу үзгәрешләр руслардан башка халыкларның телләрен өйрәтүне чикләүгә һәм хәтта туктатуга юнәлтелгән.

Соңгы елларда шушы максатны күздә тотып гамәлгә ашырыла башлаган тагын бер яңалык шуннан гыйбарәт: федераль мәгариф әһелләре «туган тел» дип атап, конкрет милли тел укыту белән бәррәттән, шул ук телне дәүләт теле статусындагы туган тел дип атап укыту тәртибен кертте. Бу башваткычның хикмәте шунда: туган тел дәүләт теле статусында булса, ул, укыту программасына кертелеп, расписаниегә куелып, һичшиксез өйрәтелергә тиеш, ә гадәти «туган тел» генә булса, аны укыту ата-аналар һәм мәктәп ихтыярында була. Мәсьәләне болай катлауландыру, дөресрәге, аңа буталчыклык кертүнең безнең республика өчен кирәге бармы икән? Татар теле ул – закон тарафыннан Татарстанның дәүләт теле, һәм ул республика мәктәпләренең программаларында һичшиксез булырга һәм укучыларга - татар мәктәпләрендә тиешле югары дәрәҗәдә күбрәк, рус мәктәпләрендә аралашырлык дәрәҗәдә азрак – өйрәтелергә тиеш.

Хәзер илдә, шул исәптән безнең республикада, сәяси хәл шундый: өстән ни кушсалар, шуны берсүзсез үтәп торыр чак түгел. Милли мәгарифебезнең роле, барыннан да бигрәк яшь буынга туган телебезне өйрәтү-укыту өчен мөмкинлекләр бетә баруын истә тотып, республиканың дәүләт органнары, җәмәгать, иҗат оешмалары, берләшеп, милли мәгариф беренче чиратта татар телен һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләрен хәл итү хокукын, элеккечә, Татарстан мәгариф министрлыгы карамагына тапшыруны катгый таләп итеп, Россия Президентына һәм парламентына мөрәҗәгать итсен. Бу мөрәҗәгатькә Дәүләт Думасындагы Татарстаннан сайланган депутатлар да кушылсын: алар безнең республика халкының мәнфәгатьләрен якларга тиеш. Шуны онытмыйк: Россиянең дә, Татарстанның да конституцияләре һәм республикабыз парламенты кабул иткән Татарстан халыклары телләре турындагы закон нигезендә татар халкының балаларны, яшьләрне тиешле дәрәҗәдә, кирәгенчә укытырга тулы хокукы бар. Законнар үтәлергә тиеш. Россиянең үсешенә һәм иминлегенә һәр елны триллионга якын суммалы финанс һәм игелекле хезмәт капиталы белән ясак түләп барган республика халкының балаларына мәктәпләрдә туган телен, әдәбиятын, тарихын үзе теләгәнчә укытырга хакы бардыр.

МӘҖ Җидеген вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Кытай киләчәкне кайгырта

16-22 октябрь көннәрендә Пекин каласында Кытай Коммунистлар партиясенең (ККП) XX съезды узды. Бөтен илдән 2,3 меңгә якын делегат катнашкан колачлы форумда партиянең соңгы 5 елда башкарган эшләренә йомгак ясалган, алдагы чорга «юл картасы» билгеләнгән, ККП уставына үзгәрешләр кертелгән һәм партия Үзәк комитетының (ҮК) яңа составы да сайланган. Анда шулай ук илнең алдагы үсеш юллары билгеләнгән һәм кешелек дөньясының да киләчәгенә кагылышлы карарлар вә мөһим документлар кабул ителгән. Искәртеп үтик, Кытай Халык Республикасы (КХР) 1949 елдан бүгенге көнгәчә чорда ККП җитәкчелегендә, эчке вә тышкы низаглардан бөлгенлеккә төшкән ярым колониаль хәлдәге илдән, дөньякүләм дәрәҗәдә беренче икътисадка һәм глобаль лидерлыкка дәгъва кыла торган илгә әверелә алды. Шуңа күрә әлеге съезд карарлары (ККП генераль секретаре Си Цзиньпиннең вәкаләтләрен озайтуны да кертеп), ил күләмендә генә түгел, халыкара дәрәҗәдә дә, бүгенге тенденцияләргә хәлиткеч йогынты ясау чаралары буларак кабул ителә. Сүз нинди карарлар турында бара соң?

Бу яктан, сәяси аналитиклар хисап докладында шәйләнгән өч юнәлешкә игътибар итә. Беренче юнәлеш Кытайның интеграциядә, товарны «күмәк Көнбатыш» базарларына экспортка чыгаруга корылган икътисад моделеннән баш тартып, «Бер пояс – бер юл» башлангычын киңәйтүгә булган эчке ихтыяҗны җәелдерү стратегиясенә күчүе белән бәйле. Бу исә дәүләт сәясәтендә, сүздә генә түгел, гамәлдә дә халык ихтыяҗлары өстенлеке булуын күрсәтә. Шул ук вакытта ул «доллар империясе»нә һәм АКШка эшли торган глобаль базарга каршы көрәш башлануын да аңлата. Икенче юнәлеш – «кытай милләтен зурдан торгызу» программасына «яңа үсеш моделе» һәм «кешелек цивилизациясенең яңа формасы» турындагы тезислар өстәлүе, ягъни кешелек дөньясына аны җәлеп итәрлек һәм кулланырлык та цивилизация моделе тәкъдим ителүе. Ә андый модельнең заманча югары технологияләр нигезендә тәкъдим ителүе һәм аларны комплекслы куллану вә үстерүдә бүген Кытайның дөнья лидеры булырга җыенуы инде юнәлешләрнең өченчесе була. Ул Си Цзиньпиннең рәсми төстә «яңа шартларда кытайча үзгәлекле социализм» дип йөртелә торган курсы өчен дә мөһим юнәлеш булып тора. Докладта шулай ук Кытайның алдагы чорда тышкы сәясәттә ачыклык дәрәҗәсен арттырырга һәм дөньяда яңа типтагы халыкара мөнәсәбәтләр урнаштырырга омтылуы турында да әйтелә. Тайвань мәсьәләсенә килгәндә, аны тышкы көчләрдән башка гына, тыныч юл белән хәл итү күздә тотыла. Кораллы көчләрне модернизацияләү исә 2027 елга кадәр тәгәлләнергә тиеш.

Сәяси күзәтүчеләр, Кытайда мондый форумнарда бара торган процессларның асылын аңлау өчен, анда әйтелгән һәр сүз һәм ясалган һәр ымны аерым шәрехләү кирәклеген дә искәртә. Бу җәһәттән игътибарны съезд тәгәлләнер алдыннан залда дөньяга күрсәтеп кылынган бер сәер хәл дә җәлеп итә. КХРның элеккеге җитәкчесе Ху Цзиньтаоны (сәяси даирәләрдә ул АКШ тарафдары санала) ниндидер ике ир кеше, залда Си Цзиньпин янында утырган почетлы урыныннан торгызып, култыклап алып чыгып китте. Рәсми даирәләр соңыннан моны өлкән яшьтәге түрәнең үзен начар хис итүе белән аңлатты. Әмма аның залдан чыгарга теләмәве дә сизелде. Мондый хәлне сәяси күзәтүчеләр элеккеге җитәкченең, гамәли яктан гына түгел, ишарә дәрәҗәсендә дә сәясәттән читләштерелүен күрсәтү алымы буларак бәяләде. Димәк, Кытайда үткән әлеге съезд нәтиҗәләре сәяси яктан, әйтик, Тайвань, АКШ, ЕС һәм Украина өчен отышсыз, ә Россия өчен отышлы булып чыга. Әмма сепаратизмга карата мөнәсәбәттә Кытай белән Россиянең, Тайвань һәм Украинадагы хәлләр аша, капма-каршы позицияләрдә торуын да онытмыйк. Икенче яктан, бүгенге җәһил чорда сәясәтнең бик тиз үзгәрүчән булуы да хак. Шуны истә тотып, бу форумда делегатлар ККП уставына кертелә торган үзгәрешләрне хуплаган резолюция дә кабул иткән. Алар Тайваньнең бәйсезлек игълан итүенә каршы торуга һәм КХР армиясен дөньяда иң көчлеләрнең берсе итеп модернизацияләүгә кагыла.

Съезд тәмамлануның икенче көнендә исә, гадәттәгечә, ККП ҮК пленумы үткәрелгән. ККП уставына әлегрәк кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Си Цзиньпин анда өченче мәртәбә ККП генераль секретаре һәм ККП ҮК Хәрби шурасы рәисе итеп сайланган. Пленумда шулай ук ККП ҮК Политбюросының 8 кешедән торган Даими комитеты да яңартылган. Ә XX съезд карарларын Халык вәкилләренең 2023 елның мартында узачак Бөтенкытай җыены хуплагач, Си Цзиньпин анда инде КХР рәисе итеп тә сайланачак. Кайбер сәяси аналитиклар әйтүенчә, Конституциягә кертелгән үзгәрешләр һәм дөньяда саклана торган гаять катлаулы вәзгыять Кытай лидерына әле 2033 елга кадәр дә югары вазифаларда калу мөмкинлеге бирәчәк.

Фоат УРАЗАЙ.

Илһамлы «Татар моңы»

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында «Татар моңы» Халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсы гала-концерты үтте. Быел ул беренче тапкыр Илһам Шакиров исеме белән узды. Концертта бәйгенең лауреатларын һәм җиңүчеләрен бүләкләделәр.

«Татар моңы»ның дүрт номинация буенча җиңүчеләре акчалата бүләкләргә, дипломнарга ия булды. «Халык җыры» номинациясендә Алинә Гыйльметдинова, «Инструменталь башкаручы»да – Алмаз Ахунов, «Эстрада вокалы» номинациясендә Вилнур Әдилов белән Гөлназ Муллаәхмәтова, «Академик вокал» номинациясендә Диләрә Төхфәтуллина белән Илгиз Мөхетдинов җиңүчеләр дип табылды.

Җиңүчеләргә бүләкләрне «Татар моңы» конкурсының жюри рәисе, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов тапшырды.

«Тыйнак итеп җырлый белү һәм күренә белү Илһам абыйның да теләге иде. Бәйгенең киләчәге булыр дип уйлыйм. Илһам абыйның исеме белән бәйле булгач, аның дәрәҗәсе Тукай премиясеннән дә ким булмаска тиеш», – диде ул үз чыгышында.

Гала-концерт бәйгедә җиңүчеләрнең бергәләп «Татар моңы» конкурсының гимнын башкаруы белән тәмамланды. Бу кичне Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры чыгышы да бизәде.

Сүз уңаеннан, «Академик вокал» номинациясе җиңүчесе, Татарстанның халык артистлары Рамил һәм Илсөя Төхфәтуллиннарның кызы Диләрә Төхфәтуллина тиздән Италиянең опера театрында эшли башларга тиеш.

Яшьләр активлык күрсәтә

Казанда III «Яшьләр.Мәдәният. Менеджмент» республика форумы узды. «Идел» яшьләр үзәгендә башланып киткән җыенда Татарстанның 30 дан артык районыннан мәдәният учреждениеләрендә эшләүчеләр яки үз мәдәни проектларын тормышка ашыручылар, шулай ук республиканың профильле иректе ярдәмчеләр берләшмәләре әгъзалары катнашты.

Йомгаклау көнендә проектларны тәкъдим итү чарасында илнең алдынгы мәдәният учреждениеләреннән федераль экспертлар, Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова, Мәскәү шәһәренең «ЗИЛ мәдәни үзәге» директоры Мария Рогачева һ.б. катнашты.

Форумда тәкъдим ителгән кызыклы проектларның берсе – «Календарьның кызыл көне» дип атала. Ул бердәм календарь булдыру юлы белән Татарстанның Идел арьягы зонасы халыкларының традицион бәйрәмнәрен торгызуны күздә тота.

Форумда «Син һәм мин» дип исемләнгән урам фестивальләре проекты аерым билгеләп үтелде. Ул авыру-гариплек аркасында мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне сәламәт кешеләр белән берләштерә торган иҗади шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Тагын бер мөһим проектта волонтерларны күптән борчыган мәсьәлә – аларга бергә җыелу, бергәләп эшләү өчен даими урын булмавына игътибар ителә. «Волонтерлык ноктасы» проектын оештыручылар волонтерлар өчен шундый махсус урыннар булдырырга кирәк дип саный. Юлия Әдһәмова Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы исеменнән әлеге проектны районнарда гамәлгә ашыра башларга тәкъдим итте.

Фестивальләр кызган чак

Г. Кариев театры Санкт-Петербург шәһәрендә Халыкара «Волшебный фонарик» фестивалендә катнашты. Казанлылар анда «Бәхетле көнем» спектаклен күрсәтте. Фестиваль нәтиҗәләре буенча, спектакль «Иң яхшы актерлар ансамбле» буларак, диплом белән бүләкләнде.

Пермь өлкәсенең Кудымкар шәһәрендә «Сообщение» IV милләтара театр фестивале узды. Әлмәт театрының «Җил артыннан» спектакле аның Гран-прием яулады. Театраль җыенда Уфа «Нур» татар дәүләт театры да катнашты. Зифа Кадыйрованың «Фатыйма» спектаклендә төп рольне башкаручы Чулпан Раянова «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңүче дип табылды.

Чиләбе өлкәсе курчак театры сәхнәсендә «Әкият» курчак театры «Адәмнәр» спектаклен күрсәтте. Әлеге тамаша «Соломенный жаворонок» өлкәннәр өчен курчак спектакльләре халыкара фестивале кысаларында тәкъдим ителде.

1-7 ноябрьдә Түбән Кама театры Үзәк Азия илләренең VIII Халыкара фестивалендә катнашачак. Чара язучы һәм драматург, җәмәгать эшлеклесе Мохтар Ауэзовның 125 еллыгына багышлана. Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Азәрбайҗан вәкилләре чыгыш ясаячак фестивальдә татарстанлылар «Таң вакыты» спектаклен (режиссеры Туфан Иматдинов) уйнарга ниятли.

1 нче биттә: Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында Казанның «Салават Күпере» микрорайонында яңа парк ачу тантанасыннан күренеш. Фото: president.tatarstan.ru

Шагыйрьнең туган ягында

Түбән Кама районы Ташлык авылында язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең юбилей кичәсе булды.

«Гомерем гел сораулардан тора, күбесенә җавап бетереп тә булмый. Үз-үземә: «Киләчәктә нәрсә эшләргә җыенасың?» – дигән сорау бирер идем. Күп кешеләргә булышуым турында әйттеләр. Әгәр авыл халкы, республика җитәкчеләре булмаса, бу эшнең берсен дә башкарып чыгып булмас иде. Авылыбыз шулкадәр матур. Бер генә теләгем – авыл балалары туган телләрендә сөйләшсен, телебезне онытмасын иде», – диде кичәдә Разил Вәлиев.

Чарада шагыйрьнең дуслары, якыннары, хезмәттәшләре, авылдашлары катнашты. Кунаклар арасында шагыйрьнең классташы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Алмаз Хәмзин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев һ.б. бар.

Шагыйрьнең якташлары аның шигырьләрен, җырларын башкарды.

Түбән Каманың «Адымнар» күптелле белем бирү комплексында Разил Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау кичәсе булды. Бәйге быел 24нче тапкыр үткәрелде.

Район Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы Айдар Гарифуллин әйтүенчә, бәйгедә 24 ел дәверендә барлыгы 1325 бала катнашкан. «Чараның быел гына ишекләрен ачкан «Адымнар» мәктәбендә үтүе аеруча мөһим. Разил абый күп еллар дәвамында хезмәте белән башкаларга үрнәк булды. Үзе салган язучылык юлында балаларны тәрбияләүдә куйган хезмәтенең дә җиңүчеләрен күрү – зур шатлык», – диде ул котлавында.

Соңгы ике елда яшь язучылар бәйгесендә катнашкан укучылар арасыннан 31 укучының эше иң яхшы, тирән эчтәлекле дип табылып, икенче турга узган. Җиңүчеләрне билгеләүдә «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзалары да катнашкан.

Яшь каләм тибрәтүчеләрне бәйрәмнең хуҗасы Р.Вәлиев тәбрикләде. «Бу һәммәбез өчен зур бәйрәм. Милләтебез, шигъриятебез, әдәбиятыбыз, халкыбыз, республикабызның язмышы сезнең нинди булып тәрбияләнүегезгә бәйле. Бәйге 1999 елда оештырылды. Мин беренче тапкыр шул елны Татарстан Дәүләт Советына депутат булып сайландым, шунда мин халык алдында мәдәният, мәгариф өлкәсендә эшләргә тырышачакмын, мәктәпләр һәрвакыт игътибар үзәгендә булырга тиеш дип, шушы бәйгене игълан итеп, аны алып барырга вәгъдә биргән идем, – диде ул. – Җиңүчеләр бик күп, әмма бәйгедә катнашкан һәр укучы – җиңүче. Әгәр дә кулына каләм алып иҗат итәргә, кәгазьгә хисләрен төшерергә көч, кыюлык тапкан икән, ул, чыннан да, батыр кеше».

«Адымнар» белем бирү комплексында Разил Вәлиев мәктәп укучылары белән очрашу да уздырды. Язучы балаларның сорауларына җавап бирде.

«Синең шигырең укучыларга барып җитсә, шуннан да зуррак куаныч юк. Никадәр яхшы язсаң да, әгәр ул укучылар күңеленә барып җитми икән, ул зур куаныч түгел. Иң яраткан шагыйрем Һади Такташ булды. Вакыт машинасы булса, мин аның белән янәшә утырып, серләр бөлешсәм, гаплашсам килер иде», – диде ул.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Кол Галиләр, Тукайлар белән яшәде

Озакка сузылган авырудан соң әдәбият галиме, шагыйрь, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе, «Мәдәни җомга» газетасының авторы, актив укучысы Нурмөхәммәт Хисамов вафат булды.

Ул 1937 елның 24 мартында Татарстанның Чүпрәле районында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Мунчәли авылында җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, Яшел Үзәндә белем ала, Иске Чүпрәле авылының мәктәбендә унынчы сыйныфын тәмамлый. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында югары белем ала. Әүвәл «Коммунар» редакциясендә хатлар бүлеге мөдире булып эшли, аннары соң Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада укый. 1969 елга кадәр Казанда «Җиңү байрагы» исемле күп тиражлы газета мөхәррире вазыйфаларын башкара. 1969 елда Хисамов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына фәнни хезмәткәр булып кабул ителә.

1980 елның апрелендә ул Мәскәүдә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына багышланган фәнни хезмәте буенча кандидатлык диссертациясен яклый. Гомумән, Кол Гали иҗатын өйрәнүгә аеруча күп көч куя.

1965 елда аның бер төркем шигырьләре «Дуслык» исемле күмәк җыентыкка кертелә, ә 1967 елда «Яз миңа чәчәкләр китерә» дигән мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә. Н.Хисамов – 1984 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, Халыкара төрки академиянең хакыйкый әгъзасы Н.Хисамов әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә эшли. Аның Габдулла Тукай, Дәрдемәнд һәм күп башка шагыйрьләр иҗатына багышланган әдәби тәнкыйть мәкаләләре бар.



● World Population Prospects мәгълүматлары буенча, Россиядә 1990 елларда халык саны якынча 1 миллионга кимегән, шулай да ул халык саны буенча дөньяда 6 нчы урында булган әле. Аннан соңгы ике дистә елда Россия тагын 2 миллион кешесен югалткан һәм җиһанда 9 нчы урынга төшкән. 2050 елга кадәр исә 12 миллион россияле бакыйлыкка күчәчәк һәм ил дөньяда 14 нче урында гына булачак.

● Ирләр саны буенча исә Россия Зимбабведан да калыша (анда 100 хатын-кызга 89 ир-ат, Россиядә исә 87 генә туры килә), бу Гваделупа, Мартиника кебек дәүләтләр дәрәҗәсендә. Гадәттә ирләрне сугышлар һәлак итә. Бөек Ватан сугышыннан соң СССР-да 100 хатын-кызга 77 ир-ат туры килгән. 2050 елда нисбәтнең ничек буласын исә хәзер беркем фаразларга да алынмый.

Сәүдә үзәгендә – намаз бүлмәсе

Мөселман кешесе өчен намазны вакытында укып бару бик әһәмиятле. Моның өчен республикабызда тиешле шартлар тудырыла башлады. Шушы юлда чираттагы мисал: Казанның ЦУМ сәүдә үзәгендә намаз бүлмәсе ачылды. Ул Татарстан башкаласының сәүдә үзәкләрендә РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тарафыннан оештырылган унынчы бүлмә.

Тантаналы чара мәртәбәле кунаклар катнашында узды: бирегә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР Президенты каршында эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев, ТР Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина, сәүдә үзәгенең генераль директоры Илдар Гафаров килде.

Намаз бүлмәсе цоколь катында урнашкан. Монда киләчәктә мөселман сәүдә рәтләре ачу планлаштырыла. Бүлмәне үзәк ишекләрдән кереп эскалатордан төшеп табарга була. Ул Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең стандарт дизайны буенча һәм мөселманнарның тәкъдимнәрен истә тотып эшләнгән. Бүлмә ике өлешкә: ирләр һәм хатын-кызларныкына бүленгән, һәр өлешнең үз тәһарәтханәсе бар. Гомуми мәйданы – 36,5 кв.м.

ЦУМдагы намаз уку бүлмәсе Мөселман эшмәкәрләренең зур проекты кысаларында тормышка ашырылды. Әлеге башлангычны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2020 елның ноябрендә Сәүдә-сәнәгать палатасында эшмәкәрләр белән очрашу вакытында хуплаган иде. РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе аны тормышка ашыру бурычын башланган алып ахырына кадәр үз өстенә ала: бүлмәне үз хисабына ремонтлау, аны карап тору, аренда өчен түләү, чисталыкта тоту һ.б. Намаз бүлмәләре атна саен тикшерелеп тора.

Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Т.Миңнуллина республикада Halal LifeStyle (хәләл тормыш рәвеше) концепциясен тормышка ашыру барышы белән таныштырды.

Хәзерге көндә Казанда «Горки-Парк», «KazanMall», «Караван», «Мега», «Порт», «Suvar Plaza», «Тандем», «ЦУМ» сәүдә үзәкләрендә, Республика балалар клиник хастаханәсендә, Түбән Камада «Ramus Mall» сәүдә үзәгендә намаз уку бүлмәләре эшли.

Эльмира СИРАҖИ.

Шигырьләре белән тәрбияләде

Узган атнада татар җәмәгатьчелеге тагын бер югалту кичерде – күренекле шагыйрә Резеда Вәлиева вафат булды.

Резеда Тәфкаләун кызы Вәлиева 1930 елның 1 маенда Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәнбикә авылында укытучылар гаиләсендә туа. 1947 елда Салават районы Каратаулы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Аннары утыз елдан артык Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли.

Нәниләр турында язган беренче шигырьләре республика көндәлек матбугатында узган гасырның илленче елларында күренә башлый, тәүге җыентыгы («Минем дусларым») 1960 елда басылып чыга. Шуннан бирле, 1960–2005 еллар арасында, балалар өчен аның тезмә һәм чәчмә әсәрләре – шигырьләре, поэмалары, җырлары, шигъри әкиятләре, табышмаклары, сәхнә өчен язылган әсәрләре һәм хикәяләре тупланган тагын ике дистәдән артык мөстәкыйль китабы дөнья күрә.

Резеда Вәлиева – татар балалар әдәбиятын Н.Верзилин, Н.Попов, А.Барто, Л.Воронкова һ.б.ның әсәрләреннән тәрҗемәләр белән дә баеткан каләм ияләренең берсе. 1983 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Казакбаевча «РОМЕО һәм ДЖУЛЬЕТТА»

Шекспирның «Ромео һәм Джульетта»сын белмәгән кеше юк, шуңа күрә бу әсәр буенча спектакль куеп тамашачыны әллә ни шаккатырып булмый кебек. Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры режиссеры, Ш.Бабич премиясе иясе Илсур Казакбаев, бу фикерне инкяр итеп, яшьләр өчен шаккатмалы спектакль сәхнәләштерде.

Тамашаның уңышы Санкт-Петербургтан Сергей Кретенчукның затлылык чалымнары сакланган заманча сәхнә киемнәрендәме, әллә яшьләр арасында танылган GAUGA төркеменең катнашуындамы һәм Уфадан Магуля Мезинованың музыкаль бизәлешендәме, әллә Уфадан хореограф Ольга Даукаева геройларның күңел халәтләрен хәрәкәтләр аша күрсәтергә теләп иҗат иткән пластикадамы, сәхнәдә өстенлек иткән һәм замана яшьләренең күңеленә бик хуш килгән кара төсләмә, дигән сорауга бер төрле генә җавап бирүе кыен. Режиссер Илсур Казакбаевның боларны һәммәсен урынлы һәм чамасын белеп куллана, берләштерә белүендәдер, мөгаен. Илсурның классиканы хәзерге заман тамашачысына кызыклы итеп куя белүе соклану уята. М.Гафури театрында ул Мостай Кәримнең «Кыз урлау» әсәренә яңа сулыш өргән иде. Күптән түгел Әтнә театрында Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход» әсәре буенча үзенчәлекле җыйнак спектакль иҗат итте. Кариев театрында аның куелышында Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» тамашасы бара. Болар – Казакбаев сәхнәләштергән һәм телгә килгән берничә әсәр генә. Кайсын гына алсаң да, режиссердан кыюлык, тәвәккәллек, милли хис сорый торган әсәрләр. Яшь кенә булуына карамастан, Илсурның киң колачы әсәрләр сайлауда һәм һәр башлаган эшен әзлекле итеп ахырына җиткерә белүендә яхшы күренә.

Хәзерге заман яшьләрен театрга нәрсә белән җәлеп итеп була? Аларга аңлашылган сәхнә теле белән, әлбәттә. Бу җәһәттән Казакбаевның «Ромео һәм Джульетта»сы – бер дигән спектакль. Режиссер һәрвакыттагыча текстка бик сакчыл караган (тәрҗемәчеләр һәм сәхнә өчен әзерләүчеләр Илдус Әхмәтҗанов һәм Резидә Гобәева). Актерларның мөмкинлекләрен чамалап рольләр бүлүе дә хәл иткеч роль уйнаган. Биредә Ромеоны Кариев театрының күп спектакльләрендә баш геройларны гәүдәләндерүче бәхетле артист Булат Гатауллин башкара. Джульетта ролен Булат кебек үк дөньяга, беренче күргәндәй, зур күзләре белән сокланып карый белүче Рузанна Хәбибуллина һәм студент кыз Алия Фәйзиева алмашып уйный. Меркуцио – Рамил Вафин һәм Бенволио – Муса Камалов дуэты вакыйгаларга шуклык-шаянлык өстәп, спектакльне җанландырып җибәрә. Монтеккилар – Илнар Низамиев белән Альбина Гайзуллина һәм Капулеттилар – Фәнис Кәлимуллин белән Диләрә Зиннәтова әллә нинди кәттә гламур журнал битләреннән «чыккан» сыман. Лоренцо – Фернат Насыйбуллин шигырьгә корылган тәрҗемә тексны җиренә җиткереп бирә белүе белән күңелдә рәхмәт хисләре уятты. Тулаем алганда исә, спектакльдә текстка, сөйләмгә актерларның, бигрәк тә яшьләрнең игътибары җитенкерәмәде.

Шунысы кызык, «Ромео һәм Джульетта» стиле белән шушы ук театрда куелган «Алтынч[ае]ч»кә бик охшаган. Әмма беренчесендә, бәян ителгән трагедиягә дә карамастан, якты рух тоемланса, ул бербөтен булып күз алдына килсә, икенчесе ахыр максаты аңлашылмаган, шаккатыруга корылган буш булуы белән гайрәтне чигергән иде. Яшьләр өчен яшьләрчә куелган һәр нәрсә дә начар түгел икән бит. Бөтен нәрсә режиссерның талантыннан тора, димәк.

Мостай Кәрим – экранда

Казанның М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында гомердә булмаганча кино күрсәтteләр. 2019 елда мәшһүр шагыйрь Мостай Кәримнең 100 еллыгына багышлап режиссер Сәйдә Медведева төшергән документаль фильм иде ул. Кинофильмда шагыйрьне ил күләмендә бөек шәхес итеп күрсәтү нияте сизелә. Моның өчен байтак танылган шәхесләрдән әңгәмәләр алганнар. Никита Михалков, Иосиф Кобзон, Михаил Швыдкой, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, шагыйрь Ринат Харис та алар арасында. Моннан тыш танылган актерлар Рэйф Файнс, Сергей Безруков, Алсу Сафина, Полина Агуреева, дирижер Владимир Спиваков М.Кәримнең шигырьләрен һәм көндәлекләреннән өзекләр укый.

Шагыйрьнең тормыш хәлен бәян итү максат итеп куелмаса да, аның Бөек Ватан сугышы кырында каты яраланып, үлемнән калуы, катлаулы операция кичерүе искәртелә. Шагыйрьләр Константин Симонов, Александр Твардовский белән дуслыгы, аеруча Рәсүл Гамзатов, Касыйн Күлиев, Давид Кугультинов һәм М.Кәрим арасында гомер-гомергә булган җылы мөнәсәбәтләргә, иптәшлеккә басым ясала. Авторлар шагыйрьне зурлау максатына ирешкән. Әмма экранда җылылык, шагыйрьне шагыйрь иткән туган як күренешләре, җыр, моң җитенкерәмәде. Мостай Кәримне татар-башкортның бөек улы буларак түгел, Россия шагыйре итеп тәкъдим иттеләр.

Фойеда сирәк фотосурәтләрдән күргәзмә оештырганнар. Фотоларны игътибар белән тамаша кылучылар арасында кемнәр генә юк – Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов, Президент аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан мэры Илсур Метшин, республикабызның Мәгариф һәм фән министры Илсур Хадиуллин, Яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов, күренекле шагыйрь, рәссам, актер, композиторлар.

Фильм Мәскәүдә, Уфада һәм федераль телеканалларда күрсәтелгән, Казанда исә пандемия аркасында булмый калган. Казан презентациясен М.Кәрим исемендәге фонд оештырган. Шагыйрьнең оныгы, эре эшмәкәр, «Русская медная компания» ЯАҖнең директорлар советы әгъзасы, Плес шәһәре хакимияте башлыгы Тимербулат Кәримов – әлеге фондның попечителе. Тимербулат тантанага әнисе Әлфия Кәримова, хатыны – «Роснефть» башлыгы Игорь Сечинның кызы Инга һәм нәни улы белән килгән. Зур дәрәҗәле кунакларны М.Кәрим һәм аның иҗаты җыйганны, әллә бизнесс дөньясында абруй казанган оныгы җәлеп иткәнме – һич аерырлык түгел иде.

● Тимербулат Кәримов улы белән.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Югалган алтын серлəре

Бу көннəрдə тарихчы Равил Ибраһимовның «Россиянең алтын запасы сере, яки «Казан» Колчак алтыны тарихы» китабы дөнья күрде. Автор, тарихи документларга таянып, гражданнар сугышында Казан банкыннан алтын югалу вакыйгаларын торгыза.

Татарстан китап нəшрияты «Ногай» кунакханəсендə китап авторы Равил Ибраһимов белəн очрашу үткəрде. Чарага тарихчылар һəм журналистлар чакырылган иде. Автор китап белəн таныштырып кына калмыйча, гражданнар сугышы вакытында Казан банкыннан 400 пот (якынча 6,5 тонна) алтын югалу һəм аны эзлəү тарихын сөйлəде.

Гражданнар сугышының иң кызыклы эпизодларының берсе – Россиянең Казанда сакланган зур алтын запасын ак гвардиячелəр тарафыннан Себергə күчерү була. 1918 елда Комуч (Бөтенроссия Учредительное собраниесе əгъзалары комитеты) гаскəре алтынны пароходларга төягəндə, 400 пот (якынча 6,5 тонна) алтын Казанда юкка чыга (Россия империясенең барлык алтын запасы 1 мең тоннадан артык булган).

Равил Ибраһимов, тарихи документларга, шул чорда яшəгəн кешелəрнең сөйлəп калдырган истəлеклəренə нигезлəнеп, алтын урлау схемасын һəм маршрутын сурəтли. Ул шулай ук алтынның яшерелгəн урынын фаразлый. Тик кыйммəтле металл бүгенге көнгə кадəр табылмаган.

Советлар Союзы оешкач, югалган алтынны эзлəү эшенə «Алтын руно» дигəн исем бирелə. Хəзерге көндə бу эшнең материаллары МВД архивында Дəүлəт сере буларак саклана. Ул барлыгы 1200 биттəн торган 6 томга тупланган. Документларның бер өлеше – эзлəнүлəр барган урыннарның карталары. Тикшерү башланганга 90 ел вакыт узса да, документлар дəүлəт сере статусына ия. Яшерен материаллар тарихчыларга бирелми, – дип сөйлəде Равил Ибраһимов.

Дəүлəт сере булгач, тарихчыга мəгълүмат каян килгəн, дигəн сорау туа. Əлеге сорауны авторның үзенə бирдем.

– Мəскəүгə барып, зур җитəкчелəр белəн очраштым. Алар миңа бу эшнең кайбер материаллары белəн танышырга мөмкинлек бирде. Əлбəттə, мин бөтен мəгълүматны да күрмəдем. Үз чиратында, алар минем бу турыда нəрсə белүем белəн кызыксындылар. Ə минем гомеремнең бер өлеше Америкада узды. Миңа Колчак армиясендə хезмəт итеп, соңрак эмиграциягə киткəн офицерлар белəн очрашырга насыйп булды. Алар 80 яшьтəн узганнар иде инде. Хəзер исəн түгеллəрдер. Минем Казанда туып-үскəнемне белгəч, алар миңа югалган алтын турында сөйлəделəр. Китапта ул кешелəр турында мəгълүмат бар. Сан-Франциско архивында Беренче Бөтендөнья сугышы ветераннары музее бар. Мин аннан да берникадəр мəгълүмат җыйдым, – диде тарихчы.

«Россиянең алтын запасы сере, яки «Казан» Колчак алтыны тарихы» – авторның күпьеллык эзлəнүлəр нəтиҗəсе. Материаллар 25 елга якын тупланган.

Россиянең төрле төбəклəрендə сакланган алтын ни сəбəпле Казанга килеп элəккəн? Ак гвардиячелəр ничек итеп аны Казаннан алып чыккан? Китапта əлеге сер пəрдəсе белəн капланган вакыйгалар сурəтлəнə.

Яңа китап белəн берникадəр танышып, кызыклы урынныларының эчтəлеген укучылар игътибарына җиткерəм.

1914 елның 1 сентябрендə Россия империясе Дəүлəт банкының Казан бүлекчəсе Проломная (хəзерге Бауман) урамындагы яңа бинага күчə. Бу – Беренче бөтендөнья сугышы башланган чорга туры килə. Черек күл янында урнашкан иске бина зур акчалар саклау өчен бик уңышлы булмый, чөнки күршедə сырахanə, трактир һəм начар гына кунакханə һəрвакыт шик уятып тора. Банкның яңа урыны һəм бинасы бөтен куркынычсызлык талəплəренə җавап бирə. Дəүлəт банкы комиссиясе: «Казан бүлекчəсе алтын саклау өчен бик кулай. Шəһəр халкы ышанычлы, бина яңа. Алтын саклау урыны иң камиле дип табылды. Анда тəрəзəлəр дə, ишеклəр дə юк», – дип теркəп куя. Ул елларда банкның Казан бүлекчəсе бинасы илдə иң заманчасы һəм иң куркынычсызы булып исəплəнə. Шуңа күрə, Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Россия хөкүмəте дəүлəтнең алтын запасын Казанга күчерергə карар кыла.

Беренче алтын партиясе 1915 елның 19 июнендə Петроградтан килə. 1915 елдан 1918 елга кадəр Себер банкының бөтен бүлекчəлəре һəм Казанга якын башка бүлекчəлəр акча запасларын һəм җыелып барган акчаларны ай саен Казанга озата. Петроградның Акча сараеннан да кыйммəтле əйберлəр Казанга эвакуациялəнə. 1918 елда дошман Мəскəүгə таба килə башлагач, Казанга Мəскəү, Орел, Тамбов байлыклары да эвакуациялəнə.

1918 елның июль азагында, аклар армиясе Сембер (хəзерге Ульяновск) шəһəрен алып, Казанга таба юл тота. Дəүлəт банкының Казан бүлекчəсе башлыгы Петр Марьин Дəүлəт банкы комиссары Тихон Поповка алтынны ышанычлырак урынга күчерү тəкъдиме белəн телеграмма җибəрə. Моңа Тихон Попов белəн Владимир Лениннан җавап килə. Алар, бөтен акчаны банк ишегалдына күмеп, яки алтын саклана торган урынны цемент белəн катырып кую мөмкинлеге юкмы, дип кызыксына. Петр Марьин бу эшнең файдасы булмаячагын җиткерə. Ул: «Дошман Казанны алган очракта, андый чаралар белəн генə байлыкны саклап булмаячак, чөнки җəй буе китерелгəн байлык күп очракта төннəрен ташылса да, шəһəр халкыннан сер булып кала алмады», – дип хəбəр сала.

Шуннан соң Казанга Түбəн Новгородтан ике флотилия һəм берничə баржа килə. Эшчелəр туплаганчы, алтын күчерү җайланмаларын барлаганчы, фронт җитəкчелеге һəм трамвай идарəсе белəн килештергəнче, берничə көн вакыт уза. Алтынны ташырга керешер алдыннан, фронт командующие Вацетис, язмача боерык белəн, эшне туктатып торырга боера. Вацетисның комиссарлар белəн ике көн дəвамында барган сөйлəшүлəреннəн соң, алтынны чыгару мəсьəлəсе хəл ителə. Хəзинə ишеклəрен ачарга керешкəч кенə, шəһəр янында пушка тавышлары ишетелə башлый. Шəһəргə аклар кергəн була инде. Флотилия, алтынны көтмичə, китеп бара.

Башка чара калмагач, 5 машинага 12 млн сумлык 200 əрҗə алтын төяп, Арчага таба җибəрəлəр. Алтынны Сембер финанс комиссары С.И. Измайлов озата бара. Соңыннан акчаны Арчадан Мəскəүгə юллыйлар.

6-7 августта Казанны аклар ала һəм хакимият 34 көнгə аклар кулына кала. Яңа хакимият Казанның алтын запасын, 5 пароходка һəм 1 баржага төяп, Казан-Самара-Уфа-Чилəбе-Омск маршруты белəн озата. Барлыгы 8399 əрҗə, 2468 капчык, 18 сумка – алтын, 900 əрҗə көмеш чыгарыла. Аларда 14 илнең алтын тəңкəлəре була. Элек Проломная урамыннан трамвайлар йөргəн. Бу акчалар, аклар армиясе полковнигы Владимир Каппель җитəкчелегендə, 20 көн һəм төн буе трамвай белəн пароходларга ташыла.

Казанның хəрби коменданты Владимир Лебедев 1918 елның 28 августында 657 млн сумга (ул вакыттагы акча белəн исəплəнə) тиң алтын җибəрелүе турында бөтен Россиягə телефонограмма җибəрə.

«Бөтен байлык талаучылар һəм хыянəтчелəр кулыннан Учредительное собраниегə күчте, һəм Россия үз байлыгының бөтенлеге өчен тыныч була ала», – дип яза Владимир Лебедев.

Август азагында хəзерге Кама Тамагы тирəсенə Петроградтан кызылларның «Межень» пароходы килеп җитə. Су юлы белəн алтын күчерүне дəвам итеп булмый башлый. Ак армия командованиесе, калган алтынны большевикларга бирмəс өчен, Казан артында күмеп куярга карар кыла. Алтынны ат арбаларына төяп, Арчага таба юл тоталар һəм Собакина (хəзерге Калинино) авылын узгач, урман эчендəге чокырга күмеп куялар. Алтын конвое урманнан чыгуга, кызыллар белəн бəрелешə. Сугышта акларның бөтенесе диярлек һəлак була, очраклы рəвештə генə бер поляк – Константин Ветеско исəн кала. Туган ягына кайткач, үлəр алдыннан, ул алтын күмелгəн урынның билгелəрен һəм җирлекнең планын бертуганы Вячеслав Ветескога сызып калдыра.

Еллар узгач, Вячеслав Ветеско дуслары аша Франция банкы белəн элемтəгə керə. 1929 елда Франция, Бөекбритания һəм Польша алтын эзлəүчелəре, СССР хакимияте вəкиллəре белəн берлектə, алтын күмелгəн урынны эзлəүгə керешə. Хəзинə табылмый. Төрле елларда бу омтылыш кабатлана, тик файдасы булмый.

Себергə озатылган алтыннар, 1920 елның февралендə Иркутск шəһəрендə адмирал Колчак атып үтерелгəннəн соң, Казанга кире кайтарыла, тик аның бер өлеше кимегəн була. Озакламый алтын запасы Казаннан Мəскəүгə озатыла.

Рифат КАЮМОВ.



Россиянең алтын запасы. 1918 ел.

Очарга беркайчан соң түгел, Булмаса җаныңда богаулар...

Лилия ФӘТТАХОВА

БУ – МИНЕМ КҮҢЕЛ ДӨНЬЯМ

Иңләсәң иңлә, буйласаң буйла,
Бу – минем күңел дөньям.
Бәлки, тарракты́р,
Бәлки, киңрәктер
Ул синең уйдан...
Бу – минем күңел дөньям.

Тыйнак кунак бул, явызлык кылма.
Бу – минем күңел дөньям.
Минем канунның
Бер маддәсен дә
Бозарга кыйма...
Бу – минем күңел дөньям.

Хәер, үзгәрт син...
Үзгәрт яхшыга.
Ансыннан тыймам.
Әгәр дә тойсаң
Вакыт сулышын –
Минем дөньямны
Тарсына торган...

СИЗӘСЕҢМЕ, ИРКӘМ?

Япь-яшь айны
якты сагышыма
урадым да
бәллү-бәллү итәм...
Яратуым сыман нарасый ул.
Син күрдеңме, иркәм?

Төпсез галәм
йөрәк тибешемне
ишетте дә тынды...
Сөенчегә –
йолдыз белән чиккән
кулъяулыгын сонды...

Юк ла инде,
бәхетемнән генә
күз яшемне сөртәм...
Тулган айдай йөзем.
Багам күккә...
Сизәсеңме, иркәм?

ӘНИ ДОГАСЫНЫҢ ЫШЫГЫНДА

Без дә бүген
Әни янына дип
Ашыга-ашыга
кайткан булыр идек...
Көтәр кешең –
Әни булган чакта –
Кайтуларның рәхәтлеген белдек.

Көтәр кеше –
Әни булган чакта,
Без дә һаман бала идек әле,
Әни догасының ышыгында
Гомер буйлап бара идек әле...

Әни догасының ышыгында
Көннәре дә кояшлырак иде,
Тарткан йөгең – җиңелрәк иде,
Кочар дөньяң – колачлырак иде...

Әни янына дип,
Без дә бүген
Күчтәнәчләр төяп кайтыр идек...
Рәхмәт тулы бер сөенеч шунда
Мең сөенеч булып артыр иде.

...Туган нигез һаман шулай көтә,
Әни генә хәзер юк шул анда.
Күчте Әни,
Яши Әни хәзер
Безнең догаларның ышыгында...

ЫШАНЫЧ

Ышануым сиңа кирәктер дә...
Тик син башта үз-үзеңә ышан.
Ышан кабат куркып калмавыңа,
Йөрәгеңдә сөю уты тойсаң.

Ышан: җирдә барлык кешеләр дә
«Тормыш – сәхнә» дими. Ихлас яши.
Хисләр бит ул, әгәр уйный калсаң –
Кемнәрнеңдер тәгәрәгән яше.

Типке тубы түгел сөю, аңла.
Ышаныч та – типке тубы түгел...
Ышанычның язанында ята
Тугрылыгы белән садә күңел.

Ышануым сиңа кирәктер дә...
Син үзеңә ышан әле башта.
Кирмәнме син килеп сыенырлык?
Әллә хәрабәмме ... ап-ак таштан?..

ШӨКЕР...

Мин яшәгән бу авылда,
бу шәһәрдә,
Шушы җирдә,
Җир дигән бу планетада
Кемнәр генә яшәмәгән!
Яши тора...

Мин аларның кайберләрен
хәтта беләм.
Йөрәгемне ачтым, сер бүлештем
мин аларның кайберләре белән.
Кайберләре – яшем булып тамды,
Тоер булып калды...
Тынны буган.
Кайберләре – ирен читендәге
көлемсерәү булып торды бугай.
Йөрәк утым якты янган чакта,
Шул яктыга җыелдылар дуслар.
Җылыттылар дуслар,
мин күшегеп,
Гаҗизләнеп, юл читында торсам...
Йөрәгемнең утын кайберәүләр
ала гына торды.
Бүлешмәде...
Тонык утта күзләр ялгыштылар,
Салмагаеп калды йөрешләрем...
Челтәр-челтәр юллар, пәрәвездәй,
Уйлар челтәренә тоташкан шул...
Бераз юл югалтып торган чакта,
Сузыла торды, шөкер, дустанә кул.
... Шушы җирдә,
Җир дигән бу планетада
Күпме кеше арасында
мин дә яшим.
Ничә еллар минә – җыела ашым,
Ничә еллар – языла бара эшем...

Шөкер!..

БАЛЫКЧЫ БЕЛӘН БАЛЫКЛАР

(Мәсәл)

Яр буена тезелешкән балыкчылар.
Һәммәсе дә иң зур балык тотмакчылар.

Телсез-өнсез, белми хәйлә-мазар, диләр,
Җим күрүгә, балык хәзер кабар, диләр.

Су төбендә гәпләшә, ди, балык халкы:
«Тагын басты яр буйларын адәм заты.

И кардәшләр, җим күреп сез алданмагыз,
Беләсез ич, хәйләкәр ул адәм-явыз.

Ачыгавыз була калсаң, ул тиз тотар.
Кармагына эләктерсә – кабар-йотар».

PS. Корбанына күрә һәрчак әзер кармак,
Кайчан кемнәр оттырачак – зур табышмак.

МИН СЕЗГӘ БЕР СЕР ДӘ АЧМАМЫН

Мин сезгә бер сер дә ачмамын
(Бу сезгә һич тә сер түгелдер...),
Мин бары үземнең уйларны
Бер җепкә тезәргә тырышам...
Мин гомер кичергән заманның
Күрергә тырышам чын йөзен
(Ахрысы, көлкедер бу сүзем...).

...Сораулы күзләргә чор бага,
Мин багам – шул чорның күзенә.
Хурламыйм. Зурламыйм. Базмыймын...
Ул безгә шулкадәр тәс менә.

Канатсыз калдыра, дисезме? –
Канатны каерган заманнар
Әллә соң элек тә булмаган?!
Батырша булырга туганнар
Йөрмәгән Шаһгали юлыннан...

...Очарга беркайчан соң түгел,
Булмаса җаныңда богаулар.
Балавыз җилемле канат та
Күкләрне кочкачтын...югала.

Бу заман үзгәме? – Үзгәдер.
Тик... Яхшы-яманы – һаман шул.
Кемнәрдер ышанып: «Үзгәрер!».
Кемгәдер җайлырак – ярашу.

Зур җиһад – кешенең җанында
(Сер түгел, күпләргә билгеле).
Шул орыш, шул җиңү-җиңелү
Заманга бәяне билгеле.

Мин сезгә бер сер дә ачмамын
(Һәркемгә ул үзе ачылыр).
Бу – бары Каләмгә сыенып –
Үземнең – уйларга качуым...

ХӘТЕР

Безнең хәтерләүдән курыкканнар
Тырыштылар инде.
Тырышканнар!
Вакыт җиле, кемгә сөйлисең син
Бабаларың... диеп...орышканнар?!

Тавышың тонык инде.
Тавышың сынык...
Безнең хәтер нәгърәләре сыман.
Ишетерләр иде варислар да...
Тик ... үз көен көйләттерә заман.

Тик үз көен көй иттерә ятлар,
Гафу итми көчсезлекне тарих.
Дала җилен иштәш иткән чактан
Кылганнардай – иелергә калдык...

Тырышканнар инде.
Тырыштылар!
Безнең хәтерләүдән курыкканнар...
Вакыт җиле, дулап алчы тагын:
«Рухы көченнән кабат калыкканнар!»
...Рухы көчләләр кабат калыкканнар!
Кабат!

ФАҖИГА

Нәфрәтнең күзләре – кып-кызыл.
Сүзләре агулы...Үчеккән.
Бу җан да иңгәндер ак килеш,
Бу җан соң ник шулай күшеккән?

Тамчылап-тамчылап бу җаннан
Ярату югалган ни өчен?
Дөньяны караңгы баз итеп,
Кайлардан яралган кот үче?

Кизәнеп Раббының Үзенә
Ник язган җанкыяр булулар?
Шомыртлар ак чәчкә аткан чак...
Ә бездә кап-кара кайгы бар.

Ярлыкау сорарга соң микән?..
Гөнаһлар, ялгышлар, хаталар...
Ярату җитмәгән дөньяда
Мәктәптә мылтыктан аталар...

УЯУЛЫК КЕМГӘ КИРӘК?

(Мәсәл)

Шулай бер заман уйга калган Елан:
«Зирәклегем – таман, агуым – яман,
Нишләп дөнья хакиме түгелмен һаман?!
Мин шуышкач – башкалар да шуышсын,
Мәрхәмәтем көтеп, койрыгыма елышсын!"

Бар еланны үз янына ул туплаган.
Елдамнарын үсендергән һәм хуплаган:
«Өнсез-тешсез диеп сезне белсеннәр,
Һич курыкмый, гел җай гына йөрсеннәр.
Уяулыкны югалтуы тиз аны –
Шул чагында яуларбыз без дөньяны!

Куяннары өркә-өркә сырышыр,
Аюларга читлек-тозак булышыр,
Сиздермичә генә һөҗүм итәрбез,
Ваемсыз чаклары җитәр! Көтәрбез!»

PS. Елан үрчесә, пошмаслык куркыныч.
Мәкер азса, ничек яшәрсең тыныч?!
Акыллы дошманны җиңәрсең бары
Үткен күзең булса һәм үткер кылыч.

РЕДАКЦИЯДӘН. Шагыйрә һәм прозаик, Чаллыда нәшер ителә торган «Мәйдан» журналының баш мөхәррире, С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе Лилия Фәттаховага шушы көннәрдә 50 яшь тулды. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.

ДӨНЬЯНЫ

(Дәвамы.Башы 41 нчы санда).

1955-1958 елларда укып, балет училищесын тәмамлагач, Рудольфны СССРның өч төп театры эшкә чакыра. Киров исемендәге балет театрын ул үзе сайлый. Коллектив аңа зур өметләр баглый. Ул берничә спектакльдә төп рольләрне башкара. Коллектив Нуриевнең җыелышларга йөрмәвен дә кичерә. Әмма шул ук вакытта ул күнегүләрнең бер сәгатен дә калдырмый. Арып идәнгә егылганчы күнекмәләр ясый. Ул ир-ат биючеләр бары трико гына киеп биергә тиеш дип саный һәм шулай бии дә, ир-ат биюе балерина биюе шәүләсендә калмаска, пассив булмаска тиеш дип белдерә. Аның таланты, көчле холкы алдында каушап, каршы әйтмиләр. Нуриевнең абруе артканнан-арта, чөнки биюдә аны беркем дә уза алмый. Аның бию хәрәкәтләре арасында «һавада эленеп тору» элементы була. Аны тамашачы аеруча исе китеп, сулыш та алмыйча карый.

Беренче тапкыр чит илгә баруга ук, татар егете Венада узган Бөтендөнья яшьләре һәм студентлары фестиваленең алтын медаленә лаек була. 1959 елда ук Австрия матбугаты аны рус балетының төп йолдызы дип атый. Аннары Болгария, Германия, Мисыр гастрольләре... Арып кайткан Нуриевне 1959 ел ахырында Йошкар-Олага юллыйлар. Үпкәсенә салкын тисә дә, ул анда бара. Самолетка утырырга рөхсәт итмиләр, поезд белән генә барырга кушыла. Чыгышы тәмамлангач, ачуы кабарып, янә Ленинградка кайтып китә. Егеттән ни хәлең бар, дип сораучы табылмый, бары: «Сине башка чит илгә алу юк!» – дип кенә белдерәләр. Әмма Париждагы чыгышлары вакытында аны чиксез уңыш көтә. Газеталар: «Руслар бер биючене Айдан алып килгәннәр!», «Киров балеты үзенең космонавтын тапкан, аның исеме – Рудольф Нуриев», дип яза. Тик тәртибе... Аны күзәтәләр, ә кайда йөргән сорагач, ул ачу белән ишекне шапылдатып ябып чыгып китә...

Гомумән, күзәтүче хезмәткәрләрнең Нуриевкә бәйле үз планнары була, аны Мәскәүгә кире кайтарып, үз эшләренә уңай бәя алырга телиләр.

Франциядәге дәүләт балет театрлары Р.Нуриевне эшкә алудан баш тарта. Чөнки совет иле аларга: «Әгәр дә Нуриевне Париж операсы балетына алсагыз, дәүләт субсидиясендәге бар совет-француз мәдәниятләре контрактларын юкка чыгарачакбыз», – дип белдерә.

Әмма маркиз де Куэвасның балет труппасында, шәхси труппада бии башлаган егет бурычка керергә дә өлгерми кала. Чөнки аңа хезмәт хакы билгеләнә. 1992 елда Казандагы әңгәмәдә ул моның чиксез түбән хезмәт хакы булуы хакында искәртә. Чөнки биюче ул чакта һәр кич сәхнәдә тир түгә... Кесәсендә нибары илле франк кына булуын искә алмый. Рудольф Хәмит улы чит илдә калгач, икенче көнне үк: «Миңа класс, зал кирәк. Мин кайда күнекмәләр ясый алам?» – дип кенә сорый. Киләчәктә Ли Галли утравын сатып алачагы, хәтта үз балет студиясе булачагы әле аның төшенә дә керми...

Хәзер инде аны ике француз тән сакчысы һәм совет агентлары күзәтә. Тик сорап тормагыз аннан Ватанны юксыну хакында... Франциядә калып, җиде көн үтүгә, ул инде сәхнәдә «Йокыга талган гүзәл»дә принц Флоримунд ролен башкара. Тамашачылар аны аяк үрә басып алкышлый, чыгышын дүрт тапкыр кул чабып бүләләр һәм сәхнә пәрдәсе төшкәч тә, 28 тапкыр сәхнәгә чакырып чыгаралар.

Труппа әлеге балетны ай буе куя. Р.Нуриев та йә принц партиясен, йә Зәңгәр Кош па-дедесын бии. Зәңгәр Кош дебютын башкарырга берничә сәгать калгач, аңа фотограф өч хат тапшыра. Әнисеннән, әтисеннән һәм укытучысы А.И.Пушкиннан. «Ватанга кайт» диелгән сүзләр, әтисенең улыннан ваз кичүе хакындагы юллар...

Билгеле, «ватаннан ваз кичкән» качкынның аякларын да сындырырга уйлыйлар, ә Хрущёв аны юкка чыгарырга куша. 1963 елның 1 декабрендә Лондоннан Сиднейга очканда, очкычка Каһирәдә техник тукталыш ясарга туры килә. Бар пассажирларга да очкычтан чыгарга кушалар. Р.Нуриев аңлый: аны КГБ хезмәткәрләре көтә. Шулчак батыр йөрәкле бер стюардесса очкычта берүзе генә калып, Рудольфка бәдрәфкә кереп бикләнергә киңәш итә. Бәдрәф ишеген ике йозакка бикләсәләр дә, бу хәлне биюче: «Бу минутларда чәчләрем агара башлады», – дип искә ала. Очкычка кергән ике КГБ хезмәткәре бәдрәф ишеген күпме генә тарткаласа да, бераздан очкычтан чыгып китәргә мәҗбүр була, чөнки стюардесса аларга бәдрәф эшләми, шуңа күрә бикле, дип кабатлый. 1989 елның ноябрендә, ватанына кайтып, 51 яшендә балерина Жанна Әюпова белән «Сильфида»да бииячәк көннәргә кадәр ерак әле... (Дөрес, тулысынча бирелеп биесә дә, балет җәрәхәтләре, олыгаюы һәм чире көчәюе сәбәпле, спектакль бик уңышлы килеп чыкмаячак чыгуын). Әмма үз ватанында реабилитациягә ул барыбер көтеп җиткерә алмаячак. Бу карар ашыкмыйча гына, 1998 елның 18 октябрендә кабул ителә. Биюче үлеп биш ел узгач.

Р. Нуриев балет мәктәбе укучылары белән.

Р.Нуриев ашарга пешереп азапланмый, гомумән, аз ашый, тәүлегенә 4-6 сәгать йоклый, күп очракта йокы вакыты да йә таксида барган, йә очкычта очкан мәлләргә туры килә... 13 сәгать күнекмәләр ясый, һәрчак яхшы формада. Чыгышлар, башка ил тамашалары... танылган биючегә бары да ошый. Соңрак аңа тагын бер кушамат уйлап табачаклар: «Тере электростанция». Өстәвенә, инде сәхнәдән китергә ниятли башлаган 42 яшьлек прима-балерина Марго Фонтейн 23 яшьлек биючене Лондонга, бергәләп биергә чакыра. «Татар кенәзе һәм инглиз дамасы» дип аталган матур тандем барлыкка килә. Алар бергәләп 16 ел бии. 1962 елда ул Лондон Королева балеты белән контракт төзи, ә анда чыгышлар ясау өчен Бөекбритания гражданины булу таләп ителә. Әмма Р.Нуриев өчен искәрмә ясала. 1962 елда, «Конвент-Гарден» театры сәхнәсендә Марго белән бергәләп «Жизель»не бии. Татар ир-аты Лондонның Королева балеты йолдызына әйләнә. Гомумән, аны үзләрендә биергә бар дөньяның иң мәшһүр театрлары чакырачак. Чит илдә тәүге елларда аңа спектакль өчен 2800 доллар түлиләр. 1970 еллар башында бер биюе өчен 7000 доллар түләнә. 10 елдан соң «Нуриев һәм дуслар» төркемен оештыргач, аңа бер чыгышы өчен 10000 доллар түләячәкләр. Р. Нуриев үз-үзенә карата аяусыз була. Әйтик, 1984 елда пневмония һәм гепатит диагнозлары куелуына да карамастан, Эдинбург фестиваленә китә. Көчкә сулыш алса да, үзен бик начар хис итсә дә, бар спектакльләрдә дә чыгыш ясый!

1970 еллар ахырына кадәр ул «Метрополитен-опера»сында һәр җәй бии, театрның матди хәлен ныгыта, халык аның чыгышларына, ә балет яратмаучылар Нуриевнең йөзен күрү өчен килә. Нуриев Канада биючеләре белән дә дус. 1971 елда аңа инде 33 яшь була. Бу яшьтә башкалар сәхнәдән китү мәлен көтә, ә аның көрәшчән холкы, нык рухы, үҗәтлеге төгәллек таләп итүче классик биюләрдән тыш кискен хәрәкәтле заманча биюләрне дә өйрәнә башларга этәрә.

Вена артисты буларак Австрия гражданлыгын кабул итә. Англия королевасы белән очрашу вакытында, Нуриевнең аяк киеме кыса һәм ул яланаяк бии. Этикет бозучыны күреп, королева хезмәтчеләренең күзләре маңгайга менә... Королева исә Нуриевнең гамәлен күрмәмешкә салыша. Джон Кеннеди һәм аның җәмәгате Жаклин да татар биючесен җылы кабул итә. Жаклин белән дуслыгы исә гомер ахырына кадәр дәвам итә. Ә менә аның хореографиясенә һәм стиленә зур йогынты ясаган данияле биюче Эрик Брун белән дуслыгы суына. Эрик, Рудольф үтенече буенча, аңа бар бию серләрен аңлатып бирә. Э.Брун ул чакта камиллеккә ирешкән балет артисты була, аңа тиңнәр юк, шул сәбәпле Э.Брунга инде күңелсез дә... Тик менә сәхнәгә татар егете күтәрелә бит, ул гаҗәеп яхшы бии, ләкин бию осталыгы буенча аннан барыбер калыша. Рудольф Эрикның күнекмәләр залына ашкына, тагын да яхшырак бию өчен күп дәресләр ала. Тик шушы мәлләрдән соң Нуриевнең биюләрен тамашачы тагын да ошата, ә Эрик Брунны оныта башлый.

Р.Нуриев елына 250 шәр тапкыр чыгыш ясый. Бу – сәхнәдә 750 сәгать булуга тиң, ә репетицияләргә, димәк, ике тапкыр артыграк вакыт китә. Гомеренең соңгы ике елын исәпкә алмаганда, татар биючесе үзенә елына нибары ике атна гына ял итәргә

Р. Нуриев репетиция вакытында.

Р. Нуриев һәм М. Фонтейн.

ШАУЛАТКАН ТАТАР

● Р. Нуриев «Валентино» фильмында.

● Парижда калганнан соң тәүге бию.

рөхсәт иткән, дип язылган аның хакындагы истәлекләрдә. Ул һәрчак кешеләр арасында була, әмма шул ук вакытта ялгыз кала. Нуриев «Риалитэ»га биргән интервьюсында болай ди: «Мин үз-үземә сөенеч, үз-үземә көенеч! Минем үземне бер җан иясенә дә бәйләп куясым килми, ләкин еш кына әниемә, Уфага шалтыратам һәм туганнарымның яңалыкларын белү өчен дөньяның дүрт ягына да шалтыратып торам...» Билгеле, әнисе дә аның хәлләрен белеп тора. Аңа улының биюе яздырылган тасмаларны күрсәтүчеләр дә табыла. Тик аны беркайчан да чит дәүләткә чыгармыйлар. Хәтта аны кире алып кайтырга теләп Мәскәүгә, Фурцева янына баргач та, мәдәният министры Фәридә ханымны, Розаны кабул итми. Инде күп еллар үткәч, биючене чирле әнисе белән күрештерүне үтенеп, ананың үз улы янына күчүенә ризалык сорап 170 мең имза җыела, ләкин совет хөкүмәте өчен бу буш кәгазь булып кына кала. 1975 елдагы мөрәҗәгатькә дә, 1976 елдагы «Нуриевне яклау комитеты» мөрәҗәгатенә дә җавап булмый. Рудольф чит илдә һәрвакыт ялгыз. Бер дусты аның арып, ванна идәненә йоклап киткәнен күрә. «Биюченең гаиләи җылысын күргәне дә юк. Бөгәрләнеп йоклаганда ул кечкенә баланы хәтерләтә иде», – дип искә ала аны дусты. Бертран Майер-Стабльнең «Рудольф Нуриев» китабында бу хакта шулай дип тә тасвирланган: «Марго Фонтейн болай дип яза: «Рудольф белән эшләгәндә, мин еш кына аның белән дөньяви очрашуларга бара идем. Ләкин очрашулардан һәм кичәләрдән соң минем аның белән сирәк гаплашасем килә иде. Ул һәрчак төнгә чыгып китә иде, аның буш урамнар перспективасында ары китеп баручы ялгыз силуэты. Мондый китүләрдә аның нинди-дер фаҗигасы бар иде, аеруча да күңелле кичке аштан соң».

Нуриев еш кына зур суммаларгы акчаларын аз таныш кешеләргә биргәли, бурычны кайтарулары хакында да уйланмый. Төрле дәүләтләрдәге йортлары өчен даими салымнар түли, әмма ул аларда бик яшәми дә. Йортларын гаять кыйммәтле антиквар әйберләр, сыннар, борынгы гасыр картиналары, келәмнәр белән тутыра. Бу ир-атны һәрчак гаеплиләр, әнә аны мотоцикл бәреп киткән, әнә ул нинди җавапсыз, үзе белән сатулашып торган бер биючегә суккан икән,

● Р. Нуриев һәм Марго Фонтейн.

сәхнәгә биергә чыгар алдыннан юлына каршы килүче берәүне төртеп еккан, ул – эгоцентризмның үзе, имеш. Боларга каршы биюче болай ди: «Мин бик каты холыклы, кайчак үз-үземне дә аямыйм. Биегәндә миңа бик зур игътибар туплау һәм гаять күп көч кирәк...» Афишада аның исеме язылса, билетлар күз ачып йомганчы сатыла. М.Фонтейн белән бии башлагач, аларның спектаклен карарга ниятләгән 30 мең кеше театрга билет сорап мөрәҗәгать итә. Англиядә балет бумы башлана. Кайсы дәүләттә генә биесә дә, аны бары триумф көтә. Классик балетлардагы төп рольләрне үзенчә бии, моннан кала дүрт дистәдән артык хореографның йөзгә якын заманча бию куелышларын өйрәнеп, аларда да бии, алар махсус аның өчен язылган да була, репертуары киңәйгәннән-киңәя. Ул биюләрне бик тиз истә калдыра. Аларны шулкадәр камилләштерә белүе өчен, аны хәтта тәнкыйтьчеләр дә мактый. Яше барганын аңлап, тиз башкарыла торган заманча биюләрдән драматизм, романтизм көче булган биюләргә күчә бара. Тамаша тәмамлангач Р. Нуриевка рәхмәт әйтергә теләүчеләрдән чиратлар тезелә. Арып беткән, ләкин барыбер да елмаюлы иҗатчы совет кешеләренә хас рәвештә «р» хәрефенә басым ясап, аларга үз рәхмәтләрен әйтми калмый.

Ләкин аның холкы бер дә җиңелләрдән түгел. 1970 елның маенда Нью-Йоркның Королева балетында «Щелкунщик» премьерасын Мерль Парк белән биегәндә, көй кирәгеннән артык кызу уйнала. Алар биюләрен дәвам итә. Тик тиздән Рудольфның мондый тизлектә биисе килми, ул балеринага: «Тукта, кызый, әйдә әле яңадан бии башлыйк», – ди. «Ул мондый темпны көтмәгән иде, без station гына бәрелешми калдык, – дип искә ала Мерль Парк. – Мин аңа: «Рудольф, болай эшләргә ярамый, дәвам итәргә кирәк», – дидем. Ләкин ул сәхнә читенә килде дә дирижер Джон Ланчберидан туктавын үтенеп кулын күтәрде. Ә ул бернәрсә дә сизмәвен белгертергә теләп, башын аска иде һәм дәвам итте». Шулчак Рудольф үз партнершасын этеп җибәргән һәм ачуы чыгып сәхнәдән чыгып киткән. «Мин бер почмакка йөгердем һәм: «Рудольф!» – дип кычкырдым – аннары жете (балет хәрәкәте – ред.) ясадым һәм шуны ук икенче почмакта башкардым. Бу вакыт эчендә Нуриев кытай вазасын ватарга өлгерде. Па-де-де ахырында ул кире чыкты һәм мин аңа: «Бик зур рәхмәт. Сезне күрүемә бик шат», – дидем. Аннары без балетны тәмамладык. Соңрак, сәхнә артына кергән берничә тамашачыны күргәч, ул үзе дә гафу үтенде», дигән хатирә дә сакланган.

«Монысы Мод истәлекләреннән: «Без «Вашингтон мәйданы»н куйган чакта, 1985 елда, ул хастаханәгә ятачагы хакында белгертте. Хәлем начар, кил, диде. Аны күргәч, котым очты: әйтерсең лә, ике көн гомере калган төсле иде. Мин моның нинди чир икәнен шундук аңладым. «Мод, син минем каным белән ни булганын беләсеңме?» – дип сорады. «Әйе, Рудольф, мин моның нәрсә икәнен аңлыйм». Сәер, әмма сөйләшкәндә ул бер тапкыр да чире аталышын әйтмәде. Әйтте: «Беләсеңме, зарланырга хакым юк, мин моны үзем китереп чыгардым». Һәм ул чыннан да беркайчан да зарланмады, хәтта аңа операция ясаганда да (беренче тапкыр Венада, аннары, бик авыры, Парижда) һичбер зар булмады», – дип искә ала хореограф Руди ван Данциг. Тагын бер кат телгә алып үтик: 1975 елда татар биючесе 299 тапкыр чыгыш ясаган. Руди ван Данциг дәвам итә: «Рудольф: «Ун атна эчендә мин туксан спектакль биедем. Лондон Королева балеты бер сезон эчендә сиксән спектакль куя», – диде. Аның күзләрендә тантана чагыла иде. Ул бер кичтә өч спектакль бии, кайчак дүрт, әгәр дә иртәнге спектакль булса, бу инде көненә ничә балет дигән сүз! Ничек кенә арган булса да, ул, мәшһүр, һәрчак башка биючеләргә булыша һәм даими рәвештә киңәшләрен бирә яисә тәнкыйтьли. «Мондый төксе йөзләрегез белән сез монда нишлисез соң? Сезне кемдер биергә мәҗбүр итәме яисә сезнең үзегезнең бисегез киләме? Бу – балетның тәмамлануы, финал, аңлагыз, аллегро кирәк! Елмаегыз, бәхетле булыгыз!» – ди иде ул сәхнә артындагы труппага. Балет артистлары дәшми. Р. Нуриев алар өчен – абруйлы, катгый карашлы җитәкче, профессионал, төрле өлкәләргә караган бихисап китаплар укып, үз белемнәрен күтәрүче дә. Мәсәлән, Клод Геньер болай ди : «Ул һәрбер илнең тарихы, театрлары һәм әдәбияты хакында барысын да белә иде. Ул болытлар астында булганда – континенттан континентка очканда да – йотлыгып китап укыды. Ул үз хәтерен бертуктаусыз баетты һәм үз хыялларына очыш әзерләде». Иҗатчы үзен кино сәнгатендә дә сынап карый, ике фильмда төшә, шуларның берсе – «Валентино» (1977). Анда ул төп рольне башкара, әмма кинорольләре уңыш китерми.

Еллар үтә. «Менә газеталарның берсе Рудольфның чыгышына: «Тукталырга вакыт җитте» дигән фикерен белдергән. Бу сүзләр аны чыгарыннан чыгарды, ул сүгенде һәм бар нәрсәне тотып бәрде. Мин аны җәлләдем. Ул тәмам югалып калган төсле иде: күңел кайту һәм өметсезлек төене шикелле; ул бит – мәшһүр һәм публика аны ярата, ә монда аңа кемдер каршы!

Рудольф гадәти тормыш алып бармады, ул дүрт кешелек эшләде һәм биеде, тезләренә зыян килүенә дә, ашык сөяге туры кабарып чыгуына да һәм үкчә сеңере тартылуына да карап тормады.

Иртән, бүлмәләр буйлап көч хәлгә йөргәндә, ул инвалид булып күренә, баскычның ике арасын да үтеп, өскә күтәрелә алмас сыман тоела иде. Ул бик начар йоклый, йокысызлыктан иза чигә иде... Төнлә шабыр тиргә батып тора. Литрлап су эчә яисә үзе чәй куя иде. «Сине нәрсә борчый?» дисәм, «Белмим, нидер борчый», – дия иде. Шул ук вакытта ул ипохондрик та түгел иде». Менә ул инде авыру да... «Бик арган иде. Аның карлыккан, күңелсез тавышын ишеттем: «Театрда кичәге хакында, минем ничек биюем хакында беркем бер сүз дә әйтмәде, барысы да үзләрен берни булмаган төсле тотты». Кич булып, инде мин китәргә дип чыккач, баскычта чакта ул җиңемнән тартты: «Мин Россиягә кайттым һәм әниемне күрдем. Синдә теге плёнка саклandымы?» Әлбәттә, аның әнисен төшергән плёнканы мин саклый идем. «Үз әниеңне күргәч, нинди хисләр кичердең соң?» – дигән соравыма ул болай дип җаваплады: «Ул мине танымады. Миңа карады һәм: «Бу кем? Бу нинди ир-ат?» – дип сорады. Ул, әйтерсең, бу сүзләре белән үз-үзен яклады», – дип язган Руди ван Данциг китабы битләрендә.

(Дәвамы киләсе санда).

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Хәсән САРЬЯН

Мине кем озатыр?..

(«Бер ананың биш улы» повестеннан)

Мин аның исемен дә белөм белүен: Любовь Васильевна. Тик мин аны нәкъ үзләренчә итеп әйтә генә алмыйм: минем татарчага ятып беткән телем «Любовь» урынына «Лүбуф» ди. Шуңа тагы «Васильевна» сын да китереп кушсаң, иреннәрем «б» гә ябышып ката да, әллә нинди «Лүбуббасилибна» килеп чыга.

Ул – күземнең көндәлек куанычы иде. Бәлки, аның ире дә, баласы да бардыр. Тик мин аларын уйламыйм – миңа аны күреп тору гына кирәк: сылу ак йөзен бер күрсәм дә, шул караңгы, ямьсез көннәрем ачылыплар киткәндәй була иде. Бер уйласаң, бу интегүләремнең барысы да гел аның өчен иде бит! Аны күргәндә йөзем кызармас өчен иде…

Моңарчы мин – унсигезгә җитеп, Актаныштан башка район, Җәзиләдән башка кыз күрмәгән малай – Уфадай зур каланы күрдем. Уфасында бер Любовь Васильевнаны күрдем. Мин хәзер берни эшли алмыйм: әни әйтмешли, мин бер исәр Мәҗнүн идем.

Ләкин бу газаплы рәхәт көннәрем озакка сузылмады. Ноябрь башы белән военкоматка чакырып, кулга повестка тоттырдылар. Мин инде районда да, монда да комиссия үткән – ни тышымда, ни эчемдә солдатка ярамаслык бернәрсә дә юк иде. Без – группадан ике малай. Чишмәнеке, якын булгач, каралу белән кайтып китте, ә мин, туйга да кайта алмаган кеше, көзге Агыйдел бозыдай ябышып, шәһәрдә калдым.

Инде укуга йөрмәсәм дә була иде. Ләкин Любовь Васильевнаны күрми ничек торыйм?.. Укытучылары да миннән, капыл исләренә төшкәндәй, дәрес саен сорый башладылар. Сөйли алган кадәресен үзем сөйләп, алмаганын үзләре сөйләп, миңа тиз-тиз генә өчле дә дүртле куеп чыктылар. Монысы ни өчен кирәк булгандыр – күңел күтәрү өченме? – белмәдем.

Армиягә китәчәгем турында өйгә хат салдым. Инде елга-сулар туңып, җир дә катырып җибәрде. Көн тудымы, авылдан Хәвадис абыйның килеп төшүен көтәм: ичмаса, каңгырып яткан чит җирдән чит җирләргә киткәндә кул биреп калыр иде!.. Мине кем озатыр?.. Инде мин ник укырга килүемә дә үкенә башладым. Мин бит үземнең быел китәсемне белә идем. Мирза абыйның: «Китсәң дә, укудан китәрсең, кайтуыңа урының әзер торыр», – дип, бик нык кисәтеп язганга күрә генә килгән идем шул…

Любовь Васильевна, минем боек күңелемне үзенчә аңлап:

– Егет кеше солдатка киткәнгә борчылырмы? – диде.

Мин аңа борчылуым сәбәбе һич аңардан түгел икәнлекне әйттем.

– Детдом баласын да тәрбияләп озаталар, мине генә озатучы юк. Мин читтә ялгызым – ярга ташлаган балык шикелле, – дигән фикерне ватык-җимерек русчам белән ермачлап чыктым. Минем: «Ат тоягы җитмәс җирләргә китәм бит мин хәзер!» – дип тә әйтәсем килә, тик анысына телем юк иде.

Любовь Васильевна, эчемдә ни бар, барысын да үтәли күргәндәй итеп елмаеп әйтте:

– Ә мине исәпкә алмыйсыңмыни?..

Калган сүзләрен мин ишетмәдем. Җиргә төшә алмый җилпенеп очкан җиңел кардай, авырлыгым бетеп, идәнсез, стенасыз бер бушлыкта йөзә башладым.

Любовь Васильевна йомшак кына итеп беләгемә кагылды:

– Не унывай, джигит!..

Шунда гына, әйләнгән башым туктап, баскан җиремә кабат кайтып төштем…

Любовь Васильевна бер тәнәфестә мине бер читкә чакырып алды да, сәгать алты тулгач, Якут бакчасы янында көтеп торырга кушты.

Мин – тагын өч көннән китәсе кеше. Солдатка китәсе булгач, ноябрьнекенә кушып, декабрь стипендиясен дә бирделәр. Мин инде Хәвадис абый килереннән өмет өзгән: врач кулындагы кеше, әллә ниләре килеп чыккандыр әле дим. Шулай итеп, карап торыр бердәнбер кешем Любовь Васильевна булып, укуга да тик аны күрер өчен генә йөри идем.

«Ходаем! Колагым ялгыш кына ишетмәде микән?.. Әллә төштә генә күрдемме соң?» дип, курка-шикләнә Якут бакчасына киттем.

Айның соңгы җомгасы иде. Басуларга инде буразналарны тигезләп кар салгандыр. Инде малайлар да, сеңелләре белән тәңкә ясый-ясый, көзгедәй буа өстендә боз шуалардыр. Ә шәһәрдә карны яуганда гына күрәсең икән – төшә дә эри, төшә дә эри. Аяк асты гел юеш – күңел дә шуның салкын дымын тартып тора төсле… Тиздән каз өмәләре башланачак. Тиз генә күреп булмас инде ул каз өмәләрен…

Мин шулай, беркемгә кирәкмәгәндәй, япа-ялгыз башым Якут бакчасының акбурга буялган биек капкасы төбендә басып торам. Йон оекбаш белән кирза итек кигән аягым да өши башлады. Мондый гына суыкта авыл җирендә аяк өши димени! Ә монда өши. Авылымдагы җылы-йомшак җир түгел шул мондагы таш!..

Уем авылда йөрсә дә, күзем монда – гел бер якта, гел техникум ягында иде.

Сәгатьне белми көткәнгәме, миңа берзаман Любовь Васильевна бөтенләй килмәс сыман тоела башлады. Болай да кирәгем юклык хисе капыл көчәеп, йөрәгемә котып салкыны йөгерде.

Юк!.. Бәхетем бетмәгән икән әле! Әнә ул – бөтен урамга берүзе ямь биреп, коштай очып килә. Башына ак мамык шәл бәйләгән, кулына ридикюль тоткан. Салкын диме, пычрак диме, һаман йөреп торган шәһәр халкы эченнән, бу тар тротуарда йөзе бергә тыгылып килсә дә, мин аны танычак идем!..

– Аз гына соңладым инде, үпкәләмә, – диде ул.

Мин, бу бәхет, бу куанычтан очарга җитешеп, телсез калдым. Ә күңелем: «Мин барыбер көтәчәк идем. Менә бу трамвайлар туктаганчы, менә бу кешеләрнең дә бер арып егылыр сәгате җиткәнче, шәһәр уртасында ялгыз каен төсле берүзем калганчы көтәчәк идем!..» – дип сайрый гына. Тик әйтергә сүзем җитми, җиткәнә дә бер-берсенә ялганмый. Шулай да мин әйтәсе килгәнне гаҗәп тиз аңлый торган бер кеше иде ул Любовь Васильевна! Мин фикеремне бер кат ерып чыккач, беләгемнән тотып, рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

– Чудной ты!..

Аннары инде, бер тоткан беләгемне җибәрмичә:

– Туңгансыңдыр, әйдә, китик, – диде.

Чатка җиткәч, без трамвайга утырдык. Аннары, «Совбольница» дигәндә төшеп, янгырдан каралып беткән өйләр, коймалар буйлап киттек. «Совбольница менә шушы инде» дигәч күп тә бармадык, бер кечерәк капка янында туктадык.

– Менә мин кайтып җиттем, – диде Любовь Васильевна. – Бүген мин сине өйгә чакырмыйм, ә берсекөнгә сәгать биштә безгә кунакка килерсең. Йортыбызны онытмассың бит?.. Шулай да менә адрес, – дип, миңа адресын язып бирде.

Бу бәхетле минутларымны мин хәзер берничек тә сөйләп бирә алмыйм. Ничек квартирама кайтканмындыр, кайчан ятып, кайчан торганмындыр – берсен-бер хәтерләмим. Җаным бу фани җирдә түгел, җиде кат күктә иде. Ниләр генә уйлап бетермәдем мин ул көнне!.. Соңыннан үзем үк оялып йөрдем…

Шимбә көнне дә мин, йөрәгемне баса алмыйча, техникумга барып, дәрестә утырып кайттым. Любовь Васильевна мине күргәч оялып кына күрешә дә тизрәк китү ягын карады. Миңа бу нәкъ авылча, үзебезчә якын булып китте.

Якшәмбенең сәгать бишен җиткерә алмыйча, бер кибеткә ун кереп йөргәннән соң, сабырым бетеп, трамвайга утырдым. Төшкәч, берәүдән сәгать сораган идем – әле дүртенче ярты гына икән! Тагы сәгать ярымны ничек үткәрергә?.. Каршы якка чыгып, кире трамвайга утырдым. Шулай ике кабат «кольцо» әйләндем.

Ишек ачарга Любовь Васильевна үзе чыкты. Күз күреп өйрәнгән киемен алмаштырып, эре чәчәкле озын күлмәк кигән иде. Ул мине зур, якты бүлмәгә алып керде. И андагы ямьне күрсәң! Бүлмә тулы әйбер – комод, көзге, пыяла шкаф, этажерка, сәгать – тагын әллә нәрсәләр… Түрдә чуклы чаршау эленгән тагы бер ишек бар иде, шуннан ап-ак чәчле, бик матур бер әби килеп чыкты.

– Бу – минем әнием, – диде Любовь Васильевна.

Әйтмәсә дә, әнисе икәнлеге аермачык иде.

– Менә шушы егет инде мин әйткән. Исеме – Сирин. Сирень. Ә Серёжа дип әйтсәк ачуланмассыңмы? – дип, күзен тутырып миңа карады.

Ничек ачуланасың инде бу күзләргә? Кырын гына карамасын…

Әнисе миңа диваннан урын күрсәтеп, мөлаем йөз белән утырырга кушты. Мин утырдым. Любовь Васильевна комод өстеннән бәрхет тышлы альбом алып бирде. Аннары алар әнисе белән икәүләп кухняга чыгып киттеләр. Түр ишектән башын гына тыгып күзәтеп торган икеөч яшьлек бер малай, йөгереп килеп, минем альбом караганны карап тора башлады. Мин аңа күз генә кыстым да бөтенләем белән альбомга йотылдым…

Менә Любовь Васильевна – бәләкәй генә кыз бала. Менә ул тиз-тиз генә үсеп укырга китте. Менә җиткән кыз чагы. Чәчен ике яктан киртләч-киртләч ясап, башына берет киеп төшкән. Кашлары сызып куйган төсле. Керфекләренә моңсу күләгә кунган. Фотосы шундый әйбәт-ачык, күзенең һәр нуры йөрәкләргә үтеп керә иде… Аннары, эчләремә ут салып, янында бер егет күренә башлады. Гел шул бер егет!.. Ахырда ул, солдатка әйләнеп, пилотка кигән килеш, берүзе бер биттә Любовь Васильевнадан аерылып калды. Мин, тагы кире кайтып, икесе бергә басып төшкән карточкага карап тора башладым…

– Бу – Миша. Мансур. Без бер мәктәптә укыган идек. Сугышка киткәч бер генә фотосы килде.

Мин күземне фотодан алып, сизмәгәндә яныма килеп баскан Любовь Васильевнага карадым. «Ник шул егет урынында мин булмадым икән?!»

Любовь Васильевна кулымнан альбомны алды да кире комод өстенә илтеп куйды. Шунда гына мин табынга инде аш-су килгәнен күрдем.

Ике көннән безне Уфа вокзалында эшелонга төяп армиягә озаттылар.

Без киттек. Көлдәй соры, болыттай юеш перронда, тик мин генә күргән кояш төсле, миңа ак юл теләп, бәхеттәй ак йөзле Любовь Васильевна басып калды.



Инде аннан соң күпме көз, күпме язлар үтеп, мине кемнәр, мин кемнәрне озатмаган! Тик һаман да, поезд күрсәм, яшьлегемнең Любовь Васильевнасы миңа шулай кул болгап кала төсле. Тик хәтеремдәге йөзе моңсулана бара, моңсулана бара. Мине озатканда елмаеп калган иде бит ул!..

Көйсез көннәрнең көлкесез «КӨЛ»е

Илдәге вәзгыять фонында мәдәният һәм сәнгатьтә дә шомлы үзгәрешләр күзәтелә. Радиодан, телевизор экраннарыннан, мәдәнияттә мобилизация үткәреп, ышанычсызларны алып атарга, дәүләткә файда китерердәйләрне генә калдырырга чакырулар ишетелә. Бу – беренче һәм соңгы мобилизация түгел, XX гасырда «зыянлы»ларның каны елга булып акты. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының кече залында режиссер Айдар Җаббаров япон авторы Коки Митанинның «Көлү академиясе» әсәре буенча куйган «Көл» спектакле тамашачыга бүгенге вәзгыять уңаеннан татар әдәбияты һәм сәнгате тарихында канга батырылган язмышларны искә төшерә.

Спектакльдәге вакыйгаларда нибары ике герой – Эмиль Талипов башкаруында «Көлү академиясе» театр труппасының драматургы һәм Алмаз Борһанов гәүдәләндерүендә Цензор гына катнашса да, алар аркылы хакимият һәм мәдәният мөнәсәбәте, тоталитар режим шартларында иҗат иясенең хәле кебек тирән темалар ачыла. «Хуш, авылым» һәм «Хуш, авылым. Хыял» спектакльләрендә кебек үк, режиссер А.Җаббаров билгеләнгән теманы тирән өйрәнеп, документальлек чалымнары булган спектакль иҗат иткән. Япон драматургының әсәре иҗат ияләребезнең фаҗигаи язмышын искә төшерергә бер сәбәп кенә. К.Митанинның әсәрен актер Фәнис Җиһанша тәрҗемә иткән, әдәби консультант буларак телевидение журналисты Гөлчәчәк Шәйхетдинова саллы эш башкарган. Сәхнәдәге Автор һәм Цензор тарткалашуы тынып торган араларда язучы Әмирхан Еникинең ни өчен 1930 елларның беренче яртысында язудан туктап, әдәбияттан китүе, Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ы бүгенге укучыга тулы язылышында килеп җиткәнче нинди кисү-кыскартуларга дучар булуы, олуг Тукаебызның «Китмибез» шигыре өчен ничек эзәрлекләнүе турындагы материалларны, язучылар Галимҗан Ибраһимов һәм Кәрим Тинчуринның китапларын яндырып сәяси тамаша оештырулары турында Адлер Тимергалинның балачак истәлекләрен режиссерга нәкъ менә Гөлчәчәк табарга ярдәм иткән дип уйларга кирәк. Шуларның берсенә – Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәренә генә тукталсак та, спектакльнең асыл максаты газета укучыларга да, театр сөюче тамашачыларга да яхшы аңлашылыр, мөгаен. Г.Исхакый үзенең «Тәрҗемәи хәлем»дә «Ике йөз елдан соң инкыйраз» китабы басылып чыгып, кулына алгач булган халәтен болай тасвирлаган: «Рус цензоры әсәрнең өчтән икесен кисте вә калган өлешендә дә фикерләрне укучы аңламаслык итеп үзгәртте. Әсәремнең цензордан бу хәлдә кайтуына шулкадәр ачуым килде, әсәремне бу хәлгә калдырган җанвар цензорны хәтта Петербургка барып үтерү фикеренә килдем һәм бу фикерне гамәлгә ашыру хәстәренә керештем. Бәрәкәт бирсен ки, мохитем моңа киртә булды. Китап шулай ярым-ямаулык хәлдә басылды һәм шулай булса да гадәттән тыш игътибар казанды»... «Яртысын кызыл кара белән тәмам сызылган хәлдә дә китапның укучыга тәэсире гадәттән тыш зур булды, китап берничә айда Идел буеның бөтен шәһәрләрендә, авылларында күз яшьләре белән укылды...»... «Мин бу әсәремне тулы көенчә Аурупада, йә Мисырда бастыру фикеренә килдем. Үкенечкә, моңа ирешеп булмады. Рус жандармнары өемдә тентү ясаганда, бу әсәремнең бозылмаган нөсхәсен алып киттеләр. Һәм шунда әсәр югалды да калды...»

Нәтиҗә буларак, спектакльдә статистика китерелә: Николай патша заманында 248 китап көлгә әйләндерелсә, совет заманында бу сан 100 меңгә җитә. Сәхнәдәге драматургның «Үз телəгәненңе үзең телəгәнчә язарга ярамый икән, үзеңне графоман итеп тоя башлыйсың», – дигән әлегәре иҗат ияләренең дә, бүгенгеләренең дә рухи халәтен ачык тасвирлый. Спектакль ахырында экранга чыккан Мәхмүт Галәү, Муса Бигиев, Газиз Гобәйдуллин, Хәсән Туфан, Һади Атласи, Фәтхи Бурнаш, Гали Рәхим һәм үз вакытында «зыянлы» дип табылган бүтән шәхесләребезнең исемнәре трагедиянең зурлыгын, киң колачлы булуын күрсәтә. Чынлыкта, бу исемлекне тагын дәвам итеп булыр иде. Фәүзия Бәйрәмова, Айдар Хәлим, Вахит Имамов... Көлсәң көл, көлмәсәң ела. Әмма югары цивилизациягә ирешсәк тә, вәхшилекнең һаман очы-кырые күренми. Спектакльнең жанры бер сүз белән генә билгеләнмәгән, һәм кайвакыт ул концертка да охшап куя. Солистлар ролендә – шул ук Эмиль һәм Алмаз. Егетләрнең спектакль дәвам иткән саен сәгать эчендә нинди үзгәрешләр кичерүен укучы шуннан үзе чамалар шәт. Танылган рок-музыкант Виктор Цойның татарчага тәрҗемә ителгән җырлары ирекккә омтылган җанның бәргәләнүе булып ишетелсә, күренекле язучы, җырлар авторы һәм башкаручы Зөлфәт Хәкимнекеләре милләт язмышы өчен көю булып яңгырый. Егетләрне музыка уен коралларында камил уйнарга Йосыф Бикчәнтәев өйрәткән.

К.Митанинның пьесасы үзе бер дә шомлы түгел, киресенчә, көлдереп мавыктыра торган әчтәлекле. Драматург «Ромео һәм Джульетта» нигезендә язылган әсәрен сәхнәгә кую өчен ризалык сорап килгәч, Цензорның тузга язмаган төзәтмәләрен кертеп, «Гамлет һәм Джульетта маҗаралары» дигән әсәргә барып чыга. Полиция башлыгын персонаж итеп кертергә, өч җирдә исә «Императорны ходай сакласын!» дип кыстырырга мәҗбүр була. Шул йомшаклыклары өчен Авторны театр артистлары тотып тукмый. Әмма ике ут арасында калса да, драматург бирешми, чөнки ул, чын язучы буларак, һәр нәрсәне хыял байлыгын эшкә җигеп, тәм табып эшли. Ахырдан Цензор танымаслык булып үзгәрә – иҗатта катнашу аны шул дәрәҗәдә мавыктыра ки, ул хәтта драматургны мобилизациядән саклап калу өчен тиешле органнарга хат яза, әмма соңга кала. Спектакльнең бу урыннары иҗатның көчен күрсәтә. Кеше табигатендә илаһи сыйфатларның шайтани гамәлләргә караганда өстенрәк торуын һәм барыбер бер өскә чыгуын дәлилли. Митани әсәрендәге, Җаббаров спектаклендәге кебек цензорлар: «Театрларны ябарга, труппаларны таратырга! Уен-көлке чоры түгел. Үч! Җәза! Башка берәү өчен гомереңне бирергә әзер булу! Бүген генераль линия әнә шул», – дип котырынса да, бер заман аларга да дөрес бәяне бирерләр. Ни дисәләр дә, бүген аларның әйткәннәре түгел, Камал театрындагы һәр тамаша алдыннан Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакле музыкасы яңгырый. «Зәңгәр шәл» спектакле театрның йөзек кашына әйләнде. Галәү, Исхакый, Хәсән Туфан, Муса Бигиев, Тинчурин, Дәрдемәндләр бөек һәм мәңгелек. Калганнары исә көл, көл, бары тик җилгә очкан көл генә...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Атнаның сәяси мизгелләре

КИЕРЕНКЕЛЕК КИМЕМИ

Россиянең бүген Украинада үткәрә торган махсус хәрби операция (МХО) районындагы Берләштерелгән гаскәрләр төркеме командующие С.Суровикин, хәлнең анда киеренке булып калуы, ВСУның бернichә җирдә хәтта Россия оборонасын өзәргә омтылуы турында әйтте һәм, Киев ягыннан Херсон өлкәсендә тыелган ысуллар куллану мөмкинлеген истә тотып, алга таба анда «гади булмаган карарлар» кабул итү ихтималлыгы хакында да искәртте. Икенче көнне Россия Президенты В.Путин РФ Иминлек шурасы утырышында күптән түгел Россиягә кушылган төбәкләрдә (ДНР, ЛНР, Запорожье һәм Херсон өлкәләре) 20 октябрьдән «хәрби хәл» режимы кертү турында указ имзалавы турында әйтте. Ә соңрак инде төрле дәрәҗәдәге әзерлек режимнары Россиянең башка төбәкләрендә дә кертелде.

Әлбәттә, Россия мәгълүмат чараларында элегрәк төрле дәрәҗәдә узган ишарәле (әйтик, тактик максатлы атом-төш коралын куллану шартлары турында) сүз куертулардан соң урын алган ошбу үзенчәлекле вакыйгалар чылбыры күпләрне башта чын-чынлап хафага төшерде. Узган атнада моңа Украинаның «пычрак бомба» (радиоактив зарарлау ниятендә, атом-төш калдыклары кулланып ясалган шартлаткыч) кулланырга җыенуы турындагы имеш-мимешләр дә өстәлде. РФ саклану министры С.Шойгу телефон аша бу хакта хәтта үзенең Бөекбритания, АКШ, Төркия һәм Франциядәге коллегаларына да мөрәҗәгать итте. Соңрак шундый ук кисәтүне телефон аша үз коллегаларына Генераль штаб башлыгы В.Герасимов та җиткезгән. Провокациянең максатын ул Киевнең, гаепне Россиягә аударып, дөньяда аңа каршы колачлы кампания башлау нияте белән аңлаткан. Ләкин кемнең кем булуын дөнья бүген болай да белә. Вашингтон, Париж һәм Лондон күмәк җавап бирде. Анда Киевнең үз җирендә «пычрак бомба» кулланырга җыенуы турындагы хәбәр нигезсез булуы турында әйтелә.

Башка вакыйгалардан Бөекбританиядә премьер-министрның отставкага китүен һәм аның урынына һиндлы Риши Сунак куелуын, Иркутск каласында торак йорт өстенә Су-30СМ истребителе төшүен, Украинада МХО ихтыяҗларын тәэмин итү ниятендә Россия хөкүмәте каршында координацион совет булдырылуын, шулай ук Румыниядә АКШ армиясенең 101 нче элиталы һава-десант дивизиясе урнашуын (анда 4,7 мең кеше, максаты – эскалация башланган очракта, Украинага керү) санап китәргә була. Вакыйгалар Татарстанда да бар. Татарстан Президенты Р.Миңнеханов Дәүләт Советына еллык юллама белән чыкты. Анда 2023 ел республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. ТР Дәүләт Советы ТР Конституция судын 2022 елның 31 декабреннән бетерү турында закон кабул итте. Шул ук көнне Татарстанда «президент» атамасы да бетерелә.

Фоат УРАЗАЙ.

ҮЗ СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕМ БАР

АКШта яшәүче рәссам Зөфәр Бикбов белән әңгәмә

– Зөфәр, сез сынлы сәнгатькә озак еллар буе укыдыгызмы?

– Мин тумышым белән Яшел Үзәннән. 1974 елгы. Әтием Әхәт Галләм улы лаеклы елга чыкканчы «Татгражданпроект»та баш конструктор булып эшләде. Әүвәл ул рәссамлыкка укырга теләп, Казан сынлы сәнгать училищесына да кергән булган, әмма анда ярты ел белем алгач, училищедан китеп, урта мәктәптә укуын дәвам иткән. Аннары инде Казан дәүләт төзелеш-инженерлык институтын тәмамлаган. Инженер буларак төрле төзелешләрдә катнашкан, соңрак ул Яшел Үзәндә төпләнеп, «Татгражданпроект»ның шундагы остаханәсендә эшләде. Буш вакытта рәсемнәр дә ясады. Әниебез Әлфинур Гыйльметдин кызы шәфкать туташы булып хезмәт куйды. Ул Яшел Үзәннең балалар сырхауханәсе системасында эшләде, аннары мәктәптә шәфкать туташы булды. Әти-әнием күптән лаеклы ялда. Гаиләдә без өч бала үстек. Апам Зөлфия – икътисадчы, ә сеңлем Зифа бүген минем онлайн сәнгать проектымны алып баруда катнаша.

Рәсем ясау серләренә калабызның балалар сынлы сәнгать мәктәбендә төшендем. Укытучылардан рәссам Юнис Галимов дәресләре истә калган. Ә болай 3 нче мәктәп-гимназиядә физика-математика фәннәре буенча махсус сыйныфта белем алдым. Бар төр олимпиадаларда катнашып, күп җиңүләр яуладым. Мәктәптән соң Казан дәүләт төзелеш-инженерлык институтына да һәм Казан дәүләт медицина институтына да үттем. Табиблекне сайладым да, дәвалау факультетында укый башладым. Һәр көн Яшел Үзәннән Казанга укырга барып йөрү авырга туры килде килүен, ә бер елны, тулай торакта яшәргә мөмкинлек тугач, картиналар ясап, аларны сата да башладым. Рәссамнар белән аралаштым. Россия Һөнәри рәссамнар берлегенең Татарстан бүлегенә кабул ителдем, берничә күргәзмәдә катнаштым. Институтның «Казанский медик» газетасында да эшләдем, мәкаләләр яздым, карикатуралар һәм рәсемнәр ясадым. Институты тәмамлагач, онкология белгечлеге буенча ординатурга укырга кердем һәм өч ел ярым Казан онкология диспансерында эшләдем. РКБда да гыйлем тупладым. Исемдә әле, 2003 елда Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда «Табибләр ясый» дип аталган күмәк күргәзмәдә дә теләп катнашкан идем.

– Зөфәр, АКШка китү тарихыгыз нинди?

– 1996 еллар тирәсендә безнең университеттә АКШның Йель университеты профессоры, доктор Маджиг Садиг лекцияләр укыды. Шулай итеп алмашу программасы башланып китте. Америка акчасына профессорлар, ординаторлар биредәге авыруларны тикшерергә булышты, лекцияләр укыды, консультацияләр үткәрде. Шулай ук Америка акчасына – грантларга Йель университеты программасы буенча кафедра

● Әнкәй йорты.

хезмәткәрләрен үзләренә дә чакырдылар. Хирургия һәм онкология буенча ординатурада беренче ел укыган чагымда онколог программасында катнашырга чакыру килде. Инглизчә яхшы аралаша идем. Кафедра хезмәткәре буларак, 2000 елда АКШның командалы медицина эшенә өйрәнер өчен чит дәүләткә киттем. Аларда бит авыруны дәвалауны тулы бер команда: студент-медик + интерн + ординатор + кафедра ассистенты бергәләп алып бара. Бу программаның яртысына төшенгәч, гаиләм белән бәйле сәбәпләр аркасында, ватанга кайттым. Программаның икенче яртысын 2001 елда үттем. Ординатураны тәмамлагач, аспирантурада укый башладым. Бу чорда дежурлыкта да булдым, картиналар язып та саттым. Тик кандидатлык диссертациясе темасы перспективалы түгел кебек тоелды, реактивлар да юк иде, акча да таләп ителде... Шулчак АКШка китеп, алардагы имтиханнарны тапшырып карарга булдым. Янсә медицина иллюстраторы булып эшләрмен дип уйладым. Биредәге аспирантураны калдырдым. 2004 ел башланыр алдыннан гына АКШка киттем, берничә айдан соң җәмәгатем Лилия һәм кечкенә кызыбыз Кадрия дә биргә килде. Имтиханнарга әзерләнгән чорда гаилә тормышын алып барырга кирәк иде. Миңа килгән бер хатта: кем Россиядә табиб булып эшләгән, биредә урта медицина хезмәтендә эшләү өчен уку курсын тәмамлый ала дип язылган иде. Мин дә имтиханнар тапшырып, лицензия алдым һәм эшли дә башладым. Ә АКШтагы урта медперсонал Россия белән чагыштырганда күбрәк ихтирамга лаек. АКШта урта медперсонал булырга уку – ул азрак вакыт һәм азрак акча сарыф итеп яхшы белем туплау юлы. Күпләр өчен бу урта хәлле катламга чыгарга булышлык итә торган менә дигән социаль лифт. Әмма моның өчен ун ел вакыт таләп ителә. Әгәр дә дәүләт кешенең акыллы, сәләтле икәнен күрсә, ул аны тагын да укыта, стипендия дә түли ала. Ә менә табиб булыр өчен инде күбрәк вакыт кирәк... Шәфкать туташы булырга теләүчеләр уку чорында ук гаилә дә кора ала, ә менә табиблеккә укучы хатын-кызлар укый башлап, ординатура бетергәнче гаилә кормый, чөнки алар хакында «еллар буе хастаханәдә яши» дисәң дә була, аларның аннан чыгарга вакытлары да юк, 18 шәр сәгать эшлиләр, практика үтәләр, фәнни хезмәтләр язалар.

Шушы чорда да мин сынлы сәнгать белән шөгыльләндем, заказлар буенча картиналар ясадым һәм минем рәссамлык карьерам үсеш алды. Ахыр чиктә, ул медицина буенча планнарымны һәм карьерамны узып китте. Мин рәссам һөнәрендә булырга кирәк дигән карарга килдем. Картиналары сатылып торган иҗатчы монда барыбер яхшырак яши. Ләкин ул елларда АКШта рәссам буларак мәгълүм түгел идем әле. Билгеле, дусларым бар иде инде. Мин хәзер дә дипломымны, якланган лицензиямне югалтмас өчен, аена ике тапкыр клиникада эшләп кайтам. Бу – социаль яклау таләп ителгән очрак килеп чыкса дигән фикергә таянып эшләвем. Иртәгәсе көн ничек үзгәрер, бу хакта беркем дә алдан белми. Ә урта медперсонал госпитальләргә һәрчак кирәк.

Хәзер мин АКШның төрле почмакларына сәяхәт итәм, анда яшәүчеләргә дә картиналарым мәгълүм булуын беләм. Әлбәттә, интернет та булышлык итә. Рәссамлыгым биредә, ор-

● Хоорнда өйләдән соң.

●Күл өстендә.

●Зобәрҗәт үзәнлек буйлап.

● Якшәмбе таңы.

●Болдер иртәсе.

●Октябрьнең киң сулышы.

динатура бетереп, табиблыкта эшли башлап, лаеклы ялга чыгу вакытын зарыгып көткәнгә караганда, яхшырак план булып чыкты. Аннары... рәссамнар бит лаеклы ялга да чыкмый, алар гел картина ясау белән мәшгуль!

– Димәк, АКШта рәссам булып яшәү барыбер дә җиңелрәк дип саныйсыз...

– АКШка беренче тапкыр килгәннән бирле иҗат эшендә мин. Бу дәүләттә үз сәләтеңне күрсәтү өчен мөмкинлекләр күп. АКШта төрле яшьтәге төркемнәр үз хезмәтләрен экспозицияли. Рәсем ясау белән мавыгучылар саны биредә арта гына бара. Дөрес, соңгы 10-15 елда Россиядә дә сәнгать белән кызыксынучылар саны үсте. Биредә бик күпләр лаеклы ялга чыккач та укырга тели. Алар үз күргәзмә мәйданчыклары булган төрле арт-ассоциацияләрдә теркәлә, шулай итеп үз картиналарын башкалар игътибарына тәкъдим итә.

Мин – ирекле рәссам. Биредә укымадым, бернинди дәресләр дә алмадым. Бар уңышым Яшел Үзән балалар сынлы сәнгать мәктәбендә алган белемнәремә, Аллаһ Тәгалә насыйп иткән сәләтләремә һәм үзем арттырган тырышлыгыма, гыйлемлегемә нигезләнә.

Сәләтләрең булса, АКШта картиналар сатып яшәп була. Тик бар да чагыштырмача, һәрхәлдә, бер генә картина язып, шуны саткан акчага бер ел буе яшәп булмый, билгеле. Мин дә күп хезмәт куям, күп картиналар иҗат итәм. Көндәшлек бар, яхшырак ясаган саен, башка иҗатчыларны да артта калдырасың, тик моның өчен маркетинг белән дә активрак шөгыльләнергә, күбрәк күргәзмәләрдә катнашырга, үз белемеңне арттырырга, күбрәк укырга туры килә. Әйе, Россия белән чагыштырганда, монда рәссамнар бихисап, әмма, уртача алганда, аларның иҗат дәрәҗәсе Россия рәссамнарыныкына караганда түбәнрәк. Биредә галереялар да күп. Лаеклы ялга чыккан хәлләләр калаларда яшәми, күп очракта аларерактарак урнашкан авылларда төпләнә һәм бергә җыелышып ни белән булса да шөгыльләнә башлый. Алардан күпкә баераклар тагын да активрак, мондыйлар җирле китапханәләр базасында очрашулар үткәрә, арт-ассоциацияләр ача, бераздан үзара акча җыешып, берәр артүзәк тә төзеп куялар һәм шунда рәсем ясарга өйрәнәләр, оста рәссамнарны да чакыралар... Укыту белән дә шөгыльләнүче рәссамнар, һичшиксез, тагын да тотрыклырак тормышта яши. Әлеге дәүләттә коллекционерлар да җитәрлек. Сәнгать базары да зур. Чөнки сынлы сәнгатьне үз итүчеләр күп. Шуңа күрә дә киң даирә иҗатчылар тук тормышта яши ала. Үземнең дә онлайн режимда эшләүче «Russera» мәктәп-студиям бар.

– Табиб булуыгызның да кирәге чыгамы соң?

– Медицина буенча белемнәрем миңа һәрчак булышлык итә. Катлаулы хәлгә калган дусларыма ярдәм итәм, кайсы очракларда гына хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә киңәклеген аңлатам. Мин медицина өлкәсендә инглиз телен бик яхшы беләм һәм еш кына берәр дустым, авыру пациент буларак, үз табибына аңлата алмаганны аның урынына бик яхшылап аңлатып та бирәм.

Рәссамнар төркеме пленэрга юнәлгәндә дә, һөнәри белемнәремнең кирәге чыккалый. Үз укытучыларының табиб икәнен белүләре аларның күңелләренә ышаныч, тынычлык хисе өсти.

– Зөфәр, сезнең пейзажларыгыз искиткеч матур! Ни өчен сез шушы юнәлештә генә иҗат итәсез?

– Пейзажларны яратып язам. Әлеге юнәлеш күңелемне алга этәрә. Әмма үз иҗатыма һәрчак тәнкыйть күзлегеннән чыгып карыйм. Мин тарих белән дә кызыксынам, шуңа күрә тарихи мизгелле, сюжетлы әсәрләр дә язасым килә. Киләчәктә, бәлкем, Татарстан тарихы белән бәйле әсәрләргә дә алынырмын.

Пейзаж ясаганда гомуми эстетиканы барлыйм. Аның композициясенә кеше эшчәнлеге сиземләнгән архитектура күренеше дә керә ала, кырлар да, төрле сулыклар да... Табигать күренешләре, ни дисәң дә – чиксез илһам чыганагы. Өстәвенә, биредәге тормышым илне өйрәнү белән дә бәйле. Гадәттә, җирле рәссамнар автомобильгә киндерләр, буяулар төяп, бер җирдән икенче җиргә күчеп йөри. Ә сәяхәтләр... һәр рәссамның да диярлек алдан корылган иҗади планы буенча бара. Өстәвенә, мин сәнгатьне башка талантлы кешеләр белән танышырга мөмкинлек бирүе өчен дә ошатам!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ӘНӘК АВЫЛЫ

Тарихчы-галим Таһир Кәримов 90 нчы еллардан бирле Көнчыгыш Кама аръягы һәм Башкортстан татарлары тарихын өйрәнә, яңа ачышлар ясый. Фәнни әйләнешкә татар җир олыслары («татарские поземельные волости») гыйбарәсен керткән, аларга багышланган күптомлы китапларын басмага әзерләгән. Шуларның берсе, яз көне үк әзер булып та, бүгенгәчә дөнья күрми ятканы – «Президент авылы». 2023 елда нигезләнүенә 325 ел тулачак Әнәккә багышланган бу зур фәнни хезмәте билгесез калмасын, дип, өлешләп булса да, аны «Мәдәни җомга» газетасы укучыларына тәкъдим итә.

АВЫЛНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Кама аръягы – аз өйрәнелгән, татарның җир олыслары кебек уникаль тарихы булган төбәкләрнең берсе. Вотчина-биләмә ияләре рөхсәте яисә аннан башка килеп утырган халыктан торган җир олыслары Казан ханлыгы чорыннан ук яшәп килгән, хөкүмәткә даими салым (ясак) түләп баруны тәэмин иткән. Җир олыслары зур, үзәк авыл исеме белән аталган, кайда яшәвенә карамастан биләмәчеләр дә кайбер очракта үзләрен шул авылдан дип күрсәтә торган булган. Әнәк һәм дистәләрчә татар авылларының башлангыч чоры Казан ханлыгына тоташкан Мөшегә җир олысы биләмәләрендә барлыкка килгән. Соңыннан ул Бүләр җир олысына кушылып, аның Мөшегә төбәгенә (урыс чыганакларында «тюба») әйләнә.

МӨШЕГӘ ҖИР ОЛЫСЫ БИЛӘМӘЛӘРЕ

Җир олыслары эзлекле өйрәнелмәү аркасында, Көнчыгыш Кама аръягы тарихы «ак таплар» тулы татар төбәкләренең берсе булып кала. Җир олыслары кайчан, нинди шартларда барлыкка килгәнен, аларның үзенчәлекләрен, үсешен ачыкламыйча, төбәк тарихын тулысынча белү мөмкин түгел. Җир олыслары тарихы – татарның «башкорт» (чыганакларда «башкирец», «башкирцы») дип аталган шактый зур санлы сословиесе барлыкка килү тарихы да ул. Бу сословиенең ничек һәм кайчан барлыкка килү механизмы Мөшегә җир олысы (төбәге) тарихында аеруча тулы чагыла.

Әнәк авылы барлыкка килгән Мөшегә җир олысында биләмә ияләре Казан ханлыгы чорыннан бирле яшәп, 1523 елда Сәхипгәрәй хан биргән тархан ярлыгына таянып җир биләп килгән. Бу хакта әледән-әле булып торган җир бәхәсләре вакытында пәйда булган документлар сөйли.

Сәхипгәрәй хан ярлыгын алган тарханнарның варислары Актаныш-Минзәлә якларында гына түгел, хәзерге Туймазы районы территориясендәге Исламбакты авылында да яшәгән (Мустакимов И.А. Еще раз о казанском ярлыке хана Сахиб-Гирея//Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Выпуск 5. Казань, 2013). Бу тарханнарның варислары хәтта XVIII гасыр башында да ясаклы татар сословиесендә булып, бары шул гасыр уртасы-ахырларына гына «башкорт» дип языла. Бу – тарихи, күп чыганакларга нигезләнгән хакыйкать. Архив документлары җир олысларында биләмәләргә ия булып яшәүче барлык татарларның сословиесен «башкорт» дип язу традициясе нәкъ шул XVIII гасырда тамыр җәюен күрсәтә. Бу хакта аз язылганлыктан һәм чыганакларны белмәгәнлектән, бер Казан тарихчысы «башкорт» дип аталучыларның этник ягын ачыклау мөмкин түгел, дигән сәер нәтиҗә ясап куя.

Казанда Сәхипгәрәй хан ярлыгын алган тарханнарның варислары булган Мөшегә җир олысы (төбәге) биләмәчеләре архив документларында кайчаннан һәм кайчанга чаклы телгә алына соң? Архив документларын хронологик тәртиптә карыйк.

Әлеге биләмәчеләр беренче тапкыр датасы куелмаган документта чама белән 7165 [1657] елда телгә алына (Бу саклау берәмлегендә («дело»да) әлеге дата башка авыллар буенча күрсәтелә, шуннан чыгып документ («челобитная») 1657 елга карый дип әйтә алабыз). Патша исеменә үтенечләрендә алар түбәндәгеләрне язалар. «Деревни **Именчеевы**, что по речке Мушуге **ясачные бобыли чюваша** Юкачейка да Акешка да Иликейка Доскеевы, Бекчюрка Ахмаметев, Урка Баимбетев, Келмячко Ишеев, вотчина г[осу]д[а]рь у нас старинная дедов и отцов наших в Уфинском уезде река Ику по обе стороны нижняя межа подле Ику реки на Уфинской стороне устъ речки Бозяны Юту Наратас, а верхнея межа в вершине речки Бол[ь]шой Вереш, а с вершины и до устья, где [в]пала в Ик реку, а с вершины речки Бол[ь] шой Вереш на вершину же речку Мушуги на Минскую дорогу бортной ухожей и всякие звериные и рыбные ловли и всякие угодья на дватцать версту да в той г[осу]д[а]рь нашей вотчине речка Осы исток…и иные многие речки малые, которые пали в Ыкъ реку и в Бозяну и в бол[ь]шую речку Верешъ и озера и истоки и заводи и старицы, и с той г[осу]д[а] рь вотчины платим мы сироты твои в твою великого г[осу]д[а]ря казну в Казан[ь] ясаку по рублю да на Уфу з земли **бобыльсково ясаку** по десяти куниц да двадцат[ь] шест[ь] алтын четыре д[е]н[ь]ги на год. Вели г[осу]д[а]рь с меня Калмычка снят[ь] и из окладу выложить, а мы сироты твои ухнем в твою великого г[осу] д[а]ря казну сверх прежнего бобыли[ь]ского ясаку в **окладной ясак** внов[ь] платит[ь] по ш[ес]ти куниц на год и в ясачные кн[и]ги и от ново прибылой ясак написать, а денежной ясак, который мы платим в Казани великий г[осу]д[а]рь, платить по прежнему в Казани по рублю на год. <…> Ясаку учнем платить на Уфу в твою г[осу]д[а]ря по три куницы с человека, итого на год осьмнатцат[ь] куниц. Вели г[осу]д[а]рь дат[ь] нам сиротам твоим свою великого г[осу]д[а]ря **обрегал[ь] ную памят[ь]**, чтоб нам ни от кого насил[ь] ства не было. Царь г[осу]д[а]рь смилуйся» (РБАДА, 1173 ф., 1 тасв., 468 сакл. бер., 1 б.) Мөшегә елгасы буендагы Имәнче авылыннан Юкачи До[с]кеев һәм аның иптәшләре 7166 [1658] елгы документта да телгә алына. Алар Ык буендагы биләмәләреннән сусар ясагын түләүне туктатуны (чыганакта «о снятии кунного ясака с вотчины их по Ику реке») сорый (кара: Шунда ук,470 сакл. бер.).

Бу документның төп әһәмияте шунда, монда татар биләмәчеләренең борын-борыннан яшәп, буыннан-буынга күчеп килгән һәм хуҗалык иткән җирләренең



● **Документ фрагментында Акеш, Илекәй, Бикчура, Уркә, Килмәк тамгалары.**

чикләре күрсәтелә. Ык, Бәҗәнә, Олы Вәрәш, Усы («Осы») елгалары, башка кечкенә елгалар һәм күлләр 1657 елда «бобыль-чуаш» дип аталган биләмәчеләрнең зур территориягә хуҗа булып яшәвен күрсәтә. Соңрак болар – ясаклы татарлар, ә XIX гасыр башыннан ревизия документларында аларның варислары бары тик «башкорт» дип язылачак.

Әлеге биләмәчеләрнең «бобыль» ясагыннан окладлы ясакка («окладной ясак») күчү факты да зур игътибарга лаек. Элек алар Уфага ел саен 10 сусар тиресе белән түләсә, хәзер аны 18 гә җиткерергә тиеш була (Казанга акчалата ясак түләү дә саклана). Шул чордан **(1657 ел)** алар **«бобыль» булудан туктый, юридик яктан окладлы (ясаклы) «башкорт» булып китә.** Хәзер аларны беркем дә «бобыль» дип әйтә алмый, әмма «башкорт» сословиесен аңлатучы термин ныклап гамәлгә кергәнче, алар һәм аларның балалары ясаклы татарлар дип аталачак, бары оныкларына гына XIXгасыр башы халык санын алуларда «башкорт» ярлыгы тагылачак.

Патшага үтенеч белән мөрәҗәгать итүче Акеш, Илекәй, Бикчура, Уркә, Килмәк бу документка үзләренең тамгаларын салган. Бер нәселдән булганга, аларның тамгалары тәңгәл килә. Шундый ук тамганы Кыр-Елан олысына керүче Исламбакты авылының биләмәчеләреннән торган бер нәселендә дә күрәбез. Алар да хаклы рәвештә үзләрен Сәхипгәрәй хан ярлыгында телгә алынган тарханнар токымыннан дип саный. Бүген ул авыл Башкортстанның Ярмәкәй районына керә. Бер нәсел кешеләре менә кайларга чаклы таралып, татарның бердәм этномәдәни тирәлеген булдырып яшәгән!

Күпмедер вакыттан югарыда санап үтелгән биләмәчеләр – «бобыль»ләр ясаклы татар дип аталачак һәм аларга карата сословиене аңлатучы «чуаш» дигән термин башкача кулланылмаячак. Шунда аларның яңа авылы Мөшегә булачак, ә Имәнчедә башка «бобыль»ләр яшәячәк.

Бу тарихи факт «бобыль» статусындагы татарларның ничек итеп тулы хокуклы биләмәчеләр – «башкорт»лар булып китүен күрсәтүче типик мисал итеп карала ала. Үтенечләр җиргә хокукларын тагын да ныгыту максатыннан, патшадан русча «оберегательная память» дип аталган документ бирүен сораган. Мөһер сугылган мондый рәсми кәгазь булганда, аларның биләмәләренә башкалар кул суза алмый, ышанычлырак та була. Бу документның исеменә ук «саклый торган» дигән мәгънә салынган, әмма ул еш кына «владенная память», ягъни «җиргә хокук бирүче» дип тә атала.

Аеруча кызыксыну уяткан Сәхипгәрәй хан ярлыгы турында тулырак әйтеп үтик. Аның хакында мөшегәлеләрнең ирәктелеләр белән җир бәхәсе уңаеннан әйтелә. Беренчеләренең биләмәләргә хокукларын раслап 1680 елда патша указы кабул ителә. Документның русча текстын китерәбез: «В [7]188 [1680] г. *«по указу великого г[осу] д[а]ря прислана великого г[осу]д[а]ря грамота, велено Уфинского уезду Казанской дороги деревни Мушуги* ***ясачным татарам*** *Акешке Доскееву с товарищи вотчиною по Ику реке, которою владели отцы их и они по крепостям девят[ь]сот двтцет[ь] девятого да семь тысяч восем[ь]десят пятого годов (929 (Хиҗри ел исәбе буенча) [1523]г. и 7085[1577] г. – Т.К.), владет[ь] им по прежнему,<…>а уфинским башкирцам Каракуске Аканаеву с товарищи в той вотчине отказат[ь]»* (РБАДА,1173 ф.,1 тасв., 767 сакл. бер., 10 б.).

Әйтергә кирәк, җир бәхәсен мөшегәлеләр файдасына шулай хәл иткәнче, хакимият мәсьәләне җентекләп өйрәнә. Бу хакта 1678 елның 20 маена караган документта болай әйтелә (монысын да татарчага тәрҗемә итми китерәбез): *«Спорною вотчиною по Ику реке которою владели Акешка с товарыщи отцы их и они по крепостям 929 [1523] и 7085 [1577] годов, велено владеть им Акешку с товарыщи по прежнему да и потому им тою вотчиною владеть на Уфе в ясачных книгах та вотчина написана за*

● Әнәк авылында Татарстанның беренче Президенты, РФ Хезмәт Герое Минтимер Шәймиевнең бюстын ачу тантанасы күренеше.



● Текстта эчтәлеге китерелгән 1680 елгы документ фрагменты. Өске өлеше «Казанские дороги деревни Мушуги ясачным татарам», дип башлана.

ними и в сыску обыскные люди сказали, что та вотчина их Акешкова с товарыщи, а не башкирская». Воевода П.Д. Скуратов (1679 елның көзеннән 1680/81 чаклы Уфа воеводасы була) боерыгын китерәбез: *«в Уфинской уезд в вотчину ясашных татар Акешка Доскеева с товарыщи чем владели деды и отцы их и они, послать кого пригоже»* (Бу документта тагын шундый юллар бар: «окольничей и воевода Петр Дмитреевич Скуратов велел уфинцу Ивану Кириловичу Нарматцкому, да с ним приказные избы подьячему Ивану Антропову ехать в Уфинской уезд на Ике реку в вотчину Казанской дороги дрвни Мушуги ясашных татар Акешка Доскеева, да Мурзакайка Юкачеева, да новокрещена Данилка Иванова»), а *«приехавв той вотчине межи и грани и урочища и с чьеми вотчинами смежна описать<...>, и описав велеть им Акешку с товарыщи тою вотчиною владеть и ясак платить по прежнему, чтоб впредь о том челобитья не было»* (РБАДА,1173 ф.,1 тасв., 769 сакл. бер., 2-4 б.).

Әлеге өземтәдән күренгәнчә, биләмәчеләр Акеш һәм аның иптәшләре ясаклы татарлар, ирәктелеләр «башкорт» дип язылган. Шунысы әһәмиятле, беренчеләренә карата элеккеге кебек «бобыль» термины кулланылмый. «Бобыль»дән соң туп-туры «башкорт» дип аталмауларының сәбәбе, аларның Казан ханлыгы чоры һәм тархан ярлыгы белән эзлеклеләгән, аларның үзенчәлеген күрсәтүдән килә. Этномәдәни яктан гына түгел, юридик яктан да алар төбәктәге «башкорт»тан аерылмый, алар белән беррәттән окладлы ясак түләүдән тыш, патша походларына да җәлеп ителә. Алар нәселенә карата фәкать сословиене аңлатучы «башкорт» термины кулланыла башланганчы шактый вакыт үтә.

Мөшегәлеләрнең Ирәкте олысы биләмәчесе Каракүз Аканаев белән җир бәхәсен чагылдырган 7188 [1680] елгы документ башка чыганакларда да телгә алына. Сәхипгәрәй хан биргән тархан ярлыгы Акеш Доскәевтә сакланган, ә аңа бабасыннан мирас булып калган. *«Вотчина <...> написана в Казани в прежних ясашных книгах по сиюКазанского взятия в первых летах, а у него же Акешки Доскеева с товарищи на ту вотчину до Казанского взятия,* **как в Казани был татарский царь и тогда вотчину дал владеть деду его Доскену Белякову** *и дал жалованную грамоту и та де грамота татарская у него Акешки».* Алар казнага зур күләмдә ясак түләгән (бу хакта болай әйтелә: *«ясаку в Казань и на Уфе по тредцати по три (33. – Т.К.) куницы да в Казани же сверхъ того денег по шести рублев, по двадцати по три (23. – Т.К.) алтына по две деньги по десяти батманов медуна год»* (БР МА, И-10 ф., 1 тасв., 1545 сакл. бер., 219-219 б. а.). Бу чыганакта да аларның Бүләр олысына караганлыгы хакында бер сүз әйтелми.

1700 елда Морзакай Юкачев һәм аның биләмәләрендә 20 дән артык авыл булып урнашкан бобыль сословиесендәге татар һәм марилар белән бәхәс килеп чыга. Биләмәче патша исеменә хат яза, гозерендә аларны үз җирләреннән куып җибәрүне сорый, җәбер-золымга дучар иткәннәр, имеш. Әммә аның үтенече канәгатьләндерелми, киресенчә, бу бәхәс «бобыль»ләр файдасына тәмамлана, алар 1701 елда патшадан «оберегательная память» дип аталучы документ алуга ирешә. Әнәккә дә кагылышлы бу документ турында XIX гасыр чыганакларында берничә тапкыр әйтелә, аның эчтәлеген белмәүчеләр авыл 1701 елда нигезләнгән дигән ялгыш нәтиҗәгә килә.

Морзакай Юкачевка кайтыйк. Бер тапкыр ул Мөшегә авылы татары, икенче тапкыр – шул ук авылның ясаклы татары (Шунда ук, 1325 сакл. бер., 36 б.), өченче тапкырында – Айман авылы ясаклы татары (Шунда ук,39 б. Чыганакта «деревни Аймановы ясашной татарин» дип язылган) дип атала. Соңгы авыл аның төп яшәү урыны булып китә, оныклары да шунда гомер итә.

ӘНӘККӘ КАЙЧАН, КЕМНӘР НИГЕЗ САЛГАН?

Әнәк авылы югарыда әйтеп үткән Морзакай Юкачев белән бәйле 1701 елгы документта беренче тапкыр телгә алына. Әлеге чыганакта анда яшәүче Юлай Мәкәев бер урында ялгыш Пучы авылыныкы (5 нче биттә), икенче урында Күҗәкәнеке (23, 36, 39 битләрдә) дип күрсәтелә. Соңгы авыл Күҗәгол дип тә язылa, бу атаманың шундый кеше исеме белән бәйле булуын күрсәтә. Документның бары 24 нче һәм 26 нчы битләрендә генә Юлай Мәкәев Әнәк авылы кешесе буларак телгә алына.

Әнә шул Күҗәкә авылы кешесе дип күрсәтелгән Юлай Мәкәев 1701 елда хакимият вәкиленең соравына(допросына) түбәндәгеләрне әйтә. Аның авылында барысы 5 хуҗалык, аларның Пучыдан бүленеп чыгып, яңа урынга (Әнәккә) күчкәннәренә өченче ел киткән (Чыганакта болай язылган: "Д[е]р[е]вни Кузекиной Юлайка Мякеев в допросе сказал: в д[е]р[е]вне ево всего пят[ь] дворов, а поселились тою д[е]р[е]внею тому н[ы]не третей год, отделилис[ь] от деревни Поюсевы" (РБАДА, 1173 ф., 1 тасв., 1325 сакл бер., 23 б.).

Әлеге кыска мәгълүмат авылга кайчан һәм ничек барлыкка килүенә ачыклык кертергә ярдәм итә. Күргәнебезчә, Әнәккә 1698 елда пучылылар нигез салган, күченгән 5 хуҗалыкның берсе Юлай Мәкәевнеке була. Калган хуҗалык башлыкларының исемнәре күрсәтелми, шуңа да карамастан, аларның берсе Әнәк исемле, яңа барлыкка килгән авыл аның исеме белән аталган дип фараз кылабыз.

Юлай белән Әнәкнең һәм калган 3 хуҗалыкны тәшкил иткән кешеләрнең уллары 1762 елгы ревизия исемлегендә күрсәтелә.

Әнәкне нигезләүчеләр Пучыдан күченгәнче хөкүмәткә 40 ел «бобыль» ясагы түләп яшәгән, шуңа «бобыль»ләр дип аталган. Морзакай Юкачев биләмәләрендә яшәүләренә карамастан, мондый ясак түләү аларның аңа бәйле булмауларын күрсәтә. Алар иген иккән, печән чапкан, утынлыкка урман кискән, әмма моның өчен Морзакайга түгел, ә хөкүмәткә 40 ел буена ясак дип аталган салым түләп барган. Әмма Морзакай биләмәләрендә җәнлек-кошлар ауларга, умарта тотарга хокуклары булмаган, моның өчен аның үзеннән рөхсәт алырга, аңа оброк түләргә кирәк булган.

Чыганакта күп очракта «бобыль»ләр дип аталсалар, кайбер очракта аларның милләте, Морзакай Юкачевныкы кебек, татар дип күрсәтелә (РБАДА, 1173 ф., 1 тасв., 1325 сакл бер.,23 б.).

Шулай итеп «бобыль» сословиесендәге татарлар 1698 елда Әнәккә нигез сала. Бу сословие кешеләрен гадәттә Казан өязеннән күчеп килүчеләр тәшкил иткән, 1760 елгы чыганакта Әнәк авылы кешеләренең ясаклы татар дип аталуы шуңа ишарәли.

АВЫЛ 1762-1795 ЕЛЛАРДА

1762 елда Россиядә хакимияткә Екатерина II килә. 1762-1796 елларда илнең үсеше аның эшчәнлеге белән бәйле. Кайбер либераль үзгәрешләрдән башлап, Крестьяннар сугышы (1773-1775 еллар) кебек дәһшәтле вакыйгадан соң, аның сәясәте кискен төсмер ала, цензураны көчәйтүгә китерә.

Моңарчы көчләп чукындырулардан иза чиккән татар халкы патшабикәдән кайбер мәрхәмәтлекләр күрә. Мәчетләрне явызларча җимерүдән туктаткан, яңа мәчетләр салырга рөхсәт биргән һәм кайбер башка яхшылыклар эшләгән бу затка күңеле булып, халык аны «Әби патша» дип атый башлый.

1762 елгы Әнәк авылы ир-атлары исемлегеннән бу чорда кемнәр яшәвен, авыл нинди зурлыкта булуын беләбез. Гасыр ахырында (1795 ел) үткән халык санын алу авылдагы демографик үзгәрешләрне чагылдыра.

ЯҢА ҖИРЛӘР ЭЗЛӘП – НОГАЙ ЮЛЫНА

Әнәк авылы барлыкка килгән чордан алып, административ яктан Уфа өязенең Казан юлына карый. Казан юлындагы авылларда гомер итүче татарлар әлеге өязнең башка юлларында, аерым алганда, Ногай юлында яшәүче милләттәшләре белән тыгыз элемтәдә була. Шундый ук менталитетлы, гореф-гадәтле төрле авыл халыклары чын мәгънәсендә бердәм татар этнокультур бушлыкта (пространствода) яшиләр. Уфа өязенең кайсы төбәгендә яшәүләренә карамастан, алар бер-берсе белән даими аралашкан, кызлар бирешкән. Боларны раслаучы фактлар 1762 һәм 1795 елгы ревизия документларында, соңрак метрикә кенәгәләрендә дә чагылыш таба.

Яиксуба-Мин олысы биләмәчеләре белән договор һәм Уфа провинциаль канцеляриясенең 1760 елның 16 мартындагы указы нигезендә Ногай юлына старшина Мәксүт Морзакаев (Байлар олысындагы Таулар авылыннан. 1782 елда типтәр сословиесенә караучы 20 авыл (шул исәптән Торынтаеш) кешеләре старшинасы дип күрсәтелә (кара: Татары Уфимского уезда. Казань, 2021, 164 б.) һәм ясаклы татарлар Мәсәй Морзин, Шәрипкол Илкин, Мөкмин һәм Ярмөхәммәт Йозаевлар, Ибрай Ишкенин, Ибрай Тохтаров (Әнәктән; чыганакта «Яняково»), Рыкай Биганов, Мәсәй Йосыпов, Шәрип Юлдашев, Габделкәрим Әлмәкәев (Пучыдан; «Моисеево»), Мансур һәм Абдулла Сырмәтовлар, Кинҗә һәм Юлдаш Мәмәдәлиннар (Шәйчурадан), Арыслан Аймәтов (Мухан авылыннан; «Муханово»), Хоҗәмкол һәм Рәфикъ Колмәтовлар, Искәндәр Хәлилов (Бүләр авылыннан; старшина Минәй Бикбовов командасына карыйлар), Әлмәкәй Ишмәтов, Ишәнәй Бикмәтов (Тузганабикә авылыннан), Тимеркәй и Гомәр Ирмәкәевлар, Яркәй Досаев (Маткауш-Тамак авылыннан), мулла [Х]әсән Әлмөхәммәтов (Бикбау авылыннан; старшина Уразмәт Йосыпов командасына карыйлар), Чүнәй Такаев (Таулар авылында туып-үскән), Кыяз Ибраев (Туер авылыннан; «Таирово») һәм Тләммәт Аблаев (Псәй авылыннан; «Псеево»). Соңгылары Байлар олысы старшина Сөендек Тукбаев командасында тора (МИБ. Т. 4, Ч. 2, стр. 28-30). Алар Торынтаеш елгасы буена килеп утырган, шул исемдәге авылга нигез салучылар булып тора (бүгенге көндә Башкортстанның Әлшәй районына карый). Күренгәнчә, көчеп утыручыларның күпчелеген Әнәк, Пучы, Шәйчура, Мухан һәм Бүләр авылларына караучы һәм Бүләр олысына керүче ясаклы татарлар тәшкил итә.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ.

Бәгәрәктамакта

Чиләбе өлкәсендәге Бәгәрәктамак авылында зур бәйрәм тантаналары гөрләде: биредә мәктәпнең 100 еллык бәйрәмен билгеләп үттеләр һәм мәктәпнең беренче директоры Җамалетдин Сираҗетдин улы Камаловка истәлек тактасы куелды. Шушы көнне үк Бөтендөнья татар конгрессы каршында Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, академик Альберт Борһанов җитәкчелегендә татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең «Урал ягы татарлары: тарих һәм заман» VII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе утырышлары узды.

●Кунакларны каршы алу. Алгы планда мәктәп директоры Фидалия Кәримова.

●Альберт Борһанов һәм автор Валерий Хәмитов мемориаль тактаны ача.

●Коншак районы башлыгы Сибгатулла Әминов физкультура укытучысы, хезмәт ветераны Гайфулла Гайнуллинны котлый.

Авылны кешеләр нурлый

Бәгәрәктамак төбәкне өйрәнүчеләрне, журналистларны житеш тормышлы йортлары, бизәкле тәрәзә йөзлекләре, буяулы капка-коймалары белән каршы алды. Авыл Чиләбе өлкәсендәге Коншак районының төньяк-көнчыгыш өлешендә аккан Сәнәр елгасына Бәгәрәк кушылган урында урнашкан. Аны Түбәнавыл, Яңавыл дип тә йөртәләр. Бәгәрәктамакның урман-суларга бай табигате дә сокланып туймаслык. Авыл урнашкан тирәлектә 15 табигый күл булуы бу якларның ямен һәм гүзәллеген тагын да арттыра. Ә инде авылдан ике чакрым ераклыктагы Мәһәди таш авылга серлелек өсти. Бәгәрәктамак беренче тапкыр, 1708 елгы рәсми документларда Пермь губернасы Шадрин өязе Катай волостена караган Яңавыл буларак искә алына. Бәгәрәктамакның тарихы да шул вакыттан алып исәпләнә. Әмма шушы авылда туып үскән галим Альберт Борһанов искәрткәнчә, тарихи елъязмалар биредә авылның 1650 елларда инде булганлыгын күрсәтә. Галим үз вакытында монда XVII гасыр уртасына караган голланд акчасын да тапкан. Заманында авылда җиде мәчет булган. Бүген исә авылдашлары ярдәме белән өр-яңа мәчет төзелеп килә. Бәгәрәктамакның Сәнәр елгасы аша салынган, зур шәһәрләрдә яшәүчеләрне дә көнләштердәй 80 метрлы күпере дә төбәкне өйрәнүчеләрдә соклану хисләре тудырды. Ул – авыл җирлегенең элекке җитәкчесе, тынгысыз, батыр йөрәкле Эльза Газизованың фидакярлек җимеше. 1930 елларда салынган күпер инде җимерелер хәлгә җиткәч, җирлек рәисе теләсә кайсы ир-атның да кулыннан килмәстәй эшкә алына: район җитәкчеләре, авылны киләчәксез, дип билгеләп, ярдәм итәргә алынмагач, өлкә губернаторы Петр Сумингә барып җитә, акчалар табып, проектлаучылар, подрядчылар белән эш алып бара. Нәкъ менә Эльза ханым эшләгән елларда, район хакимияте хастаханәне ябу турында сүз алып бара башлагач, җитәкче аны авыл кешеләре көче белән төзекләндереп, ишек-тәрәзәләрен яңартып, саклап калган. Җирлекнең газлы булуы да – Э.Газизова тырышлыгы. Авылдашлары җитәкче ханымның никахлашу залын да тәртипкә китерүенә, бистәләр арасындагы юлларны төзекләндерү өчен акча бүленеп бирүгә ирешүенә дә рәхмәтле.

Бер гасыр яшәгән мәктәп

Автобусыбыз исә өч катлы, барлык уңайлыкларга ия заманча бинада урнашкан мәктәп янына туктады. Халкыбыз моңнары агылган уку йортында кунакларны мәктәп директоры Фидалия Кәримова җитәкчелегендә милли киемле укучылар һәм гаҗәеп ягымлы укытучылар каршылады. Бу көнне мәктәпкә килгән дәрәҗәле кунаклар арасында Коншак районы башлыгы Сибгатулла Әминов, Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илгиз Халиков, Чиләбе өлкәсендәге даими вәкаләтле вәкиле урынбасары Фәвия Сафиуллина һ.б. бар иде.

Тантаналар мәктәпнең беренче директоры Җамалетдин Камаловка багышлап уку йортының алгы диварына элемгән истәлек тактасын ачу тантанасы белән башланып китте. Ул – галим, профессор Җамалетдин аганың оныклары Альберт Борһановның һәм Әнири Камаловның мәктәпкә бүләге. Истәлек тактасының авторы исә – архитектор Валерий Хәмитов. Тарихчы галимнең бу көнне туган мәктәбенә тагын бер зур бүләге бар иде. Ул «Татарское село на Урале – Усть-Багаряк» дигән китап әзерләп бастырып кайткан.

Беренче директор Җамалетдин Камалетдиновның мәктәпне оештырып җибәргән еллары мәгариф өлкәсендәге үзгәртеп корулар, яңача оештырулар барган иң авыр, катлаулы заманга туры килгән. Шулай да тирән белемле, һәр кешенең күңеленә ачкыч таба белгән Җамалетдин ага уку йортын уңышлы эшләтеп җибәрә алган. Уку йорты башта дүртьеллык мәктәп буларак укучыларын кабул итә. Ун елдан ул Түбәнавыл җидееллык (сигезьеллык) мәктәбе итеп үзгәртелә. Ул һәрвакыт округта бердәнбер белем бирү учагы була. Укучылар исә тирә-яктагы барлык авыллардан килә. Керосин җитмәгәч, шәм яндырып укыган еллар да хәтерләрдә сакланып калган, утынны исә авыл белән бергәләп әзерләгәннәр.

1952-1953 елларда ике катлы заманча мәктәп ишекләрен ача. Ул елларда уку йортында 600 дән артык бала белем алган. Уку йортының яңа бинасы да тора-бара кысанлана. Ә инде 1983 елда бүгенге өч катлы бинаның салынып бетеп, файдалануга тапшырылуы авыл бәйрәменә әверелә. Ә аның төзелеп бетүе өчен күпме көч куелганын, ут-суларга төшкән мәлләрен ул еллардагы директор Венера Сафина үзе генә белгәндер.

бәйрәм

●Бәгәрәктамакның элекке авыл җирлеге рәисе Эльза Газизова Саба районы төбәк тарихын өйрәнүче Илдар Сафин белән.

Бүген уку йортында 139 бала белем ала һәм 47 мәктәпкәчә яшьтәге бала тәрбияләнә. Белем бирү учагының заман белән бергә атлап баруын да күрми мөмкин түгел. Һәр сыйныйфта укытучыларның эш урынында компьютер тора. Алты кабинет цифрлы укыту ресурслары белән җиһазланган. «Коллектив бик бердәм, укучыларга заманча алымнар ярдәмендә дәресләр бирү ниятеннән укытуның дистанцион һәм электрон формалары өчен дә шартлар тудырылган һәм ул камилләштерелә бара. Быел гына да 28 ноутбук алдык», – диде директор Фидалия Кәримова. Бәгәрәктамак мәктәбендә туган тел һәм әдәбияты укыту беркайчан да әзелмәгән. Укучыларның тарихка мәхәббәтен дә тоемламый мөмкин түгел. Алар мәктәп музеендагы теләсә кайсы ядкяр турында иркенләп сөйли ала. Бу исә тарих укытучысы Венера Сафина укучылар күңеленә салган үткәннәр белән кызыксыну утының бүген дә сүнмәвеннән килә.

Әлбәттә, укучыларның үткәннәргә мөкиббән китүендә белем бирү учагында озак еллар дәвамында хезмәт куйган Луиза Мөгыйнованың өлеше бар. Ул мәктәпкә 1973 елда тарих укытучысы булып кайта, урынбасар, 25 ел дәвамында директор булып эшли. Луиза ханым бүген дә укучылар арасында, урынбасар вазифасын алып бара.

Илдә булган бер вакыйга да уку йортын читләтеп үтмәгән. 1990 елларның шактый катлаулы заман икәнен хәтерлибез әле. Бу елларда яшәп килгән идеаллар сабын күбеге кебек шартлады, илдә сәяси, икътисади, идеологик яктан да зур үзгәрешләр башланды, билгеле ки, хәл ителәсе мәсьәләләр дә калкып чыкты. Шул вакытта укучыларны, алар теге яки бу якка авышмасыннар өчен, тотып калырга кирәк була. Коллектив бу сынауны да уңышлы уза. Укытучылар үзара киңәшә дә төп игътибарны әхлакый якка һәм үткәннәребезгә, тамырларыбызга юнәлтергә карар итә, программасын да эшлиләр. Россия профессиональ югары белем бирү мактаулы хезмәткәре Луиза Алмаеваны районга, Коншак районының милли программасын эшлибез, дип чакырып алалар. Бу укытучыларны тагын да дулкынландырып җибәрә. Мәктәптә Бәгәрәктамак, туган як тарихы өйрәнелә башлый, бер үк вакытта музей ядкярләрен туплау да бара. Сугышта катнашкан һәр кешенең фотосурәте, документлары аша мәгълүмат булдырыла. Шулай ук «Укытучылар – ватанны яклаучылар» дигән проект та алып барыла. Алга таба барлык ядкярләр тәртипкә китерелеп, музей ачыла, аңа лицензия дә алына. Бөек Ватан сугышында катнашучылар белән бәйле эзләнү эшләренең нәтиҗәләре дә озак көттерми. Мәктәптә барган күркәм гамәлләр хакында өлкә дәрәҗәсендә сөйләшә башлыйлар. Уку йорты база мәктәбенә әверелә, семинарларны да, хәттә өлкә күләмендәге олимпиадаларны да Бәгәрәктамакта үткәрү гадәткә кереп китә. 2004 елда мәктәпне күрергә хәтта Татарстаннан да килүләр.

Шундый хәл дә була. Бәгәрәктамакта туып үскән, авылдан Бөек Ватан сугышына киткән Идият Солтанов турында мәгълүмат сорап, Свердловск өлкәсе халык судыннан мөрәҗәгать итәләр. Германиядә аның каберен тапканнар, соңрак аның җәсәден Польшага күчергәннәр. Бу ил белән белән мөнәсәбәтләр начар. Шуннан соң дипломатлар аша барып, каберне табып, җирен капсулага салып, Екатеринбургтан бер бригада судьялар катнашында, Бәгәрәктамакка алып кайтканнар. Капсуланы Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл янына тантаналы рәвештә күмеп куялар.

Мәктәптә 100 ел дәвамында директор булган барлык егерме шәхесне онытмыйлар. 2016 елда Канададан бер директорның оныгы хәбәр сала. Ул бабасының каберенә һәйкәл куярга ниятләп кайткан. Бабасына кагылышлы материалларны юллап, мәктәпкә килеп, коллектив белән очрашып, кабергә һәйкәл куеп китү бик матур хәтирәләр калдыра.

Эш хакы ала алмаган еллар да мәктәпне читләтеп үтмәгән. Директорны исә әлеге хәлдән ничек чыгарга дигән уй борчыган. Мәктәпнең тракторы була һәм коллектив 20 гектар мәйданда иген үстерә башлый. Ашлыкны мәктәп ишек алдына алып кайталар, аны коллективтагы һәр кешегә бүлеп бирәләр. Мәктәп музеенда укытучыларның суыткыч, балаларына кием-салым, савыт-саба сорап язган бер папка гаризалары саклана.

Мәктәп белем биргән укучылары белән горурлана. 100 ел дәвамында 47 е егет һәм кыз медальгә тәмамлаган. Уку йорты тарих фәннәре кандидаты, Халыкара төрки академия академигы Луиза Алмаева, тарихчы, археолог, «Татар төбәкчеләре оешмасы» рәисе, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Россия һәм халыкара академияләр академигы Альберт Борһанов, бокс буенча тренер, биология фәннәре кандидаты Рөстәм Галимов, филология фәннәре кандидаты Шакир Абилов, физика-математика фәннәре кандидаты Ривиан Сираҗетдинов һ.б. белән горурлана. Әлбәттә, бу уңыш – мәктәп укытучыларының балаларга нигезле белем бирүенең дә күрсәткече.

Җамалетдин ага хәтерләрдә яши

Теләсә кайсы эшнең башлангычында кеше тора. Бәгәрәктамак гомуми урта белем бирү мәктәбенең данлы тарихына да 1922 елда аның беренче директоры Җамалетдин Сираҗетдин улы Камалетдинов тарафыннан нигез салынганын әйткән идек. Ул – тарихчы А.Борһановның әнисе ягыннан бабасы. Җамалетдин, әтисе Сираҗетдин гаиләсенең ярлы яшәвенә карамастан, авыл мәдрәсәсендә белем ала, аннары Шадринда дүрт классны училищены тәмамлый, «Башлангыч рус-башкорт училищесы укытучысы» дигән документ ала. Җ.Камалов алга таба Уфада һәм Төркиядә, соңрак Екатеринбурның Мөселман институтында белем өсти. Яшь белгеч революциягә кадәр Шадрин районының земство управасы секретаре булып эшли. Икмәкнең валчыгы да кадерле елларда мәктәптә укучылар өчен бушлай туклану мөмкинлеген тудыруы гына да аның булдыклы директор булуы турында сөйли. Матди яктан хәле авыр булган гаиләләрнең балалары исә Җ.Камалов ярдәмендә өсбаш белән дә тәэмин ителгән, иң яхшы укучылар кием һәм тукыма белән бүләкләнгән. Шул ук вакытта Түбәнавыл укучылары тирән белемнәре белән аерылып торган. 1932 елда Җамалетдин ага тәкъдиме һәм тырышлыгы белән мәктәп сигезьеллык итеп үзгәртелә, уку йортының яңа бинасы төзелә. Җ.Камалов мәктәпнең директоры булу белән бергә география һәм тарих укыта, китаплар бик ярата, өендә шактый бай китапханәсе дә була. 1937 елда 54 яшьлек Җамалетдин Чиләбе педагогика институтының тарих факультетына читтән торып уку бүлегенә кабул ителә, беренче семестрның биш имтиханын да тапшырырга өлгерә. Әмма ул елгаң әләк белән, «Земство управасының элекке секретаре» һәм «контрреволюция тарафдары һәм чит ил (япон һәм төрек) шпионы» буларак кулга алына, шактый еллар узгач кына, аның шул елда ук 6 ноябрьдә Чиләбе өлкәсендә атып үтерелүен беләләр. Хатыны Рәйхана исә җиде баласы (өчесе мәктәп яшенә дә җитмәгән) белән ялгызы кала. Аңа «халык дошманы хатыны» буларак барлык кимсетүләрне, рәнҗетелүләрне кичерергә туры килә. Балаларын да аямыйлар, комсомолдан чыгаралар. Шул ук вакытта авылда халык арасында төрле риваятьләр тараталар. Янәсе мәктәпнең элекке директоры Сахалинга киткән дә кайтасы килми. Җ.Камаловны 1959 елда аклыйлар. 1990 елларда архив ишекләре ачылгач, күп кешеләрнең исемнәре табыла, кемнәрнең кул куюы, ярдәм итүләре дә ачыклана.

Әмма Җамалетдин ага авылдашлары хәтерендә иң якты хатирәләр белән кереп калган. Аны зыялы, тирән белемле, беркайчан да тавышын күтәрми торган, башкаларга киңәшләре белән ярдәм итүче акыллы, гадел җитәкче, талантлы педагог буларак искә алалар.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Айга карыйн карама

Халык медицинасы чаралары белән дәваланугa керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

29 октябрь (шимбә). ***Рабигуль ахир аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 12.18 сәгатьтә калка, 17.56 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.28 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Инҗир сихәте

Бронхиттан инҗир бик әйбәт дәвалый. 3 җимешне термоска салып, өстенә 1 стакан кайнар сөт кояlар, 2 сәгать төнәтәләр дә, ашаганнан соң яртышар стакан эчәләр.

30 октябрь (якшәмбе). ***Рабигуль ахир аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 13.28 сәгатьтә калка, 19.01 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.24 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур. Теш алдырырга ярамый.

Миләш дәвалый

Дәва максатларында миләшнең кайрысы, бөресе, яфрагы, чәчәге һәм җимеше кулланыла. Миләш кан тамырларының тышчасын ныгыта, матдәләр алмашын яхшырта, шешне кайтара, атеросклероз, остеохондроз, подагра, ревматизм, бөер ташы авыруларын нәтиҗәле дәвалый. Ашказаны согының ачылыгын арттыру өчен, көненә 3 тапкыр, ашарга 20-30 минут кала, 1 әр чәй кашыгы миләш согы эчәләр. Төелгән миләш диабетны дәвалауда кулланыла. Миләш баш авыртканда, югәлгәндә, эч киткәндә, күңел болганганда булыша. Баш мие тамырлары склерозын дәвалау өчен, 200 грамм миләш кайрысын 2 литр суга 2 сәгать кайнаталар, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 30 ар грамм эчәләр.

31 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигуль ахир аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 14.07 сәгатьтә калка, 20.27 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 9.19 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказаны һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Глицеринлы лимон

Менә мондый катнашма бронхиттан бик шәп дәвалый. Лимонны суга салып, сүрән утта 5 минут пешерәләр. Аннан соң урталай кисеп, согын стаканга сыгалар. Шуңа 2 аш кашыгы глицерин кушып болгаталар һәм стакан тулганчы бал өстиләр. Көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 2 шәр чәй кашыгы кабалар, йоклар алдыннан да эчәләр. Лимон согы урынына 100 мл алма серкәсе салырга да була.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

1 ноябрь (сишәмбе). ***Рабигул ахир аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 14.33 сәгатьтә калка, 22.01 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.15 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Кәбестә яфрагы

Әгәр пешкән урын бик озак төзәлми икән, болай дәваланып карарга була. Кәбестә яфрагын бик яхшылап ваклап, шуңа икегә бер исәбеннән чи йомырка агын кушалар, әйбәтләп болгаталар һәм җәрәхәткә ябалар.

2 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигул ахир аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,14.49 сәгатьтә калка, 23.35 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.11 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Әрекмән тамыры

Озак төзәлми торган җәрәхәтләр өчен әрекмән мае яхшы. Яңа казып алынган әрекмән тамырын вак кына турап, өстенә көнбагыш мае салалар, 1 тәүлек төнәтәләр, аннан соң 15 минут кайнаталар да, суытып, сөзәләр, суыткычта саклыйлар.

3 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул ахир аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 15.01сәгатьтә калка, 1.06 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.06 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Өйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

4 ноябрь (җомга). ***Рабигул ахир аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 15.09 сәгатьтә калка, 2.33 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 9.02 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Помидорлы салат

2,5 кг кызыл помидор, 2 шәр кг башлы суган белән татлы борыч кирәк. Помидор һәм суганны – боҗралап, борычны саламлап турыйлар, һәркайсын аерым-аерым үсемлек маенда кыздыралар. Барысын бергә кушып, бик вак туралган 1-2 баш сарымсак өстиләр, тәменчә тоз, борыч сибәләр. Стериль банкаларга бүлеп, 20 минут стерилизацияләләр һәм тимер капкач белән каплыйлар.

Гаделлек беренчел

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күп хатыннарга өйләнүе бүгенге кешеләр өчен үрнәк булырга мөмкинме?

Пәйгамбәр Әфәндебезнең шәхесенә бәйле кайбер гамәлләре өммәтенә үрнәк түгел. Чөнки ул диннең беренче вәкиле, нигез салучысы, гамәлдә кулланучысы һәм, Аллаһның илчесе буларак, бөтенләй башка дәрәҗәдә иде. Шуңа күрә, бүтән кешеләрдән аермалы булып, махсус бары тик аның үзенә генә, һәр төнне торып, тәһәҗҗуд намазы кылу фарыз ителә, берничә көн рәттән ифтарсыз гына ураза тотуы (саум-ы висал) рөхсәт ителә, аңа һәм гаиләсенә зәкят кабул итү тыела. Никахларының барысы да дини, иҗтимагый һәм сәяси сәбәпләргә нигезләнгәнгә күрә, дүрттән артык хатынга өйләнүе барлык ислам галимнәре тарафыннан бертигез кабул ителгәнгә күрә, өммәтенә үрнәк булмас.

Башта шуны ачыкларга кирәк: күп хатынга өйләнүне ислам башламаган. Ул бу мәсьәләдә яшәп килгән гадәтләрне билгеле бер тәртипкә сала, кысаларга урнаштыра. Исламга кадәрге чорда бер белән чикләнү булмый. Ислам моны төп кагыйдә нигезендә «дүрт» белән чикли. Ханымнар арасында гаделлекнең сакланмаячагыннан куркып, «бер» хатынга өйләнүнең тагын яхшырак булуы белдерелә.

Икенчедән, дүрт хатынга өйләнү барлык мөэминнәр өчен дә «әмер» түгел, кайбер очракларда кулланылырга мөмкин «рөхсәт»тер. Бу сугыш, авырулар, гарипләнү, озакка аерылып тору, химая һ.б. кайбер сәбәпләр нәтиҗәсендә гаиләләрнең таркалмавы, хатыннарның ирсез һәм яклаучысыз калмаулары өчен кулланыла. Мәсәлән, бала тапмаган яки гәүдә-саннары төзек булмаган бер хатын-кыз белән никахлашкан бер кеше шул хатыннан аерылмыйча гына икенче бер хатынга өйләнергә мөмкин. Мондый заруратлар дәвам иткән тәкърирдә, гаиләләрнең саны арткан саен, бу сан «дүрт» белән чикләнә. Шул рәвешле бер гаиләнең таркалуыннан килеп чыгарга мөмкин булган матди һәм рухи зарарлар шактый киметелә.

Чыннан да, сугыш кичергән дәүләттә бердән артык хатынга өйләнүне хуплау, азайган халык санын арттыру һәм фәхишәлекне булдырмас өчен, зарури әйләнә. Моның мисаллары тарихта инде булган кебек, киләчәктә дә барлыкка киләргә мөмкин. Тормышны җиңеләйткән һәм табигый агымының дәвамын тәэмин иткән кагыйдә, бары тик өйләнүгә генә карамыйча, башка өлкәләргә дә кагыла. Шушы хосусият исламның вакыт ягыннан да, урын ягыннан да тормыш зарурияткәрын тәэмин итә алачак сыйфатта булуын күрсәтә.

Бердән артык (дүрткә кадәр) хатынга өйләнгән ир-атларга хәлләре арасында «гаделлекне тәэмин итү» бурычы йөкләнә. Моны үтәмәгәндә, Аллаһның газабы турында кисәтеләләр. Бу хакта аять-кәримәдә болай диелә: «Әгәр, сез вәлие булган, мөлкәтле ятим кызларга өйләнеп, аларга карата хаксызлык кылудан куркыксагыз, аларга түгел, күңелегезгә ошаган башка хатыннарга ике, өч һәм дүрт тапкырга кадәр өйләнә аласыз; әгәр араларында гаделсезлек кылудан куркыксагыз, бер хатын яки кул астында булганы (үзегез хуҗасы булган җария белән) канәгатьләнегез. Гаделлектән тайпылмас өчен бу ышанычлырак» («ән-Ниса», 3).

Башка бер аять-кәримәдә: «Никадәр тырышсагыз да, хатыннар арасында гаделлек сакларга көчегез җитмәс. Шунлыктан берсенә тулысынча күңел биреп, башкасын аннан баш тарткан кебек калдырмагыз. Әгәр нәфесегезне яхшыртсагыз, Аллаһтан куркып, хаксызлыктан тыелсагыз, һич шөбһәсез, Аллаһ Гафур һәм Рәхимдер» («ән-Ниса», 129) дип әйтелә.

Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бер хәдис-шәрифендә болай ди: «Бер ир-атның ике никахлы хатыны булып, араларында гаделлек тотмаса, кыямәт көнендә бер ягы параличланган хәлдә терелтелер». (Ибне Мәҗә, «Никах», 47)

Шул ук вакытта ир-атның бердән артыкка өйләнү хакын куллану мөмкинлеге, никах корганда хатын-кыз тарафыннан шарт куелып, чикләнә ала. Хатын-кызларга мондый хокук бирелгән.

Яратылыштагы илаһи максатларны игътибарга алмыйча, бары тик төгәл мантыйк белән төшенергә тырышып, хатын-кызның да бердән артык ире булуы мәгькуль күрелсә, бу дөрес булмас иде. Чөнки бу очракта туган балаларның нәсәбе бәйле бәхәс туар иде. Кайсының кем баласы булуын ачыклап булмас иде. Шуңа күрә «фөҗүр» дип әйтелгән мондый никахларга һичбер дин дә, хәтта һичбер динсез хокук системасы да рөхсәт бирми. Ислам да моңа каршы чыга.

Коръән белән яуланган Мәдинә

Мәдинәнең яңа мөселманнары, исламны өйрәнү өчен, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән, хат язып, үзләренә Коръәни-Кәрим укыячак, исламны аңлатачак һәм намаз кылдырачак бер мөгаллим җибәрүен үтенәләр. Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-сәләтү вәссәлам аларга Мусгаб радыйаллаһу ганһене юллый.

Чыннан да, Мусгаб радыйаллаһу ганһе Мәдинәгә килүгә, анда ислам шактый үсешкә китә. Пәйгамбәр Әфәндебез тәблигъ вазифасын йөкләгән әлеге яшь сәхабә кешеләргә Аллаһ динен аңлату өчен көнтөн эшли башлый. Мусгаб радыйаллаһу ганһенең тырышлыгы Бәрабәрәнә һидаяткә ирешкән тәүге бәхетлеләрдән Әсгад ибне Зүрарә радыйаллаһу ганһе аны өендә кунак итә һәм бөтен эшләрендә аңа булышлык күрсәтә. Беркөнне ул Мусгабны үз янына чакырып, Зафәр угыллары бакчасындагы кое читенә утыра. Габдүләшһәл угыллары ыруының алдынгыларыннан Сәгъд ибне Мугаз, бу хакта ишеткәч, Үсәйд ибне Худайрга:

«Син – әшен языш белгән һәм һичкемнең ярдәменә мохтаҗ булмаган бер бәндә. Халкыбыз ышанган нәрсәләрен җимерү өчен мәхәлләбезгә килгән бу адәмнәрнең янына бар да аларны кисәтеп куй, башка беркайчан да мәхәлләбезгә килмәсеннәр! Әсгад туганым булмаса, моны үзем эшләр идем», – ди.

Үсәйд сөңгесен эләктереп тегеләр янына китә һәм бик ачулы кыяфәттә: «Сез монда ни өчен килдегез? Әлеге яныңдагы чит кешене зәгыйфьләребезнең динен бозарга дип алып килдеңме? Башка беркайчан да мондый эшкә алынма! Әгәр җаныгыз кадерле икән, хәзер үк китегез моннан!» – дип кычкыра.

Зирәклек иясе булган Мусгаб радыйаллаһу ганһе аңа: «Бераз утырып мин сөйләгәннәрне тыңлап карамыйсыңмы? Син акыллы кеше, сүзләремне ошатсаң, кабул итәрсең, ошамаса, кабул итмәссең», – дигәч, сөңгесен җиргә кадап, Үсәйд алар янына утыра. Мусгаб ислам турында сөйләп, Коръәни-Кәрим укый.

Коръәни-Кәримне тыңлаган вакытта, әле сөйләшә башлаганчы ук, Үсәйднең йөзендә ислам нуры ялтырый һәм аның йөрәге исламга карата йомшый. Коръәни-Кәрим хакында ул: «Бу нинди күркәм, нинди бөек сүзләр! Сез бу дингә керергә теләгән чакта нишлисез соң?» – дип кызыксыну белдерә.

Үсәйд радыйаллаһу ганһе, аякка басып, хәзрәти Мусгаб һәм Әсгад радыйаллаһу ганһүмә өйрәткәнчә госел коена, киемнәрен чистарта һәм шәһадәт кәлимәсен әйтә. Соңыннан ике рәкәгать намаз кыла һәм: «Артымда шундый бер кеше калдырган идем, ул сезгә иярсә, аның кавеменнән һичкем аңа каршы чыкмас. Сәгъд ибне Мугаз исемле ул кешене мин хәзер сезгә җибәрим әле!» – ди.

Сәгъд ачудан кызган бер хәлдә болар янына килә. Ләкин ахырда ул да, хәзрәти Үсәйд кебек Мусгаб радыйаллаһу ганһене тыңлап, мөселманлык кабул итә. Соңыннан кабиләсе янына кайтып:

«Әй Габдүләшһәл угыллары! Мине нинди кеше дип беләсез?» – дип сорый. Тегеләре: «Син безнең юлбашчыбыз, акыл ягыннан иң өстен булганыбыз, рәисебез», – ди.

Шуннан соң Сәгъд радыйаллаһу ганһе: «Сез Аллаһка һәм Аның Рәсүленә иман китермичә, ир-атларыгыз һәм хатын-кызларыгыз белән сөйләшү миңа хәрәм булсын», – дип белдерә.

Ул көн кичкә бу кабиләдә мөселман булмаган кеше калмый.

Хәзрәти Мусгаб радыйаллаһу ганһе Сәлимә угыллары ыруының хөрмәтле, бай кешеләреннән Гамр ибне Җәмухны да исламга чакыра. Аңа «Йусуф» сурәсенең тәүге сигез аятен укый. Гамр уйлау өчен бераз вакыт сорый, фәкать бер төрле дә карарга килә алмый. Гамрның әүвәлрәк мөселманлыкка килгән улы Мугаз шуннан соң кабиләдәге мөселман яшьләр белән килешеп, бер төндә атасы табына торган потны алар яшертен рәвештә якындагы пычрак су чокырына ташлый. Иртән бу хәлне күргән Гамр, коты очып, потны чокырдан алдырта да, чистартып, хушбуйлар сибеп, кире урынына урнаштыра.

Шул ук вакыйга берничә көн кабатлангач, пот үз-үзен сакласын өчен, аның муенына кылыч асып куя. Иртәгәсе көнне потын янә чокырда күргәч, үзе гыйбадәт кылган җансыз нәрсәнең һичнәрсәгә ярамагынын, хәтта үз-үзен дә саклый алмаганын аңлый һәм ширек караңгылыгыннан исламның нурлы иртәсендә уяна. Пәйгамбәр галәйһис-сәләтү вәссәлам арадашлыгы белән үзен йөрәгендәге адашудан коткарган Аллаһка шөкер кыла. Соңыннан кавеме дә ислам кабул итәргә әзәрә.

Исламның Мәдинәдә ошбу матур рәвештә кабул ителүе турында хәбәр алган Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм мәккәле мөселманнар бик шатлана. Хәтта бу елны «Сөенеч елы» дип атый башлыйлар, чөнки Мәдинә инде исламның бишегә булыр хәлгә килә башлый.

Пәйгамбәр галәйһис-сәләтү вәссәләм Әфәндебез болай дип әйтә: «Илләр кылыч белән яуланды, ләкин Мәдинә Коръән белән яуланган иде».

Кулъязмалар янмый икән...

Талантлы шагыйрә, бик күп җырлар авторы Гөлшат апа Зәйнашева белән еш аралаштык дип әйтә алмыйм. Әмма сирәк кенә күрешкән араларда җылы итеп исәнләшәбез, әдәбият-сәнгатебез турында шактый мәгънәле генә сөйләшеп ала идек. Ул миңа «энем» яисә «Рашат энем» дип эндәшер иде. Безне якынайткан тагы бер нәрсә бар: аның композиторлардан Сара Садыйкова, әминем Фәрит Яруллин турында китап язу белән «җенләнеп йөргән чакларыбыз...

Беренче татар балеты «Шүрәле»не язган композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хрониканы (ЖЗЛ сериясеннән), дүрт ел чамасы материаллар туплаганнан соң, 1987-1988 нче елларда тәмамлаган идем. Озак тормастан, «Казан утлары» журналының 11-12 нче саннарында басылып та чыкты ул.

Шулай беркөн Язучылар берлегендә Гөлшат апа белән кара-каршы очраштык. «Энем, – ди бу миңа, – синең Фәрит Яруллин турындагы әсәреңне укый башладым. Укып бетермәс борын, алдан кычкыру килешмәстер, ничек тә хәбәрләшербез, кот, яме».

Дулкынланып котәм, миннән күпкә өлкән, тәҗрибәле апаның бәяләмәсен ишетәсе килә! Тик нишләптер безнең хәбәрләшү һаман да сузыла. Юкка хафаланганмын икән – күп тә үтмәде, Гөлшат апа минем кулга дүрт-биш битлек кенә язмасын тоттырды. Ниндидер матур сүзләр әйтте, аларын хәтерләмим дә инде. Түземдәм, шундук Матбугат йортының аулаграк бер почмагына юнәлдем дә хатны бер сулышта укып чыктым. Йә, Хода, нинечкәләп җентекләп укып чыккан әсәремне! Яртысы – мактау сүзләре, тәнкыйть-киңәш рәвешендәге фикерләре дә җитәрлек...

Язманы шәрехләп торасым килми, бу мөмкин дә түгел бугай. Иң яхшысы, бераз кыскартып, укучы хөкеменә тапшырудан да хәерлесе булмастыр.

«Рашат туган!

Сөйләшкәнебезчә, мин синең Фәрит Яруллин турындагы әсәреңне укып чыгып, кайбер фикерләремне язам. Журналдан соң китап булып чыгачак, диден ич. Бәлки, кирәге чыгар.

*Иң элек шунысын әйтим, әсәреңне яратып, бирелеп укыдым. Фәрит Яруллинның үзен яратудан да булгандыр бу. Син аның тормыш юлын – балачагын, егет чагын, консерваториядә укыган елларын, сугыштагы солдат-фронтовик чагын һәм һәлакәтен (ассызык – Г.Зәйнәшеваныкы. – **Р.Н.**) ныклы өйрәнеп, ихласлык белән язгансың. Рәхмәт сиңа, халкыбызның талантлы һәм батыр улын шулай укучыларга җанлы кеше итеп, терелтеп, сурәтләп бирүең өчен! Бүгенге һәм киләчәк буын укучылары сиңа бу хезмәтең өчен рәхмәтләрне кабат-кабат әйтерләр әле. Мин, гомумән, музыкаль тормышыбыз белән якыннан торып иҗат итүче, яшәүче кеше буларак, һәр музыка кешесе турында укып барырга тырышам, бу өлкәдә эшләвең өчен сине дә хөрмәт итәм.*

Хәзер инде берничә киңәшем.

Әсәреңдә кыюсызлык күрсәткән урыннар бар. Хәтереңдәдер, Матбугат йортында бер сөйләшкән дә идек. Хәбәрдарлыкка кадәр язылганлыктан, минем «Сара Садыйкова» китабында да кыюлыгым җитмәгән урыннар әчемне пошыра. Синең мөмкинлегең бар – хәбәрдарлык сиңа юл ачты, кыюрак бул. Фәритнең язмышы белән уйнаган кеше турында ачыграк яз. Ул урыннарны яңа баштан карап чык.

Җөмлә һәм фикер йөртүдәге кайбер төгәлсезлекләр (минем карашымча):

11 санда.

Журналның 22 нче битендә «Мишәнең тын почмагына укмашалар» дип язгансың. Ни өчендер безнең прозаиклар – Г.Ахунов, Б.Камалов, Р.Низамиев та чүмәшәләр, укмашалар дигән әллә нинди сүз кулланырга яраталар. «Утыралар» сүзеннән ник куркалар икән?

58 нче бит. Г.Сөләйманова, Г. Әлмөхәммәтов, М.Рахманкулова һ.б. арасында, мөгаен, Сара Садыйкова да булгандыр. Шул ук биттә: музыкаль редакция бүлегендә эшләүче Зәйнәп Хәйруллина ул елларда курьер булып кына эшләгән дип беләм.

66 бит. С.Сәйдәшев Фәриткә «Улым» дип әйтер микән? «Туганым» дип әйтүе ихтимал. «Улым» дию өчен яшь аермалыклары бик зур булу кирәк бит.

72 нче бит. Заһидулла Яруллин тикмәгә генә илгәзәклек итмәгәндер. Репрессия чоры бит. Халыкның күңеле кор, дисең. Ай-һай, утызынчы еллар уртасында бик тә киеренке еллар иде, төнлә килеп кемне, кайчан алып китәрләр дип зар елап яшәгән заман. Ә күңел корлеге – безнең халыкның ышанучан булуыннан бит, бу үзе бер фаҗига лабаса.

74 нче бит. Тальянда сул кул белән уйнаган Кәрам образы – искиткеч матур образ!

76 нчы бит. «Каурыйлы тәтәлкә» – бу нинди сүз? Аңламадым.

12 нче санда.

30 нчы бит. «Матурлыкның яшәр урыны – Ватан» дигәнсең. Матур фикер, әйбәт әйтелгән. Ләкин, минемчә, болай дип тагын да уңышлырак булыр иде: «Матурлыкның яшәр урыны, туган җире – Ватан!»

66 нчы бит. Ф. Вәлиева дип әйтү генә ярамас. Ул – музыковед, күпне күргән, күп музыкантларны якыннан белүче. Аның турында берничә хәрефеңне җәлләмә! «Фатыйма» дип тутырып яз... «Ф» дип кенә әйтү яхшы түгел.

70 нче бит. Соңгы абзац. Фәрит Яруллин турындагы сөенечле хәбәр: радио аша «Шүрәле» балетыннан өзекләр яңгырый. Улының сугышта хәбәрсез югалуы, үлеме кәгазен алган ата кеше өчен бу сөенеч микән соң? Бу урынын болай язу, минемчә, уңышсыз кебек.

Мин язып бирермен дип махсус укымаган идем, күзгә ташланган кайбер нәрсәләрне билгеләп куюым гына булган иде. Китапка әзерләгәндә, бәлки, кечкенә генә файдасы тияр дип, партҗыелыштан кайткач, төн уртасында сызгаладым менә. Почеркым элек әйбәт иде, хәзер начарланды, кул-бармаклар авырта, начар язган дип ачуланма, гафу ит, укы да ертып ташла.

Сиңа ихтирам белән:
Гөлшат апа Зәйнашева
22 июнь, 1989».

P.S. Күрәсез ки, хат-язманы ертып ташламаганмын. Акыллы сүзләр, фикерләр, киңәшләр җитәрлек... Тик, ни кызганыч, мин бу киңәшләрне тәэзтелгән, тулыландырылган «Ут һәм җыр» дигән китабыма кертә алмадым. Әмма яшь язучыларга булышучан Гөлшат апага рәхмәтем ифрат зур. Бу язма аның рухына дога булып ирешсен иде.

Рашат НИЗАМИ.



Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28 октябрь – Зур залда – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев). Кече залда – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
29 октябрь – «Мәңгелек буран» (спектакль экран аша күрсәтелә). Зур залда – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый). Кече залда – Әлмәт Татар дәүләт драма театрының «Микулай» спектакле (М.Гыйләҗев).
30 октябрь – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
3 ноябрь – Шәрык клубында – Логопед Фәния Гарипова белән дөрес сөйләм серләре дәресе.

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

29, 30 октябрь – «Сөембикә» (Р.Ахиярова).
3 ноябрь – «Дон Кихот» (Л.Минкус).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

28 октябрь – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
29 октябрь – 12.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци, К.Тинчурин).
30 октябрь – 11.00 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 17.00 – «Гомер буе сине көтәм» (И.Гали).
1 ноябрь – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
2 ноябрь – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
3 ноябрь – «Мәдинә» (И.Зәйниев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

30 октябрь – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Йосыф» (Кол Гали).
1 ноябрь – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).
3 ноябрь – 13.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 – «Корт» (Ф.Галиев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

28 октябрь – Татарстанның халык артисты Рәмзия Фәйзуллинаның юбилей кичәсе.
29 октябрь – Фойеда – «Идет коза рогатая» (М.Протасова). Зур залда – «Цветик-семицветик» (В.Катаев).
30 октябрь – Фойеда – Премьера. «Бобровый пруд». Зур залда – «Гуси-лебеди» (Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсценировкасы).
1 ноябрь – «Маугли» (Р.Киплинг).
2 ноябрь – «Уйна, Курай!.. Җырла, Шомбай!» (С.Дорожко).
3 ноябрь – «Ханума» (А.Цагарели).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

30 октябрь – Балалар өчен джаз музыкасы концерты.
31 октябрь – А.Астахова башкаруында шигырьләр яңгыраячак.
1 ноябрь – «Раневская. Одинокая насмешница» дип исемләнгән кичә.
2 ноябрь – «Евгений Онегин» спектакле.
3 ноябрь – Джаз концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

28 октябрь – Татарстан Республикасының М.Таминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры концерты.
30 октябрь – 12.00 – Балалар өчен «Волшебная сказка Аладдина» музыкаль спектакле. 17.00 – Татарстан Республикасы кыллы музыка уен кораллары квартетының 25 еллыгына багышланган концерт.

Төпсез күлләр

Дөньяда яманаты чыккан күлләр бик күп. Аларның исемнәре генә дә куркуга сала: Үле күл, Җенле күл, Хәсрәт күле... Переславль-Залесский янындагы Үле күлдән җиде чишмә агып чыга. Җирле халык анда су коенмый, ә менә балык тота. Нинди генә мутант эләкми аларның кармагына: бер күзле, өч күзле, саңак урынына аяк үскәннәре, хәтта тулысынча чәч белән капланганнары да очрый. Ел саен күлдә туристлар бата, тик аларның берсенең дә үле гәүдәсе табылмый. Анда су коенганнарның бөтен тәне мөгез тәңкә белән каплана, чәче коела, маңгаена мөгез үсеп чыга. Әлеге серле чир ярты елга сузыла, аннары әкренләп савыктыра. Латвиядәге Җенле күл ярында бер сәгатьтән артыграк торса, кеше акылдан шаша. Җирле риваятьләр буенча, күлнең төбе юк, анда батучыларның гәүдәсе табылмый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, күл төбеннән бертуктаусыз куәтле энергия агыла, шул кешене шаштыра.

(“Fishki.net”).

Балык мәктәбе

Ихтиологлар раславынча, инкубаторда үстерелеп иреккә җибәрелгән маймычларның күпчелеге тиз арада һәлак була, чөнки алар ачык сулыкларда яшәргә җайлашмаган. Шунлыктан Англия белгечләре балыклар өчен “мәктәп” ачарга тәкъдим итә. Аларда ике төрле методика кулланыла. Беренчесе буенча, балыкларга телевизор караталар. Экранда исә ерткычның бик тәмләп маймычлар белән сыйлануы күрсәтелә. Мондый сеанстан балыклар шок хәлендә чыкса да, ирекә чын ерткыч белән очрашканда инде югалып калмый. Икенче методика исә “Минем арттан кабатла” принцибына нигезләнгән. Үтә күренмәле экран артына ерткыч балык җибәрелә, маймычлар янына исә тәҗрибәле “өлкән туганнары”н кертәләр. “Абый-апалары”ның үз-үзен тотышын күзәтү нәтиҗәсендә маймычларда саклану реакциясе барлыкка килә. Балык мәктәпләре сирәк очрый торган төрләрне бөтенләй юкка чыгудан саклап калу максатында оештырыла.

(“The Local”).

Кочаклашу файдасы

Озак көрешми торганнан соң яки төрле борчулы хәлләр вакытында кешеләр нигә бер-берсен кочаклый? Арка миеннән 31 пар нерв чыга, алар баш миеннән эчке әгъзаларга импульс тапшыра. Нерв очлары сигналны баш миенең кешене тынычландыра һәм рәхәтлек тойгысы бирә торган өлешенә җиткерә. Шунлыктан, җилкәсеннән сөеп каксалар яки кочакласалар, сыйпасалар, кеше тынычлана. Табигать бик акыллы. Контакт (орыну) терапиясен җир йөзендә яшәүче барлык тереклек иясе куллана. Кочакка каты итеп кысылган кешедә рәхәт тынычлану хисе барлыкка килә. Менә шуңа да борчылган, кайгыдан сыгылып төшкән кешене кысып кочаклау бик файдалы.

(“Die Presse”).

Белеп эчү зарур

Пенсильвания университеты тикшеренүчеләре кайбер дару препаратларының нәтиҗәлелеге аларны тәүлекнең кайсы вакытында кабул итүгә бәйле булуын ачыклаган. Аспирин һәм статиннарның организмга иртән һәм кичен яхшырак тәэсир итүе галимнәргә күптән мәгълүм, тик моны фәнни нигезләү генә булмаган. Ә хәзер әлеге феноменны кеше геннарының үзенчәлеге белән аңлаталар. Мәсәлән, бавыр һәм бөер эшчәнлеген яхшырта торган препаратларны кичке сәгать 6 дан соң эчү файдалырак. Сулыш системасын дәвалый торган дарулар аеруча төш вакытында актив тәэсир итә. Йөрәк эшчәнлеген яхшырта торган препаратларны иртән эчү нәтиҗәле. Ә инде даруны тәүлеккә 3 тапкыр эчәргә кушалар икән, моны үзгәртергә ярамый. Тагын шунысын да истә тоту мөһим: дару препаратларын беркайчан да чәй, сөт, сок белән эчәргә ярамый, бары тик чиста су белән генә эчү мәслихәт.

(“The Daily Mail”).

Нидерландның Зандам шәһәрендә Inntel Hotels Amsterdam отеле бик күп төрле йортны бер-берсе өстенә куйган кебек итеп төзелгән.



Гөмбәз астындагы шәһәр

Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә дөньяда беренче гигант гөмбәз астындагы шәһәр төзелә. Дубай үзәгендә урнашачак инновацияле комплексның мәйданы 4-5 миллион квадрат метр тәшкил итәчәк. Кала инфраструктурасы объектлары бер-берсенә барлыгы 7 километр озынлыктагы урамнар белән бәйләнәчәк. Металл каркас өстенә пластик һәм пыяладан ясалган гөмбәз куелачак, шул рәвешле, шәһәр тышкы тирәлектән тулысынча аерылачак: андагы һава торышын махсус җиһазлар җайлаячак. Фильтр аша үткән һаваның дымлылыгы, температурасы контрольдә тотылачак. Коммуникацияләре Дубайныкына тоташачак, әмма кала 7 көн буе тышкы ресурсларсыз да яшәрлек булачак. Биредә Дубайдагы иң зур сәүдә үзәге урнашачак, 20 мең бүлмәлек кунакханәләр челтәре, 50 мең кешелек ял зонасы төзеләчәк. Ун елга сузылыр дип фаразланган төзелешкә 6,8 миллиард доллар акча бүленгән. Әлбәттә инде, шәһәргә машиналар кертелмәячәк, алар махсус урында калдырылачак.

(“Khaleej Times”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

31 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «БЕРДӘН БЕР». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи турында телеочерк. 6+
15.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МАНЕКЕНЩИЦА». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСКУПЛЕНИЕ». 16+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ПРОЩАЙ, ЛЮБИМАЯ...» 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Фаддей Беллинсгаузен.
8.00 Черные дыры. Белые пятна.
8.50, 19.45 «12 СТУЛЬЕВ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Встречи по вашей просьбе. Академик Дмитрий Лихачев».
12.25 «НАСРЕДДИН В БУХАРЕ».
13.45 «Первые в мире».
14.05 Линия жизни. Святослав Бэлза.
15.05 Новости. Подробно. Арт.
15.20, 22.10 «ЖЮЛЬ И ДЖИМ».
17.10 «Солисты Москвы» - 30 лет.
18.35 «В поисках музыки античности».
20.50 Больше, чем любовь.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Сишәмбе

1 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 6+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «БЕРДӘН БЕР». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Онытa алмыйм...»
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - ЦСКА. 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». Сара Садыйкова турында телеочерк. 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРОЩАЙ, ЛЮБИМАЯ...» 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСКУПЛЕНИЕ». 16+
14.40 «Связь времен. История доброй воли». 12+
15.10 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.40 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Леди Сапиенс».
8.40 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
8.50, 19.45 «12 СТУЛЬЕВ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «В поисках жанра. «Тот самый Горин».
13.35 «Имя - Культура».
14.20 «ЮБИЛЕЙ».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20, 22.25 «ШЕРБУРСКИЕ ЗОНТИКИ».
16.55 «Добро пожаловать, или Посторонним вход воспрещён». Без сюрпризов не можете?!»
17.35 Ильдар Абдразаков, Игорь Бутман и Московский джазовый оркестр в концертном зале «Зарядье».
20.55 «Агора».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
0.30 «Основано на реальных событиях». 16+

Чәршәмбе

2 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Онытa алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 0.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 12+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 Документальный фильм. 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Моңсара». 6+
20.30 «Юлчы». 6+
22.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРОЩАЙ, ЛЮБИМАЯ...» 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ХУТОРЯНИН». 12+
14.35 «Связь времен. История доброй воли». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТРИГГЕР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Жизнь и приключения Элизабет Виже-Лебрен».
8.35, 19.45 «12 СТУЛЬЕВ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Ираклий Андроников. Воспоминания о Большом зале».
12.30 «СЕРДЦА ЧЕТЫРЕХ».
14.05 Линия жизни. Ирина Антонова.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20, 22.05 «ЗАВТРАК У ТИФФАНИ».
17.10 «Первые в мире».
17.25 Екатерина Лёхина, Дали Гуцериева, Александр Титов и Санкт-Петербургский симфонический оркестр в Зеркальном зале дворца Белосельских-Белозерских (Санкт-Петербург).
21.10 Власть факта. «История русофобии».
21.50 Цвет времени. Анри Матисс.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Пәнҗешәмбе

3 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 6+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.05 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00, 0.50 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Онытa алмыйм...»
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Салават Юлаев». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.20, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.20 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Кыргый океан серләре». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Моңсара». 6+
19.20, 20.30, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРОЩАЙ, ЛЮБИМАЯ...» 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ХУТОРЯНИН». 12+
14.35 «Связь времен. История доброй воли». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Ступени победы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ХУДОЖНИК». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»

7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Жизнь и приключения Элизабет Виже-Лебрен».
8.40, 19.45 «12 СТУЛЬЕВ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Без ретуши. Мстислав Ростропович».
12.15 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
12.40 «ЗОЛУШКА».
14.05 Линия жизни. Виталий Вульф.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20, 22.05 «РИМСКИЕ КАНИКУЛЫ».
17.15 Концерт-посвящение Николаю Некрасову. Академический оркестр русских народных инструментов.
21.05 «Энигма. Роби Лакатош».
21.50 Цвет времени. Уильям Тёрнер.

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БАЛАБОЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Җомга

4 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
5.50, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00 «Манзара». 6+
8.00 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.30 «УЕННАН УЙМАК». 12+
12.30 «Татарлар». 12+
13.00 Торжественное мероприятие, посвящённое Дню народного единства и Гала-концерт фестиваля «Наш дом - Татарстан».
15.00 «Ибрагим Аганин. Война за линией фронта». 12+
15.50 «Русский акцент». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «БРАТ ВО ВСЁМ». 16+
23.25 «ТАНКИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Манзара». 6+
8.00, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
8.30, 20.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.15 Спектакль «Ут күршеләр». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05, 23.05 «Ком сәгате». 12+
13.00 «Татарстан- безнең йортыбыз». Республика этномәдәни фестиваленең гала-концерты. 6+
15.00 Спектакль «Әлдермештән Әлмәндәр». 12+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Театрның кыллы колы». Фуат Әбүбәкеров турында телеочерк. 6+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
21.25 «Татарстан- безнең йортыбыз». Республика этномәдәни фестиваленең гала-концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ПРОЩАЙ, ЛЮБИМАЯ...» 16+
10.30 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «Иосиф Сталин. Как стать вождем». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.00 «АДМИРАЛЪ». 16+
15.05 «Золото Колчака». 12+
16.00 «Связь времен. История доброй воли». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «ДЕЛО ДЕКАБРИСТОВ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро».
10.00, 12.00, 17.50 Новости.
10.05 «Символы России». 12+
11.10 «Жизнь своих». 12+
12.15 Юбилейный концерт Александра Зацепина.
13.50 «ИМПЕРИЯ. ПЕТР I». 12+
18.05 «Империя. Анна Иоанновна». 12+
19.05 «Империя. Елизавета Петровна». 12+
21.00 «Время».
21.35 «ОДИННАДЦАТЬ МОЛЧАЛИВЫХ МУЖЧИН». 12+
23.50 Концерт памяти Александра Градского. 16+

«РОССИЯ»
4.25 «ИДЕАЛЬНАЯ ПАРА». 12+
6.10 «КАТЬКИНО ПОЛЕ». 12+
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00 Вести. День народного единства.
12.00 Большой праздничный концерт «Песни русского мира».
14.40 «КОГДА ЗАКОНЧИТСЯ ФЕВРАЛЬ». 12+
20.00 Вести.
21.15 Вести. Местное время.
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Казанская икона Божией Матери.
7.00 Мультфильмы.
7.45 «ПО СЕМЕЙНЫМ ОБСТОЯТЕЛЬСТВАМ».
9.55 Неизвестные маршруты России. «Ханты-Мансийский автономный округ - Югра. Из Ханты-Мансийска в Югорск».
10.35, 23.50 «ЮНОСТЬ ПЕТРА».
12.50, 23.20 «Как царь Пётр Германию познавал».
13.25 «Между двух океанов: дикая природа Коста-Рики».
14.20 Международный фестиваль «Москва встречает друзей».
15.35 «Последний дом Романовых».
16.20 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ».
17.50 «Эстрада, которую нельзя забыть».
18.35 «Покровские ворота». Мой отец запрещал, чтоб я польку танцевал!»
19.15 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА».
21.30 «2 верник 2».
22.15 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
4.50 «ОТСТАВНИК». 16+
6.20 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 «ДедСад».
12.00 «Как мы будем размножаться?» 12+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА». 16+
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
19.50 «БАЛАБОЛ». 16+
21.50 «ОДНАЖДЫ В ПУСТЫНЕ». 12+

Шимбә

5 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Идел-йорт».Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле концерты. 6+
14.30 «Бар ул, бәхет, бар!» Фирая Әкбәрованың иҗат кичәсе. 6+
17.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.45 «НЕВЕСТА МОЕГО ДРУГА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Театрның кыллы колы». Фуат Әбүбәкеров турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 6+
22.15 Спектакль «Гөлҗамал». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30, 0.45 «Связь времен. История доброй воли». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Химия». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «СЕМЕЙНАЯ ТАЙНА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОДАРЁННАЯ». 12+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
18.00 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ИЗМЕНИЛ ВСЁ». 16+
23.15 «ДЕТЕКТИВ-ГУРМАН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.40 «А У НАС ВО ДВОРЕ...» 12+
16.55 «Горячий лед». Фигурное катание. Гран-при России.
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период».
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 Бокс. Бой за титул Чемпиона мира по версии WBA. 16+

«РОССИЯ»
4.25 «ПРИЛИЧНАЯ СЕМЬЯ СДАСТ КОМНАТУ». 12+
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «60 лет на сцене». 16+
14.40 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВАША ТЁТЯ ЛЮСИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Летучий корабль».
6.55 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА».
9.10 «Мы - грамотеи!»
9.55 «Кабардино-Балкария. От Нальчика до Джилы-Су».
10.35 «В НАЧАЛЕ СЛАВНЫХ ДЕЛ».
12.50 «Игра в бисер» «Самуил Маршак. Стихотворения для детей».
13.30 Черные дыры. Белые пятна.
14.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Галина Шурепова.
14.40 «Рассказы из русской истории».
15.40 Искатели. «Пропавшее золото смоленского банка».
16.30 «ОНА ВАС ЛЮБИТ».
17.50 «Эстрада, которую нельзя забыть».
18.35 Большие и маленькие.
20.30 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ».
22.00 «Горгона Медуза. Репетиция с оркестром».

«НТВ»
5.15 «Спето в СССР». 12+
5.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Детская Новая волна-2022».
23.25 «Семь мгновений Роберта Рождественского». 16+

Якшәмбе

6 ноябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Халкыбыз мирасы». 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «Казан» бию ансамбле концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Идел-йорт».Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле концерты. 6+
14.30 «Видеоспорт». 12+
15.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 Хоккей. «Северсталь» - «Ак Барс». 6+
19.30, 22.00 «Семь дней». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «СКАНДАЛЬНОЕ ПРОИСШЕСТВИЕ В БРИКМИЛЛЕ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Шаян хәлләр». 12+
7.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 6+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Резеда Шәрәфиева турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
13.50 «Тарихлы да син, яшь тә син, Татарстаным». 6+
15.40 «ҮКСЕЗЛӘР». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Мирас - Наследие». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+

«ЭФИР»
5.00, 15.15 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Связь времен. История доброй воли». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Химия». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «БЕГЛЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 16+
11.00 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ИЗМЕНИЛ ВСЁ». 16+
15.35 «СЕМЕЙНАЯ ТАЙНА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОДАРЁННАЯ». 12+
23.00 «КОД КРАСНЫЙ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 6.10 «ВРЕМЯ ЖЕЛАНИЙ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 К 100-летию Анатолия Папанова. «Надо просто любить и верить». 12+
13.20 «ПРИХОДИТЕ ЗАВТРА...»
15.15 «Валдис Пельш. Путешествие к центру Земли».
16.20 «Горячий лед». Фигурное катание. Гран-при России.
17.45, 0.20 «Романовы». 12+
18.50 «Поем на кухне всей страной». 12+
21.00 «Время».
22.35 К 100-летию выдающегося российского мыслителя Александра Зиновьева. «Возмутитель спокойствия». 12+

«РОССИЯ»
5.40 «КРЕПКИЙ БРАК». 16+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Измайловский парк». 16+
14.40 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.35 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ».
9.05 Тайны старого чердака. «Знакомство».
9.35 Диалоги о животных.
10.20 Передача знаний.
11.10 Большие и маленькие.
13.05 Спектакль «Турандот».
14.35 «История кукольной любви».
14.55 «Элементы» с Ильёй Доронченковым».
15.25 «СВАДЬБА».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 Цвет времени. Анатолий Зверев.
17.20 «Пешком...»
17.50 «Эстрада, которую нельзя забыть».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ПО СЕМЕЙНЫМ ОБСТОЯТЕЛЬСТВАМ».
22.20 Спектакль «Ромео и Джульетта».

«НТВ»
5.05 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.40 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Суперстар! Возвращение». 16+
23.25 «Звезды сошлись». 16+

Хезмәт урынында үлем-китем очраклары еш була. Бу яктан төзелеш оешмалары аеруча хәвефле санала. Иң беренче чиратта махсус хәзерлеге булмаган вакытлы хезмәткәрләр, мигрантлар эшләгән төзелешләрдә күп була хәвеф-хәтәр, бигрәк тә, югарыдан егылып төшеп үлә эш кешеләре.

Төзелештә кирәк саклык

Моны Әлмәттә булган аяныч хәлләр дә раслый. Нефтьчеләр каласының Совет урамында «Татнефть» җәмгыяте заказы белән аскы катта балалар бакчасы, югарыда фатирлар булган биек бина төзелә. 15 май якшәмбе булса да, гадәти эш көне була анда. Подряд оешмалары йортны килешенгән вакытта тапшырырга ашыгалар. Үзбәкстаннан килгән Бохромжон, Муйдинжон, Достонбек һәм Бабурбек 10 нчы каттагы балкон, төгәлрәге, калкып торган бетон плитә кырыена измә салу өчен агач тышча ясыйлар, димәк, уннарча метр биеклектәге як-ягы ачык мәйданчыкта кайнашалар. Түбәнгә егылу мөмкинлеге гаять зур булган мондый урыннарда күп кенә саклык чаралары күрергә кирәк. Мәсәлән, «высотник»ларның биектә эшләргә рөхсәт итүче таныклыгы, ягъни хәзерлеге булырга, алар махсус кием, шул исәптән, таймый торган аяк киеме, каска, иң мөһиме, хәвефсезлек каешлары белән тәэмин ителергә, медицина тикшеренүе, инструктажлар узарга һәм башка биниһая күп кагыйдәләрне үтәргә тиеш. Әлбәттә, вакыт, өстәмә чыгымнар сораучы ошбу таләпләрнең үтәлүе өчен, эш бирүче оешма җаваплы. Бу очракта үзбәк егетләре белән «Фортресс-Д» җәмгыяте арасында 7 дән 20 сәгатькә чаклы ял көннәрсез эшләү шарты белән хезмәт килешүе төзелә, махсус киемнәр бирелә, хак булса, куркынычсызлык кагыйдәләре буенча бердәнбер инструктаж да үткәрелә, әмма үзбәк малайларының русча начар белүе, аңламадык дип әйтүләрен искәртергә туры килә. Алар хәвефсезлек каешлары да бирделәр дигән булалар, ләкин 10 катта алардан файдаланып булмый, чөнки иминлек бауларын эләктерә торган трослар да куелмаган. Хәер, андый мөмкинлек тудырылса да, эшчеләрнең үзләрен «арканга» куюлары икеле, чөнки бәйләнгән килеш эшләү уңайсыз, ди алар.

Шул рәвешле, 15 майда дүрт кеше, гадәттәгечә, бернинди саклык чаралары турында уйламыйча эшли. Аларның өчесенең әйтүенчә, төштән соң, читләнмәгән балкон идәне кырыенда ук кайнашкан Бабурбекның кинәт кычкырып җибәрүен ишетеп борылып карагач, аның юкка чыгуын күрәләр дә түбәнгә йөгереп төшәләр. Гәүдә ком өеменә ятса да, 19 яшьлек егет җансыз була. Ашыгыч ярдәм табибларына үлемне рәсми таныргa гына кала, алар язу-сызу белән шөгыльләнгән арада мәет янәшәсендә хәвефсезлек каешы пәйда була. Аны төзелеш оешмасы кешеләре китереп ташлавы бәхәссез, хезмәттәшләре Бабурбекның иртәдән үк, каеш та, махсус киемен дә кимичә йөрүен әйтеп торалар. Инде әйтелгәнчә, 10 нчы катта каешны эләктерү җайланмасы булмый бит. Әлеге фаҗигадән соң гына ясап куялар аларны. Аннан соң, мондый биек биналарда түбәнгә мәтәлгәннәрне тотып калу өчен тыштан махсус челтәр дә тартылырга тиеш. Кыскасы, вазифаи затларның гаебе ярылып ята монда.

Әлеге төзелешнең генераль подрядчигы «Евростройхолдинг+» җәмгыяте, төзү эшләрен «Фортресс-Д» дигән субподрядчы оешма башкара, димәк, бар җаваплылык соңгысына йөкләнә. Үзбәк егетләре пандемиягә кадәр әлеге җәмгыятьнең Казандагы объектында эшләгән булалар, чикләр ябык чакта үз илләрендә яшиләр, ә 2021 ел җәендә Татарстанга яңадан киләләр. «Фортресс-Д» җәмгыяте аларга Әлмәттә торак хәзерләп куя, самолет билетлары бәясен кайтара, ярыйсы гына хезмәт хакы түләп бара.

Б.Хәсәнбаев үлеме зур шау-шу куптара, әлбәттә. Тикшерү комитетының Әлмәт бүлегеннән Алексей Сурчилов төзелештә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәү сәбәпле саксызлык белән кеше үтерү турындагы 216 нчы маддә буенча җинаять эше кузгата. Бу инде искә алынган ширкәттән кем дә булса хөкем ителәчәк дигән сүз. Ул исә бик тиз ачыклана. Чөнки хезмәт килешүләре, норматив документлары буенча барысы өчен дә әлеге бинада эшләгән төзелеш җитәкчесе, гадиләштереп әйткәндә, прораб Драгомир Ясиковац җаваплы булып чыга. Генераль һәм субподрядчы оешмалардан җитәкче иптәшләр бердәм рәвештә бар гаепне 63 яшендәге шушы абзыйга өяләр. Көн-төн төзелештә кайнашкан кешегә ник ярдәм итмәгәннәр дигән сорау туа.

Д.Ясиковац күп еллар Татарстанда яшәп эшләүче Сербия гражданы. Әлбәттә, аның гаебен кире кагып булмый. Татарстан эчке эшләр министрлыгыннан килгән төзелеш буенча экспертлар 2002 елгы кеше үлеменә китергән бәхетсезлек очрагына сәбәпче 12 җитешсезлекне күрсәтә. Ахыр чиктә, Д.Ясиковац гаебен таныны белдерә. Һәм Әлмәт шәһәр суды аны шартлы рәвештә ике елга ирегеннән мәхрүм итәргә карар чыгара.

* * *

2020 елның 13 апрелендә Уфада теркәлгән «Билд» дигән ширкәт «Татнефть»нең Әлмәттәге автотранспорт предприятиесе биналарына капиталь ремонт ясарга рәсми килешү төзи. Әлеге документка кул куелуга нәкъ бер ел тулган көнне, объектта эшләүче 28 яшьлек ир-ат бетон плитә астында калып һәлак була.

Монда да эшләр хәзерге заман өчен гадәти тәртиптә алып барыла, ягъни башлыча шабашниклар дип йөртелгән очраклы кешеләр тарафыннан башкарыла. Совет чорында салынган цех бинасының яссы бетон түбәсен сүтеп яңадан ябуны директор А.Александров һәм аның урынбасары Р.Шәйхелисламов өч-дүрт кешелек бригадасы белән шул ук АТПның күршедәге корылмасын ремонтлау белән шөгыльләнүче М.Сәйфуллинга тәкъдим итәләр. Марат алдан шунда ук эшләүче хәзерлекле, югарыда эшләргә рөхсәт бирүче таныклыклары булган кешеләрне тартмакчы була. Ләкин һөнәри төзүчеләр түләү мәсьәләсе белән килешмичә китеп бараллар. Шуннан соң бер дусты ярдәме белән биш кешелек бригада туплый ул.

М.Сәйфуллин моңа кадәр «ИП Гаффаров» дигән шәхси предприятие аркылы эшли, хезмәт хакы да шунда күчерелә. Бу юлы андый хезмәт килешүе төзелми, шабашниклар да рәсми рәвештә эшкә урнаштырылмый. АТП территориясенә дә КППдан китеп барган төзүчеләрдән калган таныклыклар белән, димәк, чит кеше фамилиясен атап керә алар. Әлбәттә, хәвефсезлек турында уйлаучы булмый монда. Әлеге төркем төзелештә эшләү күнекмәләре булмаган ирләрдән тора. 1992 елгы Радик Гыйниятуллин, мәсәлән, соңгы елларда Себердәге нефть оешмаларында эшләгән.

Җиңел эш булмый, билгеле. Түбәне кардан, плитәләр өстенә җәелгән измә, асфальтны арындырырга, арматураны кисеп алырга кирәк була, өстәвенә, алардагы кранга эләктерү өчен куелган тимер элмәкләр череп яраксыз хәлгә килгәнгә өстәмә кыенлыклар туа. Ләкин эш бара. 2021 елның 13 апрелендә ике кеше аста, дүртесе 8 метр чамасы биеклектәге түбәдә мәш килә, бина кырыендагы калайларны алгач, кран белән плитәләрне аска төшерергә ниятлиләр. Шул мәлдә аларның берсе, Р.Гыйниятуллин басып торганы кинәт түбәнгә оча, аның артыннан башкалары да гөрселдәп коела башлый, хәтта бина стеналары калтырый. Өч ир-ат хәвефсез урынга күчеп котыла, Радикның андый мөмкинлеге булмый. Тузан басылгач, аның плитә астыннан аяклары гына чыгып торуы күренә. Җансыз гәүдәне МЧС коткаручылары чыгара.

Фаҗига урынында ыгы-зыгы куба, әлбәттә. Җитәкче иптәшләр шунда ук «эшкә» керешә, мондый җирдә эшләргә хокукы булмаган шабашниклар, башка кеше исемендәге таныклыкларны калдырып чыгып китә, алар урынына тиешле документлары булган өч төзүче чакырып китерелә, стропальщик һөнәренә ия кеше эзләп табыла. Мәрхүм Р.Гыйниятуллинның «ИП Гаффаров» аркылы эшкә алынуы турында ялган килешү төзү хәстәре күрелә башлый. Кыскасы, «Билд» җәмгыятен агартып күрсәтергә юнәлдерелгән күп кенә ашыгыч чаралар күрелә. Ләкин ошбу тырышлыкларның бер файдасы да тими. Тикшерү комитеты мондый эшләр барышында үтәлергә тиешле куркынычсызлык кагыйдәләренең аерым таләпләре генә түгел, чынлыкта, тулысынча санга сугылмавын ачыклый. Казаннан килгән полиция экспертлары да күп кенә җитешсезлекләрне күрсәтәләр. Шулай да җинаять эшен тикшерү алты айга сузыла. Чөнки гаепләү белдерердәй җаваплы затны яисә затларны ачыкларга кирәк була.

Ошбу егетләрне эшкә тартып, чынлыкта, җитәкче бригадир булган М.Сәйфуллинның гаебе бар кебек. Ләкин ул үзе дә рәсми рәвештә эшкә алынмаган шабашник кына булып кала. Суд каравына җибәрелгән җинаять эшендә «Билд» җәмгыятенең төзелеш буенча директоры А.Александров, участок начальнигы А.Ульмасов тарафыннан юл куелган җитешсезлекләр дә санап үтелә, әмма алар фаҗигале хәлгә турыдан-туры этәргеч бирмәгән дип белдерелә. Шул рәвешле, әлеге объектта даими рәвештә эшләгән директор урынбасары Ринат Шәйхелисламов гаепле дип табыла. Тикшерүче, экспертлар гына түгел, хезмәттәшләре, ахыр чиктә, хөкемдар да шулай саный. Нәтиҗәдә, 1966 елгы Р.Шәйхелисламов 1 ел ярымга шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм ителә. Закон карарында гына түгел, мәрхүмнең туганнары алдында да гаепле саный ул үзен. Марат Сәйфуллин белән Радикны җирләргә дә баралар, шунда апасына 500 мең сум акча тәкъдим итеп карыйлар. Уртак тел табылмый. Соңрак Р.Шәйхелисламов рухи зыянны каплау йөзеннән 1 млн сум бирергә әзер икәнен белдерә. Тикшерү эшләре барышында зарар күрүче яктан рәсми дәгъва белдерелми.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 28.10.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2776

16+

Югалып барган матурлык

● Алсу Тимергалина тәлинкәләре.

● Асия Семёнова (сулда), Озад Хәбибуллин, Рауза Солтанова.

● Гүзәл Шакирова эше.

● Асия Семёнованың керәч панносы.

● Асия Семёнованың «Татарстан кояшы» исемле иҗат әсәре.

● Ринат Әхмәтов эше.

Казанның Ә.Мәҗитов галереясендә Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсе белән берлектә оештырылган «Осталар» исемле гамәли-бизәү сәнгате күргәзмәсе ачылды. Биредә пыялага ясалган һәм чигелгән шәмаилләр, намазлыклар, балчык эшләнмәләр, агачны уеп ясалган сәнгать әсәрләре, күн паннолар һ.б. урын алган. Күргәзмәне оештыручылар гамәли-бизәү осталарын барлауны, бу төр сәнгатьнең бүгенге хәленә бәя бирүне максат итеп куйган.

Милли бизәкләрдән күзләр камашса да, чынлыкта, татар гамәли бизәү сәнгате өлкәсендә хәлләр мактанырлык түгел. Моны әңгәмә вакытында сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова да раслады. Галимәнең әйтүенә караганда, экспозициядә өмет уятырдай күренешләр юк түгел. Яшел Үзәннән батик остасы Дилә Барышева, мәсәлән, үзенең үтә нечкә итеп иҗат ителгән ефәкләрен алып килгән. Дилә – күренекле рәссам Рәшит Галиуллинның кызы, үзе иҗат итеп кенә калмый, батик сәнгатен балаларга да өйрәтә. Рәсем сәнгатендә әнә шундый буыннар дәвамчылыгына ничек шатланмыйсың. Р.Солтанованы архитекторларның үз сүзен әйтергә омтылулы да куандырган. Шуларның берсе – Рөстәм Шәмсутов инде байтактан керамика өлкәсендә эзләнә һәм ерак гасырларга кайтып иҗат ителгән яңа әсәрләре белән әледән-әле сөендереп тора. Күренекле рәссам Озад Хәбибуллинның хатыны Асия Семёнова шәрыкчә бизәлгән агач һәм керәч эшләнмәләре белән күргәзмәгә нәзакәтлелек өстәгән.

Әмма шатлык-куанычлар шуның белән чикләнә дияргә була. Ник дигәндә, каюлы күн сәнгатендә һаман бер үк авторлар – Софья Кузьминых, Светлана Гарбузова, Наилә Кумысникова эшләрен генә тамаша кылабыз. Күргәзмәдән күргәзмәгә күрә торгач, без аларны инде ятлап бетердек. 1950 еллар ахырында каюлы күн сәнгатен торгызуның башында торган Софья Даниловна да, аның үрнәген күз уңында тотып, күн сәнгатенә 1990 еллар башында килгән бүтән авторлар да зур эш башкарганы өчен хөрмәткә лаек. Әмма белгеч күн сәнгатенә яңа яшь осталар килми, дип борчыла. Каюлы күннең дивар паннолары, мендәрчекләр, намазлыклар рәвешендә генә тәкъдим ителүе, әйтик, кием дизайнында киң файдаланмавы йөзек кашы булган мактаулы бу сәнгатебезнең үсеш офыклары бик чикле дигән фикер уята. Казан сәнгать училищесында каюлы күн уңышлы өйрәтелсә дә, анда укып чыккан яшьләрнең киләчәге нинди? Аларны остаханәләр белән тәэмин итәбезме, иҗат өчен шартлар тудырабызмы, әллә берәмтекләп иҗат ителгән читекләрен дә сата алмыйча иза чигәләрме, яшь осталарны рәхимсез рәвештә салымнар белән буабызмы?

Алтын белән чигүче Луиза Фәсхетдинова да байтак еллар инде япа-ялгыз күз нурларын түгә. Агачны тимер белән бизәкләүче Ринат Әхмәтовка да агач ую сәнгатендә алмаш күренми. Шәһәрләрдә түгел, хәтта авылларда агач бизәү сәнгате үлеп бара. Элеккеге матур капкаларны тимерләре алмаштырды. Тәрәзә кырыйларында челтәрле бизәкләрне дә сагынып сөйләргә һәм галимнәребез туплап чыгарган китаплардан тамаша кылырга гына калды.

Алексеевский туку фабрикасы осталарының кул эшләре дә экспозицияне бер баш югары күтәргән. Әмма фабрикада уртача 55 яшьлек осталар эшли. «Авылларда туку сәнгате генә түгел, хәтта чигү үлеп бара. Элек туташ-ханымнар Сабан туйларына ел буе әзерләнгән. Хәзер исә милли бәйрәмнәрдә кибеттән сатып алынган эшләнмәләр бүләк итәләр. Шулай булгач, туку сәнгате ничек чәчәк атсын? Мәктәпләрдә кызларны тукырга, чигәргә өйрәтмибез икән, бу сәнгатьләрне югалтачакбыз», – дип борчыла Р.Солтанова.

Булган иҗат әсәрләрендә дә декоративлыкның еш очрап, иҗади стилизацияләрнең аз булуы шулай ук сәнгать белгеченең күңелен тырный.

Тагын да аянычрагы – тукучылыкта – асалап сугу (закладная техника), зәркән сәнгатендә – бүртмәле нәкыш (бугорчатая скань), чигү сәнгатендә – тырнак алмалау (ушковая техника) һәм татарның элек-электән килгән башка техникаларның юкка чыгуы. Дөрес, кул осталарының җиңелрәк һәм күбрәк эшләргә омтылулары һәм Европадан кергән модага иярү сәбәпле, күп кенә традицион техника, технологияләребез XIX гасыр ахыры XX йөз башында ук юкка чыга башлаган. Шулай да бүген алар бик аз сандагы осталарыбыз иҗатында яшәвен дәвам итте. Мәсәлән, зәркән осталары Татьяна Соловьева, Ирина Васильева алка, беләзекләрдә катлаулы һәм авыр эшләнешле техникаларны кулланды. Тырнак алмалау Земфира Бикташева иҗатында һаман саен күзләрне иркәли. Әмма яшь буын матавыклы, нәзберек, күп көч, зур осталык сорый торган бу иҗат ысулларыннан бөтенләй баш тартмакчы бугай...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.